РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕНЕҢ МӘГАРИФ МИНИСТРЛЫГЫ
БӨРЕ ДӘҮЛӘТ ПЕДАГОГИЯ ИНСТИТУТЫ
БР фәннәр академиясенең БДПИ каршындагы
«Поликультур фәзадә тел һәм әдәбият» проблем-лабораториясе

Р.Г. ӘХМӘТҖАНОВ

# ТАТАР ҺӘМ БАШКОРТ ТЕЛЛӘРЕНЕҢ ЧАГЫШТЫРМА-ТАРИХИ ФОНЕТИКАСЫ

Укыту кулланмалыгы

БИРСК 2003

УДК – 494.3-023(075)
ББК – 81.63-923г
А – 95

Печатается по решению
Редакционно-издательского совета
Бирского государственного
педагогического института

Рецензент: *доктор филологических наук,*
*проф. Шайхулов А.Г. (БГУ, г.Уфа)*

ӘХМӘТҖАНОВ Р.Г. ТАТАР ҺӘМ БАШКОРТ ТЕЛЛӘРЕНЕҢ ЧАГЫШТЫРМА-ТАРИХИ ФОНЕТИКАСЫ. – Бирск: Бирск. гос. пед. ин-т, 2003. – 112 с. ISBN 5-86607-188-6

Бу китап татар һәм башкорт телләренең тарихи фонетикасына даир төен мәсьәләләр системалы бәян ителгән 1-нче дәреслек. Китапның нигезен замандаш тюркологик казанышлары һәм авторның үз тикшеренүләре тәшкил итә. Кулланмалык вузларның филологик факультетларының мөдәррисләренә һәм талипләренә билгеләнгән.

ISBN 5-86607-188-6

© Ахметьянов Р.Г., 2003
© Бирский государственный педагогический институт, 2003



ЭЧТӘЛЕК

| | | Битләр |
|---|---|---|
| Мөкатдимә | | 4 |
| Беренче баб. | Гомуми мәгълуматлар | 5 |
| Икенче баб. | Синхроник манзара | 19 |
| Өченче баб. | Үсеш конструкциясе. | 31 |
| | 1. Вокализм | 33 |
| | 2. Консонантизм | 49 |
| Дүртенче баб. | Инәкә төрки тел фонетикасы | 63 |
| Бишенче баб. | Фонетик билгеләр буенча генеологик классификация тәҗрибәсе | 78 |
| Алтынчы баб. | Болгар теле мәсьәләсе. Болгар һәм татар фонетикасы | 87 |
| Җиденче баб. | Алтын Урда һәм Казан дәүләте чорларындагы татар теле һәм аның фонетикасы | 93 |
| Сигезенче баб. | Идел=Чулман телләре бергәлегендә татар һәм башкорт телләре | 98 |
| Тугызынчы баб. | Татар һәм башкорт әдәби фонетик нормаларының формалашуы | 106 |
| Кулланылган әдәбият исемлеге (Татар һәм башкорт телләренең тарихи фонетикасы буенча мотлак әдәбият) | | 111 |

# ТАТАР ҺӘМ БАШКОРТ ТЕЛЛӘРЕНЕҢ ТАРИХИ ФОНЕТИКАСЫ

## Мөкаддимә

Татар вә башкорт телләре күп гасырлар буенча янәшә һәм тыгыз бәйләнештә яшиләр. Аларның тарихи язмышлары күп җәһәттән охшаш.

Дөрес, аларның оешу процессларында шактый аермалыклар булган. Башкорт халкы составына кергән кайбер кавем-кабиләләр татарлар составына кермәгән. Һәм киресенчә. Әдәби телнең барлыкка килүе һәм функцияләре җәһәтеннән дә аермалар булган. Ләкин мондый факторларның тәэсире торган саен юыла, җуела, ә үзара тәэсирләшү торган саен көчәя барган. Нәтиҗәдә татар һәм башкорт телләре арасындагы уртаклыклар бүтән бер чорда һәм җирдә кабатланмас бер система рәвешенә кергән.

Менә бу хәл татар һәм башкорт телләренең тарихи грамматикасын бергә карарга, аларның аермаларын да гомумтөрки телләр үсеше кысаларында карарга мөмкинлек бирә. Һәм шулай иткәндә шәебез (предметыбыз) тирәнрәк ачыла, аңлаешлырак була. Шулай итмәгәндә тикшеренүче (һәм өйрәнүче дә) бернинди закончалыкларга сыймаган шикелле булган четерекле мәсьәләләр каршында ярдәмсез кала.

Хезмәтебездәге мисаллар һәм телдә гамәлдәге орфография нигезендә язылып, кирәк табылганда кириллык хәрефле транскрипция бирелде. Борынгы һәм тәнәйтелгән (реконструкцияләнгән) мисаллар, 1790-1990 елларда Бакуда чыгып килгән «Советская тюркология» журналында кабул ителгәнчә, латин хәрефләре ярдәмендә язылды. Фигыльләрнең төп (сүзлек) формасы *=мак//мәк* кушымчасы белән бирелде; чөнки бу формат, *=у//ү* һәм *=ырга//ергә*, *=рга//рга* кушымчаларыннан үзгә буларак, беренчедән, фигыльнең нигезен яшерми, икенчедән, татарча да, башкортча да бер төрле диярлек язылa.

## ТРАНСКРИПЦИЯ

Чагыштырма-тарихи фонетика гыйлемендә транскрипциясез хәлдән чыгып булмый.

Бу хезмәттә татар диалектологиясендә гамәлдә булган махсус *ö*, *о* (русча һәм борынгы төрки типтагы *о*), билгеләреннән тыш Идел-Урал телләренә хас булган кыска «ы» һәм «е»не белдерү өчен *–ы* (чуваш телендә *ă*) һәм *ĕ* (чувашча да *ĕ*) билгеләре алынды.

Латин хәрефләрендә язылган текстларда ул авазлар *y* һәм *ɵ* хәрефләре белән белдерелде. Бүтән специфик төрки авазлар элекке «Советская тюркология» журналындагыча бирелде.



Башкортча *ç* белән буталмасын өчен чувашча *ç* хәрефе урынына *сч* берекмәсе кулланылды.

Кыскартмалар:
бор. – борынгы
к. – карагыз
чаг. – чагыштырыгыз

## БЕРЕНЧЕ БАБ. ГОМУМИ МӘГЪЛУМАТЛАР

§1. Тарихи грамматика дип бер телнең (яисә үзара якын кардәш телләр группасының) бүгенге грамматик (фонетик, морфологик, синтаксик) төзелешенең нинди юллар үтеп ничек формалашуы, ягъни тарихы турында фәнне атыйлар. Грамматика тарихы дип әйткәндә грамматика фәненең үз тарихы аңлашылганлыктан, тарихи грамматика, шулай ук тарихи фонетика, тарихи морфология, тарихи синтаксис терминнары, беркадәр шартлы булсалар да, тиешле мәгънәне кулай белдерәләр.

§2. Татар һәм башкорт телләренең тарихи грамматикасы аерым рәвештә тик XX гасырның икенче яртысында гына эшләнә башлады. Шуңа кадәр бу телләрнең тарихына караган мәгълүматлар төрки телләр җөмләсенә багышланган хезмәтләрдә генә бирелеп килде. Шундый хезмәтләргә О.Н.Бетлингның 1851 елда алманча пичәтләнгән «Ueber die Sprache der Jakuten» («Якутлар теле турында») дигән классик хезмәте (анда мишәр сөйләшләре фонетикасы турында чагыштырма күзәтүләр дә бәян ителә), В.В.Радловның алман һәм рус телләрендә нәшер ителгән күпсанлы китапплары (шулар арасында безнең өчен мөһимрәге «Phonetik der nördlichen Türksprachen». Leipzig, 1882-1883) керә.

Татар, башкорт һәм чуваш телләре тарихының аерым мәсьәләләре XIX гасыр азагыннан башлап революциягә кадәр А.Г.Бессонов, Н.И.Ильминский, Ф.Е.Корш, чыгышы белән хакас Н.Ф.Катанов һәм, бигрәк тә, Н.И.Ашмаринның күпсанлы хезмәтләрендә, аннары фин галимнәре Һ.Паасонен, А.Каннисто һ.б. алманча (немецча) язылган китап һәм мәкаләләрендә яктыртылды. Революциядән соңгы чорда татар һәм башкорт телләре тарихына турыдан-туры кагылышлы темаларга фин галимнәре М.Рясянен һәм Е.Итконен, рус галимнәреннән В.А.Богородицкий һәм Н.К.Дмитриев аеруча әһәмиятле хезмәтләр яздылар. Безнең тема өчен рус галимнәре Н.А.Баскаков, А.Н.Кононов, А.М.Щербак һәм башкаларның гомумтюркологик яисә бүтән төрки телләргә багышларган хезмәтләре, Э.В.Севортянның рус телендәге тарихи-этимологик тикшеренүләре дә читләтеп үткесез мөһим.

Шуңа әйтергә кирәк ки, тюркологик хезмәтләрдә телгә алынуы һәм аерым үзенчәлекләре каралып үтелүе җәһәтеннән татар теле төрки телләр арасында беренче урыннарның берсендә тора.

Туган телләренең тарихын өйрәнү өлкәсендә татар галимнәре дә күптәннән бирле активлык күрсәтеп киләләр. Идел-Чулман телләре тарихына кагылышлы иң күренекле ачышларның берсе татар Х.Фәезхановның «Три надгробных булгарских надписи» дигән мәкаләсендә (1863) бәян ителде. К.Насыйри китапларында күпсанлы тарихи-этимологик күзәтүләр ясалды. XX гасыр башларында Г.Әхмәровның тарихи диалектологик хезмәтләре басылып чыкты. Октябрь революциясеннән соң Икенче бөтендөнья сугышына кадәрге чорда татар теле тарихының аерым мәсьәләләре Г.Шәрәф, Г.Алпаров һәм Ш.Рамазановларның хезмәтләрендә җентекләп каралды, Җ.Вәлиди тел тарихы өчен беренче дәрәҗә әһәмияткә ия булган диалектологик тикшеренүләр башлап җибәрде.

1934 елда Казан университеты профессоры В.А.Богородицкийның татар тел гыйлеме өчен генә түгел, бөтен тюркология өчен дә әһәмияткә ия булган «Введение в татарское языкознание в связи с другими тюркскими языками» дигән зур хезмәте басылып чыга. Бу әсәрне язуда аңа Г.Шәрәф зур ярдәм күрсәтә.

Башкорт телен тарихи планда тикшерү Н.К.Дмитриев хезмәтләрендә («Грамматика башкирского языка», М.-Л., 1948 һ.б.) шактый зур урын ала.

Егерменче гасырның икенче яртысында чагыштырма-тарихи тикшеренүләр шактый җанланып китә. Л.Җәләйнең «Татар теленең тарихи фонетикасы буенча материаллар» (Казан, 1954), Л.Яфаровның «Татар теле үсештә» (Казан, 1955), Д.Г.Тумашева һәм Г.Х.Әхәтовларның Көнбатыш Себер татарлары диалектын чагыштырма планда өйрәнүгә багышланган хезмәтләре (1960 еллар), Л.Т.Мәхмүтованың татар теленең көнбатыш (мишәр) диалектын һәм Р.Г.Әхмәтьяновның татар теленең Идел-Чулман телләр союзындагы урынын чагыштырма-тарихи җәһәттән яктырткан хезмәтләре (1970-1980 еллар), татар теленең өчтомлык аңлатмалы сүзлеге (1977-1981), күләмле диалектологик сүзлекләр һәм диалектологик тикшеренүләр (Л.Җәләй, Л.Мәхмүтова, Н.Борһанова, Д.Рамазанова, Ф.Баязитова, Т.Хәйретдинова һ.б.), иске татар язма ядкәрлекләре буенча тирәнтен башкарылган тикшеренүләр (Ф.Фәсиев, Ф.Хисамова һ.б.), Э.Хаковның татар әдәби-язма теле тарихы буенча язылган күпсанлы хезмәтләре һ.б. дөнья күрде. Татар, чуваш һәм башкорт телләре тарихы буенча рус галимнәреннән Б.А.Серебренников аеруча күп эшләде.



Башкорт тел гыйлемендә шул елларда тарихи грамматикага даир темаларга Җ.Киекбаев һәм Ә.Биешев күп хезмәтләр яздылар, Т.Гариповның татар һәм башкорт телләрен чагыштырып язган мәкалә вә китаплары дөнья күрде, С.Миржанова, Н.Максутова һәм башкаларның башкорт диалектлары буенча тикшеренүләре язылды[1]. 1976 елда Ә.М.Атнабаев белән В.Ш.Псәнчиннарның «Башкорт теленең тарихи морфологиясе» нәшер ителде. Болар барсы да татар һәм башкорт телләренең тарихи грамматикасын арытабан өйрәнүгә җитәрлек базис тәшкил итәләр.

§3. Тел тарихын язу өчен җитәрлек мәгълүмат кирәк. Элекке заманнарда телне тәфсилләп, бөтен үзенчәлекләрен бәйнә-бәйнә бәян итү, тасвирлау омтылышлары бик сирәк булган. Үз заманындагы төрки телләрне лексика һәм грамматикасын тулай рәвештә тасвирлап чыгу омтылышын XI гасырда Мәхмүт Кашгари ясый. Ул үзе төрки халыклар яшәгән күп кенә өлкәләрне йөреп чыга һәм үз зиарәт кылалмаган өлкәләр (мәсәлән, Болгар һәм Сувар җирләре) теле турында сәүдәгәрләрдән һ.б. сораша. Туплаган материалларын эшкәртеп ул «Дивану-лугат ит түрек» (Төрки сүзләр җыентыгы)[2] дигән өч томлык сүзлеген һәм төрки телләр граматикасын яза. Аның шул төзегән сүзлеге безнең гасырга ике нөсхәдә килеп җитә, ә граматикасы югала.

Мәхмүт Кашгари сүзлеге – дөньяда тиңе булмаган бай лексикологик, фольклористик һәм гомумлингвистик хезмәт. Ләкин ул заманда телне тасвирлау ысулларының камилсезлеге бу хезмәттә дә барыбер сизелә.

Мәхмүт Кашгаридан соң күп гасырлар дәвамында – XIX гасырга кадәр төрки телләр буенча аның сүзлегенә тиң килерлек әсәрләр язылмый. Аннары XIII гасырда чыккан монгол яулары төрки дөньяны тәмам болгатып ташлый: күп халыкларның исемнәре дә калмый. Телләр берберсе белән тәмам тупланып, яңа этнослар, яңа телләр формалаша башлый. Хәзерге төрки телләрнең оеша башлавы XVI гасырга туры килә.

Менә шундый хәлләр аерым төрки телләрнең тарихын тәнәйтүнә[3] (без бу диалекталь сүзне моңарчы кулланып килгән торгызу – *восстановление* сүзе урынына, шуны алмаштырып кулланабыз) шактый кыенлаштырган.

---

[1] Китап һәм мәкаләләрнең исемнәре, чыккан еллары һ.б. астөшмәләрдә һәм махсус күрсәткечтә (к. 111 б.) бирелә.
[2] Беренче тулы басмасы: Divanü lûgat it türk tercümesi. I-III c. Ankara, 1939-1941.
[3] Татар һәм башкорт сөйләшләрендә *тәнәйту* «җирне, агачны яисә терлекне продукт бирүдән беразга туктатып, ял иттереп, иң замант (продуктив) чагындагы сыйфатка кайтару» дигән сүз. *Торгызу* сүзе, безнеңчә, артык күп мәгънәле.

Шулай да һәрбер төрки тел тарихын диярлек җитәрлек ышандырырлык һәм тәфсиллек белән шактый борынгы заманнардан алып тәнәйтергә була. Моның өчен тиешле чыганакларны табарга, җыярга һәм файдалана белергә кирәк.

§4. Тел тарихын, тарихи грамматиканы өйрәнүдә түбәндәге мәгълүмат чыганаклары файдаланылды:

а) гомумхалык теле һәм аның әдәби формасы үзе;

б) үткән дәверләрдән калган язма ядкәрлекләр;

в) диалектологик мәгълүматлар;

г) ономастик мәгълүматлар;

д) кардәш һәм күрше телләр материалы.

Шул чыганаклардан табылган мәгълүматлар чагыштырма-тарихи методика алымнары буенча теге яки бу закончалык формулаларына салынып, теге яки бу сүзнең, морфологик элементның кызыксындырган чордагы яңгырашы һәм мәгънәсе билгеләнә. Табылган элементлар телнең аерым этаплардагы торышын, тулай картинасын тәнәйтергә, реконструкцияләргә мөмкинлек бирәләр.

Татар теленең норматив материалы шактый зур матур әдәбиятта һәм фольклор әсәрләрендә (Н.Исәнбәтнең өч томлык «Татар халык мәкальләре», унөч томлык «Татар халык иҗаты» сериясе һ.б.), күпсанлы сүзлекләрдә (беренче чиратта өч томлык «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә) теркәлгән.

Башкорт теле материалы шулай ук матур әдәбиятта, унсигез томлык фольклор мәҗмагасында, ике томлык аңлатмалы сүзлектә һ.б.ш. җитәрлек дәрәҗәдә чагылыш тапкан.

Язма ядкәрләргә килгәндә, татар теленең үзенчәлекләрен теге яки бу дәрәҗәдә чагылдырырдай булган ядкәрлекләргә түбәндәгеләр керә.

а) Урта Идел регионында табылган руник (Урхун-Енисей хәрефләре белән язылган) язулар[4] (X-XII гасырлар);

б) Колгалинең (Кол Галинең) «Кыйссаи-Йусеф» дигән шигъри романы (Йосыф китабы), аның төрле кульязма вариантлары (XIII-XIX гасырлар);

в) кабер ташларындагы язулар (эпиграфик ядкәрлекләр) (XIII-XIX гасырлар);

г) Алтын Урда чоры ядкәрлекләре: акчалардагы язулар һ.б. «Нәһҗел-фәрадис»; С.Сәраи, Котби һ.б. әсәрләре;

[4] Бу турында K.H.Kurbatov. Idil-Çulman (Volga-Kama) boylarında ele geçen runik kitabeler//Türk dünyas araştırmaları, №88. 1994 (Istanbul). 104-113 б.



д) Казан дәүләте чорыннан калган документлар, әдәби әсәрләр (Мөхәммәтәмин, Колшәриф, Мөхәммәдьяр һ.б. әсәрләре, «Сиражүл-Колубь», XVI гасыр коръән тәфсире һ.б.ш.), хан приказлары;

е) Касыйм ханлыгыннан калган документлар, Кадыйр Гәлибәкнең «Мәҗмугыль-тәварих» әсәре;

ж) тарихи һәм дини-тарихи әсәрләр; Хисаметдин Болгариның «Болгар тарихы», Батыршаның патшага язган хаты һ.б.;

з) Рус патшалыгы чорында язылган татарча рәсми документлар, эш кәгазьләре (XVI-XIX гасырлар);

и) XVII-XX гасыр башы чорларындагы әдәби әсәрләр, сәяхәтнамәләр, хатлар, истәлекләр һ.б.;

й) татар һәм башкорт шәҗәрәләре;

к) татар теле буенча XVIII-XX гасырларда язылган иске хезмәтләр (И. Һәм С.Хәлфиннәрнең сүзлек вә грамматикалары, Й.Гиганов сүзлеге, А.Троянскийның сүзлеге һәм грамматикасы, Г.Мәхмүтов, М.Иванов, К.Насыйри, В.Катаринский, М.Өметбаев хезмәтләре, «Шура», «Аң» журналларында басылган материаллар һ.б.);

л) төрле чорлардан калган русча һәм немецча (алманча) документларда, этнографик, лингвистик хезмәтләрдә һ.б. теркәлгән татар-башкорт сүзләре һ.б.

**Диалектологик чыганаклар** – башлыча диалектологик хезмәтләрдә (сүзлекләрдә, тасвирламаларда һ.б.), шулай ук төбәкләрдәге фольклор әсәрләрендә, документларда теркәлгән материал. Татар һәм башкорт диалектлары буенча хәзерге көндә кечерәк вә күләмле сүзлекләр, уннарча китаплар, йөзләрчә мәкаләләр нәшер ителгән.

**Ономастик чыганаклар** – башлыча топонимик мәгълүматлар (елга-күл, тау-үзән, авыл-кала һ.б. исемнәре), шулай ук борынгыдан килгән исем-фамилияләр. Ономастик материалда еш кына телнең инде онытылган, бүтән чыганакларда табылмый торган элементлары табылырга мөмкин. Мәсәлән, *Янгаличев* дигән электән килгән татар (мишәр) фамилиясе борынгы заманда бездә *янгалыч* дигән исем һәм сүз булганлыгын күрсәтә. Төньяк Кавказ халыкларында *янкылыч*, *җанкылыч* «яшен тәнресе» дигән сүз (ул борынгы *яң* «җая» һәм *кылыч* «корал; ук» сүзләреннән кәш). Димәк, элек татар телендә дә (һәрхәлдә мишәр диалектында) *янкылыч* яисә *янгылыч* «яшен», ук һәм «җая» сүзе булган. Фонетик җәһәттән моңда **к>г** күчеше булганлыгы чагыла.

**Кардәш һәм күрше телләр материалы**. Татар һәм башкорт телләре төрки телләр семьялыгына, бу семьялыкның кыпчак группасына, аның Идел-Урал (икенче төрле атаганда кыпчак-болгар) тармагына карыйлар. Шул хәлдә татар һәм башкорт телләренең тарихын бер-берсенең, аннары кыпчак төрки телләренең, ниһаять, барча төрки

телләр материалын файдаланмыйча язуны күз алдына китерү дә мөмкин түгел.

Татар һәм башкорт телләре төрки телләр булу белән бергә, Идел-Чулман телләре союзына да керәләр. Бу союзга кергән биш тел – башкорт, татар, чуваш, мари һәм удмурт телләре – кимендә мең ел дәвамында бер-берсеннән сүзләр, тәгъбирләр алып, грамматикаларын охшашландырып килгәннәр. Татар һәм башкорт телләре тарихын тәнәйтү өчен ошбу союзга керган бүтән телләр материалын файдалану мотлак кирәк[5].

Бу урында мәшһүр социолог һәм философ Ф.Энгельсның түбәндәге сүзләрен китерү урынлы булыр: «Туган теленнең материал һәм формалары аларның килеп чыгышын һәм әкренләп үсешен эзмә-эш күреп үткәндә генә тулысынча аңлашыла, ә бу исә беренчедән, теленең катып калган формаларына, икенчедән, кардәш үле вә тере телләр материалына тиешле игътибар бирмичә мөмкин түгел» (тәрҗемә безнеке – Ә.Р.).

Күптәннән бирле төрки телләр (бигрәк тә татар теле) белән тәэсирләшеп килгән рус теленең, бигрәк тә аның лексикасының төп материалы да күп нәрсә бирә.

Кызганычка каршы, татар һәм башкорт тел гыйлемендә кардәш вә күрше телләр материалын тел тарихын тәнәйтү максатларында файдалану бик тә нокcанлы, кимчелекле рәвештә бара. Беренчедән, элекке СССРда озак еллар дәвамында һәр аерым төрки тел филологиясе, бигрәк тә тел гыйлеме үз казанында кайнарга тиеш булды. Икенчедән Казан һәм Уфа вузларының татар һәм башкорт бүлекләрендә мантыйк буенча татар һәм башкорт телләреннән тыш кимендә тагын бер төрки тел өйрәнелергә тиеш иде – бу эшләнмәде һ.б. (бу әйткәнебез түбәндә конкретлаштырылыр).

§5. Тел тарихын өйрәнүнең гомуми принциплары түбәндәгеләрдән гыйбарәт.

Беренчедән, тел тарихын халык тарихыннан аерырга ярамый, ягъни «тел тарихы – ул халык тарихы» (Яков Гримм) икәнлеген истә тоту зарур. «Тел тарихында бик күренерлек рәвештә шул телдә сөйләшүче халык тарихы чагыла»[6]. «Тел – инсанның рухи эшчәнлеге – иң күпкырлы рәвештә белендерелгән өлкә. Һәр халыкның теле – аның сүзләрдә вә грамматик категорияләрдә гомумләштерелгән һәм беркетелгән тарихи тәҗрибәсе ул. Кеше яшәүшенең телдә тегеләйме-

[5] Бу хакта к. В.А.Серебренников, Н.И.Исанбаев. Восточные финно-угорские языки и их значение для истории тюркских языков Поволжья//СТ, №5, 1979.
[6] И.Абаев. Осетинский язык и фольклор. М., 1949, стр.9.



болаймы чагылмаган бер җәһәте дә, бер култыгы да юк»[7]. Шуңа күрә тел тарихы, аны фәнчә дөрес яктыртканда, гомумтарихи һәм этногенетик мәсьәләләрне хәл иткәндә дә беренче дәрәҗәдәге әһәмияткә ия була. Чөнки «тел, реальләштерелгән аң буларак, үзенең иҗатчалары тарихын язма документлардан да ышандырыклырак итеп саклый ала»[8].

Бу сүзләр интуитив рәвештә түгел, тел тарихы өлкәсендә озак еллар эшләгән галимнәр тарафыннан бик күп күзәтүләр нигезендә әйтелгәннәр. Алар һичшиксез һәм тулысынча дөрес, ләкин аларны конкретлаштырасы, төгәл закончалыклар, формулалар шәкелендә тәгъбирлисе бар. Менә бу эш әле һаман тиешенчә үтәлмәгән. Этимологиянең ягъни сүзләр тарихының тарихка багланышы шактый ачык күренеп тора, монда югарыда әйтелгән сүзләрнең дөреслеге шик тудырмый. Ә менә морфология һәм фонетика өлкәләрендә тарихның ничек чагылуы әлегә баркайда да бәйнә-бәйнә бәян ителми. Монда, күрәсең, тарих, тарихи процесс проблемаларының үзләренең дә хәл ителеп бетмәве кире тәэсир ясый торгандыр, күрәсең.

Тел белән тарих багланышын якынча конкретлаштыру омтылышын В.А.Богородицкийның түбәндәге сүзләрендә күрергә була: «Һәр халыкның теле гүяки аның үткәндә кичергән мәдәни тормышының ике өлкәдә – мәдәни тормышта һәм социал тарихының елъязмасы»[9]. Монда тел тарихының чагылышын ике өлкәдә – мәдәни тормышта һәм социаль тарихта аерып карарга кирәклеге күрсәтелә дип әйтеп була. Социаль тарих дигәннән этник тарихны – яулап алулар, кушылулар һәм аерылулар нәтиҗәсендә яңа телләр, диалектлар һ.б. барлыкка килүне дә аңласак, мәдәни тарих белән башлыча сүзләр тарихы, социаль тарих белән морфология һәм фонетика тарихы багланган. Социаль процесслар, К.Маркс өйрәткәнчә, кешеләр аңыннан үтә, ләкин бик еш кына бәндәләр үзләре һич теләмәгән нәтиҗәләргә китерә, алар омтылмаган ярларга чыгара. Шул социаль үзгәрешләр нәтиҗәсендә туган тел үзгәрешләре, бигрәк тә фонетик үзгәрешләр, бигрәк тә «аңнан өстен» булганнар. Ләкин аларның «аңнан өстенлеге» социаль-этник үзгәрешләрнең фонетик үзгәрешләр белән багланыш законнарын таныл-белергә киртә куймый. Һәм без шул багланыш законнарын вә аларның конкрет чагылышларын таныл-белү юнәлешендә эшләргә тиешбез.

Икенчедән, телдәге үзгәрешләр – объектив күренеш. Аларны таныл-белү өчен алар турындагы барча мәгълүматларны тупларга

[7] И.Абаев. Осетинский язык и фольклор. М., 1949, стр.9.
[8] Л.Җәлойнең Казан татарларының килеп чыгышына багышланган конференциядә сөйләгән сүзләре. К.//Происхождение Казанских татар, Казань, 1948, стр. 81.
[9] В.А.Богородицкий. Этюды по татарскому и тюркскому языкознанию. Казань, 1993. С.3.

кирәк. Шунсыз хата ясау ихтималы зуррак булачак. Мәсәлән, без телдәге берәр сүзнең килеп чыгышын һәм бүгендәге яңгыраш вә мәгънә структурасын белергә телибез икән, без ул сүз кулланылган барлык өлкәләрне һәм телләрне билгеләп чыгарга ягъни, лингвистик терминологиядә тәгъбирләсәк, сүзнеең таралыш ареалын билгеләргә тиешбез. Шулай ук, нинди дә булса морфологик элементның яисә фонетик күренешнең чыгышын-тарихын тикшергәндә дә эшне аларның таралыш ареалларын билгеләүдән башлау мотлак зарур.

Өченчедән, нинди дә булса лингвистик күренешне тарихи планда тикшергәндә *якыннан еракка* кагыйдәсе буенча эш итү мотлак. Ягъни туган телнең бер элементын алып, аның чыгышын-тарихын билгеләү максатында барлык мәгълүм параллельләрен жыясың-күрсәтәсең икән, тәүдә аның туган тел диалект вә сөйләшләрендәге, аннары иң якын телдәге, шуннан соң ераграк торган телдәге чагылышларын барларга кирәк («якын» һәм «ерак» сүзләре биредә вакыт, фәза-ара һәм кардәшлек мәгънәләрендә аңлашылырга тиеш). Әгәр без «баш аша сикереп» туган тел элементының ерак параллелен китерсәк һәм шундый чагыштыру нигезендә нәтиҗәләр ясыйй башласак, безнең белгәнебез тулы булмау өстенә, ялгыш булырга да мөмкин.

§6. **Төп гомуми фонетик үзгәреш законнары.** Татар һәм башкорт телләрен чагыштырып караганда без шуны күрәбез: бу телләрдә әйтелгән, язылган бердәй текстта бөтен-бөтен җөмләләр, хәтта пассажлар, сәхифәләр еш кына сүзмә-сүз бер-берсен кабатлыйлар. Ләкин ул бердәй сүзләрнең яңгырашыы (язуда – хәрефләре) төрлечәрәк, аермалырак. Мәсәлән, түбәндәге текстны алыйк:

| **башкортча:** | **татарча:** |
|---|---|
| *Башкорт ерендә королтайҙар борон-борондан үткәрелә килгән. Бындый йыйындарҙа бөтә ырыуҙарҙан да вәкилдәр катнашкан һәм улар ил, халык алдында торган мөһим мәсьәләләрҙе бергәләп хәл иткән. Әлбиттә, беҙҙең ата-бабаларыбыҙҙы ер язмышы, бердәмлек, ирек һәм азатлык мәсьәләләре борсоган, һүҙ шул турала булган.* | *Башкорт җирендә корылтайлар барын-борыннан үткәрелә килгән. Мондый җыеннарда бөтен ырулардан да вәкилләр катнашкан һәм алар ил, халык алдында торган мөһим мәсьәләләрне бергәләп хәл иткән. Әлбәттә, безнең ата-бабаларыбызны җир язмышы, бердәмлек, ирек һәм азатлык мәсьәләләре борчыган, сүз шул турында барган.* |
| («Королтай» листовкасыннан, Эстәрлетамак, 7 февраль 1996 ел). | (Тәрҗемә безнеке – Р.Ә.) |



Монда әйтелеше-язылышы аермалы сүзләрдә (алар барлыгы 35 сүздән 12) түбәндәге аваз-өн башкалыклары күзәтелә: тартыкларда башкортча *–й–* урынына татарча *–җ–* (*ер ~ җир, йыйын ~ җыен*); башкортча *–ҙ–* урынына татарча *–д–* (*бердәмлек ~ бер ҙ әмлек*), *-н-* (*мәсьәләләрҙе ~ мәсьәләләрне* һ.б.) яки, сирәгрәк *–л-* (*ырыу ҙ ар ҙ ан ~ ырулардан*): башкортча *–д-* урынына татарча *–л-* (*вәкилдәр ~ вәкилләр*); башкортча *–б-* урынына татарча *–м-* (бындый ~ *мондый*); башкортча *–с-* урынына татарча *–ч-* (*борсоган ~ борчыган*); башкортча *–һ-* урынына *–с-* (*һүз ~ сүз*); сузыкларда башкортча *–у-* урынына татарча *–а-* (*улар ~ алар*); башкортча *–и-* урынына татарча *–ә-* (*әлбиттә ~ әлбәттә*); башкортча *–а-* урынына татарча *–ы-* (*бындай ~ мондый*); һ.б. (орфографик шартлылыктан гыйбарәт булган аермаларны әйтеп тормадык).

Бу аермалыклар кайдан килә соң? Әлбәттә, очраклы яисә теләсә ничек түгел. Әйтик, башкортлар: туктале, без татарча «ч» урынына һәрвакыт «с» авазын әйтеп сөйләшик, аларның *бердәмлек* дигәнен без *берҙәмлеккә* үзгәртик, дип сүз куешмаганнар, әлбәттә.

Юк, бу аермалар хәтсез барынгылыктан киләләр һәм сөйләшүчеләр ихтыярыннан тыш яшиләр. Аннары, әгәр без озынрак һәм төрле-төрле эчтәлектәге текстларны тикшереп карасак, аермаларның саны чикле һәм һәрдаим бер үк авазларда булганлыгын күрәбез (асылда, әле китерелгән кечкенә текстта башкорт һәм татар телләре арасындагы аваз аермалыкларының иң мөһимнәре барсы да чагылыш тапкан).

Галимнәр кардәш телләр, диалект һәм сөйләшләр арасындагы күп төрле аваз аермалыкларын күздән кичереп һәм анализлап аваз тәңгәллекләре һәм аваз күчешләре дигән төшенчәләрне кулланышка керткәннәр. Аваз тәңгәллеге ул, мәсәлән, татарча «ч» авазы урынына башкортча «с» авазы туры (тәңгәл) килү, кулланылу. Аваз тәңгәллеген зур булмаган бердәй текстларны югарыдагыча чагыштырганда да күрергә була. Ә менә аваз күчешен билгеләү бик үк ансат түгел. Чынлап та, татарча *качышлы*, ә башкортча *касышлы*, бу яңгырашларның кайсы борынгырак, әүвәлгерәк? *Качышлыдан касышлы* килеп чыкканмы, киресенчәме? Яисә мәсьәлә тагын да башкача, өченче бер яңгыраштан бер тарафта *качышлы*, икенче тарафта *касышлы* килеп чыкканмы?

Чагыштырмалы тел гыйлемендә тагы синхрония һәм диахрония төшенчәләре кулланыла: синхрония – телнең хәзерге күренеше, телләрнең бүгенге (гомумән билгеле бер конкрет датадагы) аерма вә охшашлыклар манзарасы булса, диахрония – телнең һәм телләрнең төрле заманнардан алынган гомум күренешләренең чагыштырмасы ул. Аваз тәңгәллекләре диахроник планда фиксацияләренең чагыштырмасы ул. Аваз тәңгәллекләре диахроник планда фиксацияләнә һәм тикшерелә.

Аваз күчешләрен, аларның юнәлешен, тарихын билгеләү өчен исә бик күп тел һәм тарих фактларын вә закончалыкларын белеп алып, аек мантыйклы фикер йөртү нигезендә нәтиҗәләр чыгару ягъни диахроник тикшеренүләр алып бару шарт. Чөнки тыштан гади генә күренгән аваз тәңгәллекләре дә бик катлаулы тарихи вакыйгалар соңында барлыкка килгән булулары мөмкин.

Җилсез яфрак та селкенми, сәбәпсез берни дә булмый. Телдәге аваз күчешләре дә тик торганнан гына булмый.

Телнең гомумән һәм аның фонетикасының хосусан үзгәреш, алгарыш, үсеш сәбәпләре иң гомуми планда шул телдә сөйләшүчеләр тормышыннан чыга, дидек. Монысы дөрес, ләкин фонетик үзгәрешләрнең саф лингвистик сәбәпләре турында да сөйләнелә.

Телләрнең һәм аларның фонетикасының тарихи үзгәрешендә ике мөһим сәбәпне аеру зарур. Беренче «сәбәп» – барлык телләргә хас булган үзгәреш төрләре. Боларның иң мөһиме – сүзләрнең һәм тәгъбирләрнең барча телләрдә тулай кыскара бару законы. Үз эчендә генә үсә торган телдә сүзләр һәм фразеологизмнар һәрвакыт кыскаралар, ике сүз сүзтезмәләр бер сүзгә әверелә һ.б. (бу турында тагын к. §8) дип әйтергә ярый. Дөрес, сүзләр озынаю, сүзләргә протеза (алдан аваз кушылу), интертеза (сүз эчендә яңа аваз пәйдә булу), эпитеза (сүз азагында аваз яки авазлар кушылу) күренешләре дә юк түгел. Ләкин ул күренешләр күпчелек очракта читән кергән сүзләрне үзләштергәндә күзәтелә. Телнең электән килгән үз сүзләрендә андый өстәмәләр гадәти булмаган аваз чатлашулары килеп чыкканда, ягъни шул ук кыскарту нәтиҗәсе буларак пәйда була (типик кыскаруга типик булмаган өстәмә җавап булырга мөмкин)[10].

Кыскара бару закончылыгыннан тыш күп кенә типологик яки фреквенталь аваз күчешләре бар. Мәсәлән, сүз нигезенләренең азагы аеруча үзгәрүчән булу, авазларның пардашлыкка омтылуы, сузык авазларның бер-берсеннән ерагаерга тиешлеге һ.б.[11] Бу закончалыклар белән бик белеп эш итү тиешле. Кайбер галимнәр, әйтик, татар-башкорт вокализм системасы үзгәрешен шундый типологик үзгәреш законнары нигезендә генә аңлаталар (к. алдарак – § 23). Тик мондый аңлату күп нәрсәне ачып бирми, чөнки атаклы француз лингвисты А.Мейе күптән инде кисәтеп куйган: «Гомум эволюция фонетика формулалары мотлак үтәлергә тиешлекне түгел, ә ихтималлыкны гына белдерәләр»[12]. Мотлак пәйдә булырга, йөз бирергә тиешле аваз күчешләре булган, ләкин алар

---

[10] Төрки телләргә карата бу закончалыкның чагылышлары тур. к. Т.Х.Акбаев. О причинх редукции гласных в тюркских языках. СТ №3, 1986, с. 3-14.

[11] В.А.Серебренников. Вероятностные обоснования в компаративистике. М., 1974.

[12] А.Мейе. Сравнительный метод в историческом языкознании. М., 1954. с. 78.



нинди дә булса типологик «фреквенталь» закончалыклар буенча түгел, конкрет тарихи процесслар логикасына буйсынып барлыкка килгәннәр. Гомумән аваз күчешләре телнең үзенең эчке «серле» хасиятләреннән эзләү-эзләтү тел тарихын гомуми тарихтан аерырга теләүдән килеп чыга булса кирәк.

§7. Безнең тикшерү өлкәбезгә даир хосуси фонетик үзгәреш закончалыклары.

Татар һәм башкорт фонетик системаларының уртак һәм аермалы булган үзенчәлекләрен аңлау өчен аларның гомумтөрки фонетик системасындагы урыннарын билгеләү зарур. Ә моның өчен исә кайбер хосуси фонетик закончалыкларны белергә кирәк.

Адәм баласының сүзне аңлау һәм сөйләү күнекмәләре (артикуляцион база) нарасый чагында (2-6 яшьләрендә) үк формалаша һәм ныгып җитә. Шуңа күрә дә инде үсә төшкәч икенче бер телне сөйләмдә аңлау һәм шул телдә сөйләү күнекмәләрен, күнегелмәгән чатлашуларны (сочетания звуков) үзләштерү, аннары, әйтергә гадәтләнмәгән тартык авазларны әйтә башлау, ят сузыкларны үзләштерү, тәҗрибәләр күрсәткәнчә, ничектер читенрәк бара. Гомумән, үзләштерү кыенлыклары буенча авазлар, иң җиңелен иң өскә куйганда, түбәндәгечә урнашалар:

Сузыклар

Тартыклар

Аваз чатлашулары; иҗек характеры

Бөтен тел буенча караганда, чит телнең фонетик нормаларын үзләштерү – иң авыры: кеше бүтән телнең грамматик төзелеш һәм лексик байлыгын тәмам үзләштергәч тә, фонетик үзенчәлекләрен белеп бетермәстән, әйткәндә җиренә җиткермәскә, чит тел авазларын яки аваз чатлашуларын туган тел авазлары яисә аваз чатлашулары белән алмаштырып сөйләргә мөмкин. Чит телдә туган телнең артикуляцион базасы нигезендә сөйләү **акцент** дип атала.

Хәзергә заманда тел өйрәнү чаралары көчле, мөмкинлекләр зур һәм гадәттә чит телдә сөйләүчеләр үз акцентларын бетерергә яисә киметергә тырышалар. Борынгы заманнарда акцентны бетерү турында сүз дә булмаган. Һәм элеккке чорларда бөтен-бөтен кабиләләр икенчеләренә буйсынып, көчлеләрнең телен тиз генә кабул итү зарурлыгында калганнар. Икенче бер очракларда көчле кавем-кабиләләр көчсезләрнең бөтен ир-атын кырып, хатын-кызларын хатын иткәннәр.Еш кына андый хатын-кызлар барлык хатыннарның күпчелеген тәшкил иткәннәр (кайбер төрки телләрдә «хатын» мәгънәсендә хәзер дә *улҗа* «трофей» сүзе йөри).

Өченче бер хәлдә төрки кабиләләр бөтенләй башка телдә сөйләшүче кабиләләр белән дуаль ыругчылык мөнәсәбәтләренә кергәннәр ягъни шул кабиләдән кыз алып кыз бирергә сөйләшкәннәр (шундый дуаль

ыругчылык мөнәсәбәтләре калдыгы буларак телебездәге *җиңгә, җизни, кияү, кода, кодагый* сүзләре йөри – алар кытай-монгол яисә тунгус-маньчжур телләреннән алынганнар). Менә шундый хәлләрдә акцент белән сөйләшүчеләр телнең фонетик нормаларын үзләренчә борып җибәрә алганнар: яулап алынган хатыннар үзләренең акцентларын балаларына йоктырганнар. Ләкин фонетика грамматика илә тыгыз бәйләнгән һәм яңа фонетик нормалар грамматик нормаларның да үзгәрешенә китергән. Шул рәвештә яңа телләр пәйда булган. Чыннан да күп кенә борынгы кавем-кабиләләрнең (мәсәлән, динлиннарның, меркитларның һ.б.) үз телләрен онытып төрки телгә күчүе тарихтан конкрет билгеле.

Ничек кенә булмасын, фонетикада булынган информация халыкның борынгы тарихы турында төгәл, ышандырырлык нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә. Чагыштырма-тарихи фонетика мәгълүматлары буенча халык тарихыы турында нәтиҗәләр ясаганда түбәндәгеләргә нигезләнелә:

а) фонетик үзгәрешләрнең спонтан хәрәкәте, грамматика һәм лексикада кебек үк, бер яктан системалылыкка, симметриягә һәм төгәллеккә мәеллерәк булса, икенче яктан кыскартуга омтылышлы (к. §6, 8);

б) фонетик системага телнең иң хәрәкәтчән состав өлеше – лексика дә тәэсир итәргә, аның ислахына (тирән үзгәртелүенә) китерергә мөмкин;

в) фонетик үзгәрешләр бер яктан бөтен тел системасы белән, икенче яктан күпсанлы сөйләшүчеләр тупламының тотрыклы сөйләү (артикуляцион) күнекмәләре белән тыгыз бәйләнгәнлектән, тарихи процесслар – масштаблы этник вакыйгалар, аларның нисби хронологиясе һ.б. турында мәгълүмат бирә. Һәрбер колачлы (күп сүзләрне эченә алган) фонетик үзгәрешкә билгеле бер тарихи ситуация туры килә, дип әйтеп була;

г) бүгенге кардәш күрше телләрдә фонетик җәһәттән бөтен бер аермалар җөмләсе бар булу бу телләрдә сөйләшүчеләрнең һич югында кайбер элгәрләре борынгы заманнарда озак вакытлар аерым-аерым яшәүләре турында сөйли. Һәм, киресенчә, уникаль фонетик уртаклыклар системмасы хәзерге көндә ареал аралары ерак булган телләрдә сөйләшүчеләрнең кайчандыр озак заманнар бергә яшәүләре турында гуаһлык бирә. Мәсәлән, татар һәм башкорт телләре арасында кайбер кискен фонетик аермалар бар икән, бу халыкларның кайбер борынгы элгәрләре бер-берсеннән ерак яшәгәннәр дип әйтеп була[13]. Татар теленең фонетик төзелеше вә морфологиясе белән кумык теленең фонетик төзелеше вә морфологиясе арасындагы зур охшашлыклар бу телләрдә сөйләшүчеләр кайчандыр бергәрәк булганнар дигән нәтиҗәгә китерәләр һ.б.

[13] К. В.М.Жирмунский. Некоторые проблемы лингвистической географии//ВЯ, 1954, №4.



Күзәтүләрдән күренгәнчә, телара аваз аермалары һәм аваз күчешләре ике төрле була: а) позицион күчешләр, ягъни сүздәге аерым позицияләрдә пәйда була торган үзгәрешләр (мәсәлән, татарча *атлар* башкортча *аттар*, ягъни гомумтөрки күплек кушымчасы *–лар ат* сүзенә ялганганда татар телендә үзгәрми, ә башкорт телендә исә үзгәрә, *-тар* булып яңгырый); б) тотальь күчешләр, ягъни бернинди позициягә, торышка карамастан бер телдәге бер авазга икенче телдә икенче аваз туры килү (мәсәлән, татарча *-ч-* авазы урынына гомумтөрки һәм гомумкыпчак сүзләрендә башкорт телендә һәрвакыт *-с-* авазы килә). Бер телдәге сүзләрдә, аффиксларда бер авазның икенче телдәге шул ук сүзләрдә, аффиксларда һәрвакыт икенче бер аваз илә алмашынуына **фонетик субституция** дип тә атыйлар.

Позицион һәм тотальь аваз күчешләрен аерым белү тел тарихы һәм халыклар тарихы зур әһәмияткә ия. Шуңа күрә бу мәсьәләгә аерым тукталырга кирәк.

§8. Философиядән билгеле ки, һәр үзгәреш вә үсешнең этәргече – эчке каршылык. Аваз үзгәрешләренә этәргеч булып «экономия принцибы» белән «коммуникатив функцияне башкаралучанлык» принцибы арасындагы диалектик каршылык хезмәт итә[14].

Сүзләрне әйткән чакта авазларны экономияләү (Г.Алпаров тәгъбиренчә «тел ялкаулыгы») нәтиҗәсе буларак телдә **редукция** – авазлар төшеп калу күренеше күзәтелә. Мәсәлән, татар телендә *авыру>ауру, аерылу>айрылу, арылы-биреле>арлы-бирле, ултыру>утыру* һ.б.ш. Икенче бер төрле кыскару – сүз тезмәсенең кыскарып бер сүзгә әверелүе (мәсәлән, *алып килү>апкилү, бара алу>баралу, күрә алмау>күрәлмәү, сары ат>сарат* һ.б.) гаплология дип атала. Мондый очраклар аңарчы булмаган аваз чатлашуларына, аннары морфологик үзгәрешләргә (мәсәлән, кабаттаркалышка, к. §62) китереп, бик ешайган, күбәйгән очракта, «сан сыйфатка күчеп» бөтен морфологик, хәтта фонетик системаны үзгәртергә мөмкин[15]. Мәсәлән *турур* «торыр» ярдәмче фигыль формасының *-тур>-ту>-т>0* (ноль) булып кыскаруы аерым төрки телләрнең грамматик структурасына сизерлек үзгәреш керткән[16].

Экономикадагы шикелле, телдә дә кыйммәтнең зурлыгы шул кыйммәтне булдыруга киткән хезмәт күләме белән үлчәнә, билгеләнә. Телнең иң абстракт элементлары аларны үзләштерү өчен иң күп фикри хез-

[14] К. А.Мартине. Принцип экономии в фонетических изменениях. М., 1960.
[15] Е.Д.Поливанов. Статьи по общему языкознанию. М., 1968. С.72.
[16] К. А.Н.Кононов. Семантика и функции связки –turur>-turu>tur>-tu>-t. СТ («Советская тюркология» журналы моннан соң шулай аталачак) 1980, №5, с.3-19. Р.Г.Ахметьянов. Лексика говора мордвы-каратаев в сравнительном освещении//Мордва-каратаи: язык и фольклор. Казань, 1991. С. 52-53.

мәт таләп итәләр һәм шулар иң зур кыйммәткә ия. Кыйммәт никадәр зур булса, аны алмаштыру – ваклау да шулкадәр кыенрак. Телдә иң абстракт элементлар – фонемалар, фонетик һәм грамматик система. Һәм шул системалар һәртөрле үзгәрешләргә иң зур каршылык күрсәтә дә.

Тел системасы беришле түгел – аның югары һәм түбәнге структур катламнары була. Һәм түбәнрәк, арзанрак булган катламнарны үзгәртеп кору җиңелрәк. Гомумән исә система торгын, структура үзгәрүчән[17].

Әйтелгәннәр телдә күзәтелгән түбәндәге закончалыкларны аңлаешлы итәләр:

1) телдә спонтан үсеш (үзеннән-үзе алгару) нәтиҗәсендә килеп чыккан үзгәрешләр, структур үзгәрешләр буларак, фонетик системаны тулаем үзгәртмиләр; бигрәк тә фонемалар составы даими булып калучан;

2) спонтан эчке үзгәрешләр процессында яңа фонема килеп чыгу ихтималы гомумән бик аз.

Фонемалар составын үзгәртүнең кыенлыгы тышкы субституция ягъни читтән, бүтән телдән сүзләр алганда ул сүзләрдәге ят авазларны туган телдәге авазлар яисә аваз компонентлары белән алмаштыруда күренә (мәсәлән, татар халык телендә булмаган «о» авазы рус алынмалары *у*-га әверелсә, татарга ят «*в*» авазы *б*-га әверелдерелеп килде, һәм *вор>бур, вагон>багун* кебек сүзләр кулланылды). Һәрбер тел чикләнгән сандыгы фонемалар – «үз» фонемалары белән генә эш итәргә тырыша[18]. Күрше телләрнең бик көчле тәэсиренә бирелмәгән аерым телдә яңа фонемаларның «үз-үзеннән» килеп чыгуы мөмкин түгел диярлек (яңа фонемалар килеп чыгуны төрле диалектлар буталып, яңа тел оешкан мәлдә генә күзәфәләп була). Бертелле кешенең аңында аңарга таныш фонемалар универсаль, һәр телдә дә шулар гына бар кебек тоела.

Югарыда без телдә са́нча үзгәрешләр сыйфа́тча үзгәрешкә китерәләр дидек. Ләкин бу үзгәреш нәтиҗәсе булган сыйфат билгеле кимәлдән күтәрелми: санча үзгәреш нәтиҗәсе булган сыйфат телдә инде күптән билгеле сыйфат була. Мәсәлән, кыргыз телендә гомумкыпчакча «aw» чатлашмасы *о*-га әверелә (гомумтөрки *бawыр*>кыргыз. *боор* «бавыр»). Ләкин бит *о* авазы кыргыз телендә электән билгеле – ул гомумтөркилек заманнарыннан калган. Шулай итеп, бу процессларда кыргыз телендә бернинди дә яңа фонема килеп чыкмаган.

Әйтелгәннәрдән шундый мөһим нәтиҗә ясарга мөмкин: телдәге позицион үзгәрешләрнең (позицион аваз көчешләренең һ.б.) төп сәбәбе – телнең үз эчендәге спонтан үсеш, алгарыш, әмма тоталь аваз

[17] Ю.В.Сачков. Введение в вероятностный мир. 1971. С. 50-136.
[18] П.Блумфилд. Язык. М., 1968. С.389-391.



күчешләренең төп (яисә бердәнбер) сәбәбе – тышкы йогынтылар, бүтән телләр (бигрәк тә субстрат) тәэсире була.

Позицион һәм тоталь күчешләр (үзгәрешләр) тел алгарышы процессында, әлбәттә, үзара үрелеп, тәэсирләшеп баралар[19]. Шуңа күрә һәрбер җитди фонетик үзгәреш ике яктан: телнең эчке үсешендә килеп чыккан таләп, хаҗәт һәм конкрет үзгәрешне мөмкин иткән этнолингвистик (тарихи) вакыйгалар ягыннан аңлатылырга тиеш.

§9. Хәзерге көндәге (синхрон кисемдәге) фонетик һәм морфологик система картинасы тел үсешендәге бик төрле һәм катлаулы процесслар суммасы, нәтиҗәсе вә йомгагы ул. Ләкин бу йомгакны принципта сүтеп, тел тарихын һәм шул телдә сөйләшүче халык тарихын билгеле дәрәҗәдә тәнәйтеп була. Күзәтелгән фонетик үзгәрешләрнең (аваз күчешләренең) һәркайсы берничә баскычлы үсеш нәтиҗәсе булырга һәм ул баскычлырның һәрберсе билгеле бер урында, билгеле бер чорда гына була алырга мөмкин. Ул урын вә чорларны билгеләп була. Һәм һәрбер фонетик үзгәреш баскычын тикшергәндә ике нәрсәгә – беренчедән, теге яки бу үзгәрешнең гомумән мөмкин булуына, икенчедән, шул үзгәрешнең пәйда булуына этәргән конкрет сәбәпкә игътибар итү фарыз[20].

***

Тарихи фонетиканың кайбер хосуси методик алымнары аерым конкрет мәсьәләләрне тикшергәндә каралачак. Чөнки ул алымнар күләмле, колачлы мисаллар китергәндә генә аңлашылачак.

***

Тел тарихы курсы гадәттә фонетикадан башланып, синтаксис һәм стиластика белән тәмамлана. Кайберәүләр төрки телләрдә, киресенчә, синтаксистан башларга кирәк, дип карасалар да, без алай итү өчен җитәрлек нигезләр тапмадык.

## ИКЕНЧЕ БАБ. СИНХРОНИК МАНЗАРА

§10. Бүгенге көндә үзара аңлаешлы булган татар һәм башкорт телләре Евразиядә киң таралган төрки телләр семьялыгына керәләр. Бу семьялыкка алардан башка тагы кырымтатар, нугай, кумык, карачай-балкар, караим, кыргыз, казах, алтай, хакас, тува, уйгур, үзбәк, төрекмән, азәри (әзербайҗан), төрке, гагауз, чуваш вә якут телләре һәм

[19] В.А.Серебренников. Вероятностные обоснования в компаративистике. М., 1974. С.30.
[20] к. Н.А.Баскаков. Принципы разработки исторической грамматики младописьменных тюркских языков. СТ, №6, 1990, С. 52-53.

үз язуы булмаган кайбер бүтән телләр – Кытайдагы сары уйгур, Ирандагы кашкай, халаҗ, афшар телләре һ.б. керә. Язма ядкәрлекләре буенча гына билгеле булган үле телләрдән мәзкүр семьялыкка урхун, болгар, чыгтай һәм әрмән*кыпчак телләре карый.

Төрки телләр җөмләсе бүтән телләрдән бик ачык аерылып тора: күп санлы фонетик һәм морфологик уртаклыклар, грамматик система-ның бердәйлеге, төп лексик байлыкның тамырдашлыгы, ниһаять, бу телләрдә сөйләшүче халыкларның мифология, йола вә фольклорындагы уртаклыклар һ.б төрки телләрнең бер төптән, бер нигездән таралган-лыгына какшагысыз дәлил булып торалар[21].

§11. Фонетик уртаклыкларга түбәндәгеләр керә:

а) Төрки телләрдә иҗек калыплары (С – сузыклар, Т – тартыклар дип алсак) түбәндегеләр: С, СТ, ТС, ТСТ, ТСТТ; ягъни иҗекләр ике, өч һ.б. тартык кушымына башлана алмый; әмма иҗек азагында ике тартык кушымы килергә мөмкин (мисаллар: *у-мак, а-га, ат, ба-ба, сан, карт*). Төп төрки-татарча иҗек азагында ике тартык килсә, аларның соңгысы –т авазы була: *ант, арт, аст, выжт, келт* һ.б. Башкортча шундый очракта –к да киләлә: *к алк -, к урк -, һарк .*[22]

б) Сузыклаар нигездә калын вә нечкә (арткы рәт һәм алгы рәт) авазлары бүленеп, алар парлашкан хәлдә кулланыла ягъни һәр калын сузыкның үзенә охшаш нечкә варинат була; бу хәл сингармонизм дип аталган ошбу күренеш белән баглы: барча кушымчалар ике вариантта – калын вә нечкә вариантларда кулланылып, соңгы иҗеге калык сузыклы булган тамыр һәм нигезләргә калын сузыклы вариант кушымчалар, соңгы иҗеге нечкә сузыклы булган тамыр һәм нигезләргә нечкә вариант кушымчалар кушыла. Сингармонизм сөйләм агымында сүзне аеру чарасы булып тора.

в) Басым сүзне сүздән (нигезне нигездән) аеру өчен кулланылмый. Ләкин сүз тамырын аеру билгесе булырга мөмкин (мәсәлән, *Алмагач-ның алмасы́н, Карга-козгын а́лмасын,* дигәндә соңгы *а́лмасын*да беренче иҗектәге басым сүз тамырын күрсәтә).

**Грамматик система өлкәсендә төрки** телләргә түбәндәге төп уртак үзенчәлекләр хас:

а) Сүзләр җенес классларына бүленми һәм төрләнештә җенес категориясе юк.

б) Сүз нигезләренең кайсы сүз төркеменә каравын күрсәткән билге-ләре юк. Әмма сузыкка беткән нигезләр төрләнеше һәм тартыкка беткән

[21] Төрки телләрнең уртак сыйфатлары Н.А.Баскаков хезмәтләрендә шактый ачык күрсәтелә, мәс. Н.А.Баскаков. Тюркские языки (Введение). М., 1966. С. 7-42.

[22] Хәер, әдәби телдә бар булган очраклар нибары дүрт-биш мисал белән чикләнә бугай, к. М.Х.Әхтәмов. Башкорт теленең морфологик сүзлеге. Өфө, 1992: 177, 179, 206.



нигезләр төрләнеше бар (тик бу аерма да күпчелек очракларда белендерелми).

Уртак тамыр һәм нигезләрнең сингармоник рәт һәм төрләнеш классларына бүленеше барлык төрки телләрдә күпчелек очракларда бердәй. Әйтик, татар телендә

| | | бетеме | |
| --- | --- | --- | --- |
| | | тартыкка | сузыкка |
| соңгы сузыгы | арткы рәт<br>алгы рәт | *баш; бул-*<br>*бил; кер-* | *ага; тара-*<br>*тәкә; үтә-* |

Тарихи җәһәттән бердәй исем һәм фигыльләр барлык төрки телләрдә дә нәкъ бер үк графаларга керәләр. Мәсәлән, гомумтөрки сүз – *баш* (үзбәкчә *бош,* казахча *бас,* чувашча *пуҫ,* кайбер Себер телләрендә *пас, паш*), һәр телдә дә тамыр сузыгы арткы рәтнеке (калын) булып, һәрвакыт тартык авазга бетә; аңа 3-зат тартым кушымчасы *–ы* кушыла; *ага* сүзенә гел 3-зат тартым кушымчасы *–сы* (чуваш телендә аның бик нык үзгәргән варианты *–и*) ялгана. *Кер- (кермәк)* фигыле (бүтән төрки телләрдә *кир-,* угыз телләрендә *гир-,* чувашча һәм хакасча, татар телендәге кебек, *-кер*) барлык төрк ителләрдә дә алгы рәт тамыр сузыклы һәм кушыла торган барлык кушымчалар да алгы рәт сузыклы булырга тиешләр (*кер-ә-ләр, кер-т-ел-гән-нәр, кер-ү-че* һ.б.).

Бу гомумтөрки схема күп кенә телләрдә, шу хисаптан башкорт һәм татар телендә, саңгырау тартыкка беткән тамыр һәм нигезләргә кушымчаларның саңгырау тартыкка беткән кушымчалары ялганырга тиешлек кагыйдәсе белән (мәсәлән, *һавада, карда,* ләкин *кошта*) катлаулана.

в) Сүзнең ясалышында һәм төрләнешендә агглютинация ягъни ялганмалык ысулы кулланыла. Бу – кушымчалар тамырга яки нигезгә билгеле чират белән бер-бер артлы ялганалар, дигән сүз.

Сүз төрләнеше парадигмасында сүз нигезе принципта үзгәрми, кушымчалар исә нигезгә җайланып, үзгәрәләр ягъни тиешле фонетик вариантларда яшиләр һәм нигез шулардан «үзенә кирәген сайлап ала».

Төрләнештә сүз нигезләре дә үзгәрү – фузия – агглютинациягә каршы куела һәм һинд-европа телләрендә күзәтелә.

Фузия күренеше тарихи үсеш процессында төрки телләрдә дә, мә-сәлән, татар телендә (хәзерге заман фигыль формаларында) һәм, бигрәк тә чуваш телендә еш кына очрый. Ләкин мондый күренешләр икенчел характерда һәм аларның ничек итеп чыкканлыгы да күренеп тора.

г) Барлык төрки теләргә төрләнештә сан, зат, килеш, заман, хәбәр-лек категорияләре белән бергә тартым тартым категориясе һәм тартымлы төрләнеш формалары хас.

Тартым категориясе кемгә-нәрсәгә тиешлекне, «кемнекелекне» генә түгел, билгелелекне һ.б.ш. функцияләрдә дә кулланыла.

Төрки телләрнең барсына да уртак булган үзенчәлекләрнең тагын күпкенәсен күрсәтергә мөмкин (к. мәсәлән, Н.А.Баскаковның «Языки народов СССР» сериясендәге «Тюркские языки» томына (М. 1966) кереш сүзен: анда төрки телләрдә җенес категориясе юклык, сыйфатлар-ның тышкы аергыч билгеләре булмау һ.б.ш. әйтелгән). Ләкин хәлиткеч үзенчәлекләр – бирелә язылганнары.

Грамматик хасиятләре буенча татар теле төрки телләрнең уртак эталонына бик якын тора. Башкорт теле дә шул эталонга якын, әмма бу телдә, аның тарихи үсешендә күп кенә инновацияләр (яңа күренешләр) пәйда булган. Шул ук вакытта башкорт телендә бүтән төрки телләрдә сакланмаган борынгылыклар да булырга тиеш.

Инновациядәр күплеге ягыннан төрки телләр арасында чуваш теле беренче урында тора. Шул ук вакытта нәкъ менә чуваш телендә бүтән беркайда да (һәрхәлдә тере телләрнең берсендә дә) булмаган борынгы элементлар сакланып калган. Ләкин бу очраклы күренеш: инновацияләр күп булган телдә борынгылыклар – «бакый»лар да күп булырга тиеш дигән закончалык юк.

Лексика өлкәсендә тирәннәнге кардәшлек тарих дәвамында үзгәрми торган нәрсәләрнең һәм эш-хәрәкәтләрнең атамаларын (шулай аталмыш Сводош исемлеге) чагыштыруда сынала. Шул сыналыш буенча (аны Америка галиме А.Раун ясаган[23] һәм татар галимнәре Т.Гарипов белән Ф.Фәсиев тикшереп карады) лексика өлкәсендә төрки телләр арасындагы кардәшлек түбәндәге цифрлар белән тәгъбирләнә.

| | төрек | татар | башк. | үзбәк | тува | төрекмән | чув. |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| төрек | – | 68 | 69 | 71 | 60 | 65 | 66 |
| татар | 68 | – | 89 | 78 | 67 | 70 | 69 |
| башк. | 69 | 89 | – | 76 | 65 | 61 | 66 |
| үзб. | 71 | 78 | 76 | – | 61 | 76 | 65 |
| тува | 60 | 67 | 65 | 61 | – | 69 | 56 |
| төрекмән | 65 | 70 | 61 | 76 | 61 | – | 58 |
| чув. | 66 | 62 | 66 | 65 | 56 | 58 | – |
| Суммалары | 406 | 437 | 426 | 427 | 370 | 391 | 373 |

Һәрбер тел буенча индекслар суммасы тегә яки бу телнең уртак төрки телгә (эталон телгә) лексик якынлык дәрәҗәсен билгели. Һәм менә татар теле ул үзәк телгә иң якыны булып чыга – иң зур сумма (437) аныкы. Бу цифрның реаль әхвәлне чагылдыруы шуннан күренә: чыннан да бүтән төрки телләрдән нык аерылып торган тува һәм чуваш телләренең лексик

[23] Raun A. Über sogenannte lexikostatistische Methode oder Glottochronologie und ihre Anwendung auf des Fnnisch-ugrische und Türkische. Uralo-altaische Jahrbuch, B. XXVIII, Hefte 3-4.



индекслары иң аз суммага (370 һәм 373) ия. Димәк, бу саннар лексик уртаклыкны гына түгел, фонетик һәм морфологик уртаклыкларны да чагылдыралар.

Татар теленең төрки телләр арасында урта позициядә торуы XIX гасырда һәм XX гасыр башларында төрки телләрне төрек-татар телләре дип (финн-угор, һинд-европа сүзләре үрнәгендә) йөртелүенә сәбәп булган.

Таблицада татар һәм башкорт телләренең уртаклык индексы 89 дип күрсәтелгән. Әмма икенче бер мәгълүматларга караганда ул 96%-ка тиң. Алай булганда татар теленең уртаклыгы тагын да калкурак булып күренә (әлеге сумма – 444 була).

§12. Әйтелгән һәм кайбер бүтән систем уртаклыклар белән бер төрки телләр вә диалектлар арасында күп кенә структур аермалыклар да яшәп килә. Бу аермалар фонетик өлкәсендә фонемаларның саны вә сыйфаты, морфологик үзенчәлекләр һәм тоталь аваз тәңгәллекләре буенча күзәтелә.

Аермалар, гомумән, күптөрле, күпъяклы. Ләкин (бигрәк тә морфология өлкәсендә) конкрет төрки элементларның саны чикләнгән. Һәрбер төрки тел бүтәннәрдән билгеле элементларның үзенчәлекле, шул телгә генә хас чатлашмасы буларак аерылып тора. Мөмкин булган чатлашмалар (әгәр әлеге элементлар исәбенә лексиканы да кертсәк) исәпсез күп. Хәзерге төрки телләр булып үткән, элекке һәм борынгы төрки телләрнең аерым концентратлар булып формалашкан ватыкларыннан гыйбарәт, дип әйтеп була. Бу шартларда төрки телләрне классификацияләп күрсәтү бик кыенга калыр иде. Ләкин, бәхеткә каршы, төрки телләрне (һәм өлешчә монгол телләрен дә) «уртак ваклаучыга» китерә торган бер фонетик билге бар – ул сүз башындагы парлы җ-ч (з-с) авазлары (яңгырау җ авазы һәм аның саңгырау пардашы). Инәкә (прото) төрки телдә бу авазлар урынына йоталанган һәм йоталанмаган авазлар булган булса кирәк. Шуннан, төрки телләр тармаклану белән, бу авазларның рефлекслары да тармакланган:




[24] Сүз яисә хәрефнең сул ягындагы * билгесе фонетик закончалыклар буенча тәнәйтелгәнлекне белдерә

[25] җ-ч парның борынгы элгәрле мәсьәләсе бик бәхесле, к. Н.З.Гаджиева, Б.А.Серебренников. Был ли начальный j в тюркских языках первичным?/СТ, №3, 1974, с.

Телләр «болгатылу» һәм яңадан формалашу процессларында кайбер телләрдә торынгы т' (t')-нең рефлексларының икесе-өчесе кулланылу яисә бергә кушылуна кадәр барып җитсә дә, гомумән һәр телдә (диалектта) ул рефлексларның тик бер төрлесе (йә *җ*-, йә *й*- һ.б.) ныгып кала алган.

Шул рефлекслар бигүк «буталмаган» телләр һәм диалектлар түбәндәге таблицага урнашып классификацияләнәләр (к. түбәндә).

Бер үк тамырлар составындагы *ẓ(җ)* һәм *č (ч)* авазларның төрки һәм монгол телләрендә чагылыш таблицасы

| ẓ / č | –ž (ж) | dẓ, ẓ (дж, җ) | dz, z (дз, з) | j (й) | d', t' (дй, тй) | č (ч) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| š (ш) | казах. кара-калп. | | | нугай | | тува |
| ç (ч) | | караим. (Тракай), Казан арты (тат.), кыргыз, «классик» монг. | | кумык, татар, кырым-татар., угыз вә карлук-уйгур | алтай, мишәр сөйләш-ләре | хакас, алтай диалект-лары |
| c (ц) | | карачай | караим (Галицк), балкар, мишәр (төньяк), халха-монг. | Себер диалекты | | |
| s (с) | | якут | бурят. | башкорт | | сагай (хакас диал.) |
| s' (сч) | | чуваш | | | | |

Чуваш һәм якут телләрендә җ һәм ч авазларының рефлекслары еш кына бер аваз (чувашча *ç-сч*, якутча *с*) булып китә.

*Җ-ч (ẓ-č)* рефлексларыннан тыш төрки теләрне аерым группаларга аера торган тагын берничә фонетик билге бар.

75-32/. А.М.Щербак. Еще раз к вопросу о реконструкции тюркского архетипа анлаутның j-, ẓ-, z-, ŝ-, č-, s./СТ. 1974, №4, с. 80-84. Без биредә үзебезнең концепцияне үткәрәбез – Ә.Р.



§13. Беренче мөһим аергыч билге – *γ, g ~ w, j, q, k*.

Кайбер (бигрәк тә борынгы) язма һәм җанлы төрки телләрддә ижек азагында (сүз азагында) *-γ* һәм *–g* авазлары булала (мәсәлән, руник язмаларда *quruγ* «коры», *sevig* «сөекле; сөю», *taryγ* «ашлык-тару»), икенче бер төркем телләрдә исә *-γ* һәм *–g* авазлары һичничектә ижек яисә сүз азагында киләлми: алар урынына йә *–w, -j (-й), -q(-қ ), k(-к)* авазлары килә, йә ул *-γ* һәм *-g* эзсез төшеп кала. Соңгы төркем телләргә барлык кыпчак телләре, шул хисаптан татар һәм башкорт телләре дә керә. Мәсәлән:

| Борынгы төрки | Татарча һәм башкортча |
|---|---|
| *aγ* | *ау* |
| *aγlan* | *аклан, алан* |
| *atlyγ* | *атлы (исемле)* |
| *baγ* | *бай, бәй* |
| *bilig* | *белу, белек* |
| *isig, issig* | *эссе* |
| *ölüg* | *үле, үлек* һ.б.ш. |

Шул ук вакытта бу телләрдә интервокаль (ике сызык арасындагы) *-q-* һәм *-k- (-қ-* һәм *–к-)* авазлары *-γ-* һәм *-g-* (*-ғ-* һәм *-г-*) авазларына, ә шул позициядәге -γ- һәм *-g-* (*-ғ-* һәм *-г-*) *-w-* авазына күчә ягъни биредә **эшелонлы күчеш** күзәтелә:

*-q->-γ-//-γ->-w-*

*-k->-g-//-g->-w-*

Мәсәлән, борынгы төрки *taqy* > татарча *тагы*, ләкин борынгы төрки taγy> татарча *тавы* һ.б.

Ләкин бу күчешләр тоталь һәм регуляр (бүртөрле генә) характерда түгел.

§14. Икенче мөһим аергыч билге *-q->-γ-, -k->-g-, t->d-* ягъни бер төркем телләрдә борынгы сүз башындагы *q, g, t* авазлары яңгыраулаша, мәсәлән:

| Төрекмән, әзәрбайҗан, төрек | Борынгы төрки | Татар, башкорт телләрендә |
|---|---|---|
| *гара* | *qara* | *кара* |
| *гүн* | *kün* | *көн* |
| *дал* | *tal* | *тал* |
| *дил* | *til* | *тел* һ.б. |

Бу күренешләрнең югарыда әйтелгән интервокаль *-q-* һәм *-k-* авазларының *-γ-* һәм *-g-* авазларына күчеше белән бер багланышы да юк.

Сүз башында гомумтөрки *q-, k-* һәм *t-* урынына *γ-, g-* һәм *d-* авазлары күпләп күзәтелгән телләр угыз телләре дип аталалар. Бу төркем телләргә тагын кайбер морфологик һәм лексик үзенчәлекләр дә хас.

Шунысы кызыклы ки, уртак сүзләрдә гомумтөрки *q-, k-* һәм *t-* урынына сүз башында *γ-, g-* һәм *d-* куллану монгол телләрендә дә күзәтелә.

§15. Өченче аергыч билге – ассимиляция вә диссимиляция үсешкәнлеге. Якутиядән алып Әстерхан далаларына чаклы параллельләр буйлап сузылган бер төркем телләрдә тамыр вә нигезләргә кушымчалар кушылганда бик еш кына төрле ассимиляция (тамыр яисә нигезнең соңгы авазына кушымчаның тәүге авазы охшашлану) һәм диссимиляция (кушымчаның тәүге авазы тамыр яисә нигезнең соңгы авазы белән төп вариантта бердәй булса, «махсус рәвештә» үзгәртелү) күзәтелә. Бу телләрдә *атлар* урынына *аттар* диелә, әмма *таллы* диясе урында *талды* диләр һ.б. һәм бу күренеш регуляр кагыйдәләргә буйсына.

Бу саф позицион үзгәрешләр башлыча кыпчак төрки телләрендә күзәтелә. Ләкин алар алтай, тува һәм якут телләренә дә хас (соңгы ике тел исә угыз телләренә якын).

§16. Бу гомумтөрки аергыч билгеләрдән тыш, аерым төрки телләр региональ фонетик үзенчәлекләргә ия, ягъни бер тирәдә, бер географик өлкәдә таралган төрки телләр төрле чагылыштагы уртак фонетик билгеләр буенча берләштерелә алалар.

Шундый региональ үзенчәлекләрнең берсе – татар, башкорт һәм чуваш телләренгә хас булган яңа вокализм системасы (к. §21-23). Бу система төрки телләрдән тыш күрше мари телендә дә чагылыш таба.

Урта Идел-Урал төрки вокализм системасының килеп чыгышы аз өйрәнелгән, күп яклардан табышмаклы күренеш. Ләкин шунсы ачык – бу система мәзкүр регионлагы телләрнең озак гасырлар дәвамында үзара тәэсирләшү нәтиҗәсе ул.

Төрки телләр региональ фонетик үзенчәлекләре (һәм һәрвакыт аларга өстәлә килгән лексик вә морфологик уртаклыклар) буенча түбәндәге регионнарга – лингвистик өлкәләргә бүленә ала: а) якут ареалы – якут (саха) һәм долган телләре; б) Алтай-Саян регионы – алтай-хакас, шор һәм чулым телләре; в) Тува регионы – тува теле һәм аңа якын диалектлар; г) Урта Азия регионы – уйгур һәм үзбәк телләре; д) Көнчыгыш кыпчак телләре регионы (Казахстан, Кыргызстан, Каракалпакстан); е) Идел-Урал регионы; ж) Төньяк Кавказ һәм Кырым регионы; з) Төрекмән регионы – төрекмән теле һәм аңа якын телләр; и) Көнбатыш регион – әзәрбайҗан, төрек һәм гагауз телләре.

Әйтелгән беренчел – төп һәм икенчел – региональ аергыч билгеләрдән башка тагын бер серле – гаҗәеп аергыч билге – төрки телләрнең бер тарихи группасында гомумтөрки *z(з)* һәм *š(ш)* авазлары



урынына *r(p)* һәм *l(л)* авазлары кулланылу күзәтелә. Тере төрки телләрдән бу *r* һәм *l* группасына чуваш теле генә керә. Әмма күп кенә эпиграфик мәгълүматлар һәм монгол вә тунгус-маньчжур телләрендәге кайбер сүзләр шул группаның борынгы заманнарда шактый киң таралганлыгын күрсәтә (к. §49).

Диахроник фонетика өлешендә барлык бу аергыч билгеләре – фонетик тәңгәллекләр вә күчешләр турында махсус сөйләнелер. Элгәртеннән шуны гына әйтергә кирәк: региональ үзенчәлекләр уртаклыклар, һичшиксез, яңарак, ә төп өч аергыч тәңгәллекләре исә арада иң борынгылары булса кирәк.

Мәзкүр гомумтөрки өч аергыч билге, әйтелгәннәрдән күренгәнчә, кайбер очракларда бер-берсе белән кисешәләр-чатлашалар; аларга тагы локаль фонетик үзенчәлекләр өстәлә:




Әстәвенә төрки телләр (бигрәк тә әдәби-язма телләр) бер-берсенә тәэсир итешеп, бер-берсеннән грамматик формантлар, сүзләр һ.б үзләштергәннәр. Нәтиҗәдә, әйтик, кыпчак яңгырашлары угыз телләренә, угыз яңгырашлары кыпчак телләренә үтеп кергән. Мәсәлән, үзендә гомумән гомумтөрки анлаут *t* – хөкем сергән татар телендә байтак сүзләр угыз телләрендәгечә *d* – авазына башлана (*давыл, дүрт, дисбе* һ.б.).

Мондый үзара чатлашулар һәм алынмалар гомуми картинаны тагын да чуарлыйлар. Шуның өчен төрки телләрнең бер өлеше генә азмы-күпме каршылыксыз булган классификациягә керә. Ул классификация түбәндәге таблицада бирелә (к. 28 бит).

Бу таблицага карап андагы һәрбер телне шактый төгәл характерлап һәм билгеләп була. Мәсәлән: ассимиляция вә диссимиляция аз үсешкән кыпчак төрки теле, бу телдә *җ-ч* пары *ж-ш* рәвешендә чагыла, ул кайсы тел була? – дисәк, аның каракалпак беле булуын әйтү кыен түгел.

Ләкин, әйткәнебезчә, бу таблицага чуваш теле, аннары Себер төркиләренең тел вә диалектлары (алтай, хакас, тува, шор, якут һ.б.) керми, сыешмый, чөнки алар тарих дәвамында бик болгатылган, *җ-ч* парының рефлекслары бик буталган телләр.

Таблицага кергән телләр дә, әлбәттә, һәрберсе беришле генә түгел: аларның шивәләре, диалектлары, сөйләшләре бар һәм шуларда гомуми кагыйдә-закончалыклардан читкә чыккан очраклар да булгалый. Алар локаль күренешләр дип атала.

**Үзәк төрки телләрнең классификацион таблицасы**

<table>
<tr><td rowspan="3">Позицион фонетик билгеләр<br><br>ẓ - č пары-ның тоталь субститутла-ры (чагылыш-лыры)</td><td colspan="2">Кыпчак телләре: иҗек азагында борынгы -γ, -g урынына w, j, q, k килә: jaγ урынына jaw, saγ урынына saw һәм saq h.б.</td><td colspan="2">ауслаутта бор. -γ, -g саклана: baγla-, beg, tag</td></tr>
<tr><td colspan="3">Сүз башында төп төрки сүзләрдәге тартыклар сангырау, ләкин мәгън» аеру өчен яңгыраулар кулланыла: ti- һәм di-, täw һәм däw h.б.</td><td>Гомумтөрки сүз башында k-, q-, t- урынын-да g-, γ-, d-</td></tr>
<tr><td>Ассимиляция, диссимиляция процесслары көчле үсеш алган телләр</td><td colspan="3">Ассимиляция, диссимиляция процесслары зәгыйфь</td></tr>
<tr><td>ẓ - č</td><td>кыргыз</td><td>Казан диалекты (урта диалект), үзбәк теленең кыпчак диалекты</td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>ẓ вә j – č</td><td></td><td>Гомумхалык татар теле; кумык теле</td><td>Төрки тел, уйгур, үзбәк әдәби телләре</td><td>Угыз төрки телләре</td></tr>
<tr><td>j – č</td><td></td><td>Көньяк мишәр сөйләшләре</td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>j – c (ц)</td><td></td><td>Төньяк мишәр сөйләшләре, Себер татар һәм караим диалектлары</td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>ẓ – c (ц)</td><td>Кыргыз сөйләшләре</td><td>Карачай-балкар һәм караим сөйләшләре</td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>j – s</td><td>Башкорт</td><td>Көньяк башкорт диалекты</td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>j – š</td><td></td><td>Нугай</td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>ж(ž) – š</td><td>Казах</td><td>Каракалпак</td><td></td><td></td></tr>
</table>

Менә бу хәлләр хәзерге, синхроник манзараны тагын да чуарлаталар.



§17. Шулай итеп, төрки телләрне бер-берсеннән аерырга мөмкинлек бирә торган аергыч – дифференциаль билгеләр (к. §16) *иң борынгы, урта* һәм *чагыштырмача соңгы* диелеп, өч төрлегә бүленә алалар. **Иң борынгысына** *r* һәм *l* ~ *z* һәм *š* тәңгәллеге, **урта билгеләргә** өч төп аерма (гадиләштереп алганда: *a/w* авазы булу-булмау һәм иҗек азагында -*γ*//-*g* килә алу – килә алмау; б) *q, k* һәм *t* авазларының сүз башында яңгыраулашу-яңгыраулашмавы; в) ассимиляция һәм диссимиляция күренешләренең үсешкәнлеге-үсешмәгәнлеге), **чагыштырмача соңгы** аергыч билгеләргә региональ вә локаль үзенчәлекләр карый. Бу билгеләр өч яссылыкта, өч кимәлдә булганлыгыннан ук алар бер классификация нигезе була алмыйлар шикелле. Шулай да тюркологлар, төрле нигезләрне чатлаштырып булса да, төрки телләргә тулай классификация биреп караганнар.

Төрле классификацияләрдән элекке СССР илләрендә Н.А.Баскаков классификациясе популяр[26]. Бу классификация буенча төрки телләр башта икегә – көнбатыш хунн һәм көнчыгыш хунн тармакларына бүленә.

Көнбатыш хунн тармагына: 1) болгар, 2) угыз, 3) кыпчак һәм 4) карлук группалары, көнчыгыш хунн тармагына 1) кыргыз һәм 2) борынгы уйгур группалары карый.

Бу классификация саф лингвистик билгеләрне тарихи мәгълүматлар белән чатлаштырып ясалган субъектив нигезгә корылган һәм кайбер очракларда буталчыклык китерә. Мәсәлән, хәзергә уйгур вә үзбәк телләре карлук группасын тәшкил итәләр һәм көнбатыш хунн тармагына карыйлар, әмма борынгы уйгур теле бөтенләй икенче тармакка кертелә. Әгәр ул борынгы тел хәзерге уйгур теленнән нык аерыла икән, нигә аны уйгур этнонимын кулланып исемләргә? Кыргыз һәм алтай телләре аерым группа итеп көнчыгыш хунн группасына куелганнар, ләкин кыргыз теле татар теленә күрше казах теленнән дә, алтай теленнән дә якынрак һәм гомумән бу телне кыпчак телләрененнән аеру кыен h.б.

Кыпчак группасында Н.А.Баскаков кыпчак-угыз, кыпчак-болгар (татар-башкорт) һәм кыпчак-нугай (нугай, казах, каракалпак) асгруппаларын аера. Монда бүленешнең үзе белән килешергә мөмкин, ләкин кыпчак-угыз сүзе урынына көнбатыш кыпчак телләре дип атау дөресрәк була. Ул чагында кыпчак-нугай асгруппасы **көнчыгыш кыпчак** асгруппасы дип, татар-башкорт асгруппасы исә **төньяк кыпчак** асгруппасы дип аталса уңайлырак кебек тоела.

Н.А.Баскаков классификациясендә борынгы һәм хәзерге төрки телләр берьюлы алынып, барсы бергә төре төргә аерыла. Нәкъ шул хәл

[26] Н.А.Баскаков. Введение ...

классификациясе катлауландыра һәм буталчыкландыра да. Борынгы һәм хәзерге төрки телләр классификациясен аерым-аерым карау хәерлерәк.

§18. Бер үк сүзне төрле фонетик вә язма кыяфәтләрдә, рәвешләрдә тану өчен телләр, диалектлар арасындагы фонетик тәңгәллек закончалыкларын (формулаларын) һәм төрле хәрефләр белән язу кагыйдәләрен (чөнки һәр хәреф системасы үз орфографиясен таләп итә) белергә кирәк.

Фонетик закончалыклар да, таныш булмаган орфография дә башта гади күзәтүләр нигезендә өйрәнелә һәм тора-бара махсус законнар, кагыйдәләр булып тәгъбирләнә, формалаштырыла.

Ике яңгыраш яки язылыштагы бер үк сүз арасында | ~ | (тирәле тильда) яисә ~ (тильда) гына куела (ләкин тильда төшерелеп калдырылган сүз урынына да куелырга мөмкин). Бу билге ике яңгыраштагы яки язылыштагы сүзнең төптә-асылда бер сүзгә кайтып калганлыгын белдерә. Мәсәлән, чувашча *ура* ~ татарча *аяк*.

Сүзнең, авазның тарихын өйрәнү нәтиҗәсендә чагыштырылган яңгырашларның кайсысы борынгырак, кайсысы соңрак булганлыгы беленсә, бер асылга кайтып калган сүзләр, формалар, авазлар арасында > билгесе куела: бу билгенең очлы ягы борынгысыннан яңасына (өлкәненнән кечәрәгенә) юнәлтелә, мәсәлән, борынгы төркичә *аϑак* |aϑaq| > татарча *аяк* |ajaq|.

Әгәр ике сүз, ике форма (яңгарыш), ике аваз өченче бер сүздән, яңгыраштан тармакланган булса, алар арасындагы мөнәсәбәт айры уклар белән белдерелә. Мәсәлән,

Борынгы aϑaq → *araq>*arax>*arah>чувашча ara>ura «аяк»
Борынгы aϑaq → ajaq – татарча ajaq «аяк»

Ике яңгыраш арасындагы арадаш формаларны язып тору кирәк булмаса, әмма арадаш формалар булганлыгы нкүрсәтү зарур булса, ике сүз, яңгыраш һ.б. арасында ике почмакча >> куела. Мәсәлән, борынгы aϑa >> чувашча *ура*.

Бер ук вакытта булган һәм үзара сәбәпле бәйләнештә торган аваз кучешләре арасында // (вертикаль параллель) билгесе куела (мәсәлән, к. §26).

Тәнәйтү асылда ошбу билгеләрне тиешенчә-кирәгенчә дөрес куеп, тел элементы яисә структур берәмлек үткән тарихи юлга маяклар беркетү дигән сүз.



## ӨЧЕНЧЕ БАБ. ҮСЕШ РЕКОНСТРУКЦИЯСЕ

§19. Нинди тел ул татар теле? Югарыда китерелгән таблица буенча моңа түбәндәгечә җавап бирергә мөмкин: татар теле ул кыпчак группасының төньяк асгруппасына караган һәм сүз башында *җ-ч* пары була алган, нигез белән кушымча җегендә ассимиляция вә диссимиляция процесслары көчле үсеш алмаган төрки тел. Татар телендә борынгы кыпчак консантизмы үзгәремсез саклана.

Башкорт тел исә болай билгеләнә: ул кыпчак группасының төньяк асгруппасына караган һәм үзендә *җ-ч* пары бөтенләй булмаган, сүз башында ичә ж-ч авазлары урынына *й-* һәм *с-* кулланылган, нигез белән кушымча җегендә ассимиляция һәм диссимиляция күренешләре көчле үсеш алган төрки тел. Башкорт теле гомумкыпчак консонантизмына *ҙ, ҫ* һәм *һ* авазлары өстәлү белән дә характерлана.

Тел тарихы билгеле бер телнең бүгенге характерлы, аны бүтән кардәш һәм күрше телләрдән аерып тора торган сыйфатлары ничек һәм кайчан килеп чыккан, нишләп ул башкалардан аерылган дигән сорауга җавап бирергә тиеш.

Шундый җавап әзерләү өчен исә телнең барча аерым элементлары моннан йөз, өч йөз, мең һ.б. еллар элек ни хәлдә, нинди кыяфәттә булганлыгын һәм, өстәвенә, аларның мәгънәсе, тулай системадагы урыны ничек булганлыгын тикшереп чыгу кирәк була. Бу бик күп белемнәр, мәгълүматлар һәм эффектив, дөрес методлар таләп итә торган эшкеремле эш. Бүгенгедән башлап вакыт тирәнлегенә төшәрәк, тел элементының төрле этап, стадияләрдәге яңгырашын һәм мәгънәсен белгәннән соң аның бөтен үзгәреш юлын күзәфәләп, билгеле булган иң борынгы яисә безгә кирәк дәрәҗәдә борынгы кыяфәте тәгъбирләнә. Менә шундый эш гомумән лингвистик тәнәйтү (реконструкция) дип атала да[27].

Тәнәйтү тел механизмының бүгенге торышын, тел системасындагы сәбәпле бәйләнешләрне, ни өчен шулай икәнлеген аныклап, бу торышның ничек килеп чыкканлыгын тикшерү, ошбу торышка китергән өлгәргә торыш вә әхвәлләрне белергә тырышу һәм билгеләү дигән сүз.

Шушы назардан, иң тәүләп татар теленең **морфонологиясен** карап чыгу зарур.

[27] Төрки реконструкция проблемалары турында. к. Е.З. Кажибеков. Проблемы реконструкции тюркского праязыка: пропедевтический ракурс. СТ 1987, №4. С. 3-22 (Шунда ук бик күп әдәбият күрсәтелә).

§20. Морфонология, кыскача гына билгеләгәндә, кушымчаларның сүз нигезенә (тамырына) кушылганда килеп чыккан фонетик күренешләр һәм шуларны өйрәнү диган сүз[28].

Татар морфонологиясе, тыгызлап характерлаганда, түбәндәге кагыйдәләр белән билгеләнә ала.

а) Татар телендә нигезләрнең гомумтөрки дүрт төргә бүленүе (калын-нечкә, сузыкка беткән-тартыкка беткән) саклана.

б) Сузыкка башланган кушымчалар бер генә пар була – алар барча нигезләргә бер төрле кушыла.

Ләкин бу очракта *–қ, –к* һәм *–п* авазларына беткән нигезләрнең азагы яңгыраулаша:

*–қ >–г, –к>–г, –п>–б* (сандхи күренеше).

в) Сузыкка, сонор тартыкка, шулай ук *-ғ-, -г* һәм *-з* авазларына беткән нигезләргә яңгырау тартыкка башланган кушымчалар, калган нигезләргә саңгырау тартыкка башланганнары ялгана (тартыкка башланган кушымчалар дүрт вариантта була).

г) Әмма *–с* һәм *–ч* авазына башланган кушымчаларның яңгырау пары юк (алар ике генә вариантта була).

д) Кушымча башындагы сонор авазлар, гомумән, үзгәрми. Тик нигез һәм кушымча җегендә *–м+–л–>–мн–, –н+–л–>нн, –ң+–л–>ңн* (ягъни *–л>–н*) һәм *–нд–>–нн–, –мд–>–мн* күренешләре күзәтелә.

ж) Алмашлык һәм йөкләтү юнәлеше кушымчаларында төрле кыскару вә кучешләр күзәтелә.

Бу кыскача сыйфатламаны укыгач ук төрле сораулар уянырга тиеш. Ни өчен, мәсәлән, кайбер кагыйдәләр аерым авазларга гына катыла. Ни өчен сүз азагындагы *-q, -k* һәм *-p* авазлары аларга сузыкка башланган кушымчалар ялганган очракта (әйтик, әлеге тартыклардан соң тартым кушымчасы *–ы//е* килгәндә) яңгыраулаша да, бүтән шундый (финаль, ауслаут) саңгырау тартыклар (мәсәлән, *–с, –т, –ш*) яңгыраулашмый? Нигә *ис* сүзенә *–е* кушымчасы ялгангач сүз *изе* булып яңгырамый? Нигә *–с* һәм *–ч* авазына башланган кушымчалар сузыкка беткән нигезгә ялганганда шул *с–* һәм *ч–* яңгыраулашмый, ягъни, нигә *аттан* һәм *даладан (кардан)* дибез дә, *атчы* һәм *далачы* диелә (һәр очракта саңгырау аваз *–ч* кала).

Аффиксларларда вариантлылык гадәттә әйтелеш уңайлылыгы белән аңлатыла. Ләкин, әгәр *китапы* урынына *китабы*дип әйтү уңайлырак икән, *бурычы* урынына *бурыҗы* уңайлырак булмас идемени?

[28] к. М.З.Зәкиев. О тюркской морфонологии//Татары: проблемы истории и языка. Казань, 1995. С. 341-351.



Мондый мантыйксызлык вә уңайсызлыкларның үз сәбәпләре бар (сәбәпсез берни дә булмый). Һәм ул сәбәпләрне еш кына тик тел тарихыннан гына табып була.

Шуны әйтеп узыйк ки, татар телендәге мантыйксызлык һәм уңайсызлыклар – тарих «бакые», тарих тәэгән йөк телләрнең күпчелегендә булганга караганда шактый азрак. Мәсәлән, күрше тел – рус теле үзендә зур һәм рациональ булмаган тарих йөген йөкләп килә. Мәсәлән, без *өстәлләр, урындыклар, эскәмияләр* дибез, ә руслар *столы, стулья* һәм *скамьи* дип сөйлиләр. Күплек кушымчасын без гомуми кагыйдәләр буенча аз санлы (нибары дүрт) варианттан эзләп табабыз. Ә руслар күплек формасының иллегә якын вариантыннан эзләп табарга, асылда һәр сүзнең күплек формасын хәтердә калдырырга тиешләр (чөнки еш рус сүзенең соңгы авазы да нинди кушымча кушылырга тиешлек турында күрсәтмә бирми: *стол* һәм *стул* икесе дә бердәй *л*-га бетә, әмма күплек кушымчалары башка-башка). Менә бу, ичмасам, тарих йөге!

**Вокализм**

§21. Югарыда (§7) фонетика бабында телнең иң тиз үзгәрүчән элементы – сузык авазлар, дидек. Шуннан чыгып, тәнәйтүле тикшеренүебезне татар теленең сузык авазларыннан, вокализмыннан башлыйбыз.

Сузык авазлар һәрбер төрки телдә, структур элемент буларак, бер сингармоник система тәшкил итәләр. Һәм, инде искәрткәнебезчә, структура хәрәкәтчән, система тотрыклы. Ягъни, системадагы аерым элементлар алмаштырыла, үзгәртелә алалар, система үзе үзгәрешсез кала (ул бик зур басым астында гына деформацияләнә). Менә шуларны истә тотып конкрет анализга керешик.

§22. Татар теленең хәзерге көндәге вокализм системасы сигез парлы авазны – *а, ә, у, ү, ŏ, ө, ы, ĕ* – фонемалары *-н* һәм парсыз *-и* вә фонематик авазларын эченә ала. Кайбер фонетистлар, мәсәлән, Р.Ф.Шакирова татар телендә тагын *–ый (ъ)* фонемасы бар дип баралар[29], ләкин бу бәхәсле фикер һәм безнең темабыз өчен әһәмиятле дә түгел. Шуның өчен без «*ый*» (*yj*) фонемасын исәпкә алмыйбыз. Рус теленнән кергән (бигрәк тә интернациональ) сүзләрдә ачык *ŏ* (*ра́йóн, тóнна, тóрт*) һәм ачык э (*эра, нетто, трест*) очрый. Бу авазлар борынгы һәм гомумтөрки *о* һәм э авазларына якын. Тик без рус алынмалары мәсьәләсен карамыйбыз[*].

Димәк, тугыз фонематик аваз кала. Аларның тарихын тикшерү өчен татар диалектларының һәм күрше вә кардәш телләрнең материалына игътибар итәбез.

[29] Р.Ф.Шакиров. Хәзерге татар теле фонетикасына кереш. Казан, 1954. 31-36 б.

[*] Шуны әйтергә мәҗбүрбез: татарча (ш. үк башкортча, марича, чувашча) *ĕ* русча э-дән шактый үзчә аваз. Югыйсә дәреслекләрдә *ĕ* авазын э хәрефе белән транскрипцияләү очрый.

Бу авазлар артикуляцион, акустик һәм функциональ җәһәтләрнең һәркайсы буенча төгәл тәңгәл килеп башкорт телендә дә кулланылалар. Аннары, бу авазлар барсы да һәм – бигрәк тә шунсы игътибарга лаеклы – аларның бик үзенчәлекле булганнары *ŏ* һәм *ө* – күрше мари телендә, өлешчә (диалекталь сөйләмдә) чуваш телендә вә якын кардәш казах, нугай телләрендә, аннары килеп, Себердәге ханты һәм манси телләренд әочрыйлар. Гомумән, артикуляцион-акустик яктан әлеге үзеәчәлекле *ŏ* һәм ө авазлары, ә-нең ачык әйтелеше һ.б. кайбер сыйфатлары белән аеруча характерлы булган бу система татар-башкорт вокализм дип атала.

Функциональ яктан система буларак та, аерым аваз парларында да татар-башкорт вокализмы гомумтөрки вокализм системасына, бигрәк тә аның уйгур һәм кыпчак телләрендәге вариантына туры килә. Борынгы ана төрки телдә сигез (дүрт пар) сузык аваз булган; шуларның җидесе татар телендә үзенчәлекле, әмма бер үк сүзләрдә туры чагылыш таба. Тик борынгы ә авазы гына татар телендә ике рефлекс бирә: *и* һәм *ә* (таблица I һәм II-не карагыз).

I

| | | Тартыкка беткән нигезләр | Сузыкка беткән нигезләр |
|---|---|---|---|
| Арткы рәт | бор. төрки | baj, boluš, cyq-, quϑruq | Ala, ortu, qyna-, turna |
| | татарча | бай, булыш, чык-, койрык | ала, урта, кыйна-, торна |
| Алгы рәт | бор. төрки | bel, bez, biz, böl-, jüz | eki, örü, kirpi, ügrä |
| | татарча | бил, бәз, без, бүл-, йөз | ике, үрә, керпе, өйрә |

II

| **Борынгы төрки телдә:** | | | **Татар телендә:**[30] | |
|---|---|---|---|---|
| 1 иҗектә | 2 иҗектә | | 1 иҗектә | 2 иҗектә |
| a(a) —— | a(a) | → | $a^o(a^o)$ —— | $a^o(a^o)$ |
| e(э) —— | e(э) | → | и(i) —— | ө(ä) |
| | | → | ә(ä) —— | ә(ä) |
| ŏ - | (булмаган) | → | у(u) – | (булмый) |
| u(у) —— | u(у) | → | ŏ (ŏ) —— | о, ы (о, у) |
| ö - | (булмаган) | → | ү(ü) – | (булмый) |
| ü(ү) —— | ü(ү) | → | ө(ө) —— | ө, е (ө, ĕ) |
| у(ы)—— | у(ы) | → | ы(у, —) — | ы(у) |
| i(и) —— | i(и) | → | е(е, ĕ) —— | е(е, ĕ) |

[30] Тулырак таблица (чуваш теле авазларын да кертеп): Р.Г.Ахметьянов. Сравнительное исследование татарского и чувашского языков. М., 1978. С.16.



Таблицадан күренгәнчә, борынгы ана төрки телдә (һәм хәзерге кайбер төрки телләрдә, мәсәлән, кумык һәм карачай-балкар телләрендә)[31] сигез сузыкның икесе *–о* һәм *ŏ* авазлары – тик беренче иҗектә генә кулланылган. Татар телендә дә шулар урынына (бер үк сүзләрдә) туры килгән *у* һәм *ү* авазлары да беренче иҗектә генә кулланылалар. Гомумән, борынгыдан килгән тамыр вә сүз нигезләрендәге сузыкларга татар сузыклары чигентесез рәвештә таблицада күрсәтелгәнчә туры киләләр. Әмма татар сузыклары акустик-артикуляцион җәһәттән борынгы сузыклардан аерылып торалар. Шуңа күрә борынгы төрки вокализм системасы татар-башкорт телләрендә **сынылыш кичерә**, диләр.

§23. Монда шундый сорау туарга мөмкин: нишләп соң борынгы төрки вокализм дигәнебез беренчел, ә татар-башкорт вокализм икенчел дип исәпләнә соң әле? Бәлки татар-башкорт вокализм борынгыдан да борынгырак булып, сигез сузыклы вокализм тугыз сузыклыдан килеп чыккандыр?

Мондый сорауга кире җавап бирергә туры килә.Чөнки шундый закончалык бар: телдә инновация (яңа бер күренеш) вакыт вә әфәза киңлекләрендә гадәттә таррак урын били. Татар-башкорт вокализм системасы исә төрки халыклар яшәгән гаять киң территориянең тик бер өлешендә – Идел-Урал регионында гына һәм асылда соңгы гасырларда гына төркәлдерелгән. Аннары, бөтен тарихи мәгълүматлар таныклык иткәнчә, төркиләрнең ана ватаны Урта Идел-Урал регионы булмаган. Киресенчә, тарих дулкыннары төрки кавемнәрне әледән-әле Агыйдел һәм Чулман ярларына китереп ташлаган.

§24. Башкорт-татар (яки татар-башкорт) вокализм сынылышының сәбәпләре турында сөйләгәндә кайберәүләр гомумлингвистик спонтан тенденцияләр – озын сузыкларның кыскаруы, нәтиҗәдә «яңа» һәм «иске» сузыкларның бергә туры килүе, аларның сыешмавы, омонизациядән качу чарасы буларак иске сузыкларның акустикасы һәм артикуляциясе үзгәрүе турында сөйлиләр[32]. Болар барысы да бер яктан дөрес. Ләкин, югарыда әйтелгәнчә, фонематик авазлар телдә үзеннән-үзе килеп чыга алмый (§6). Һәм татар-башкорт вокализмының килеп чыгышы да бу телләрдә сөйләшүчеләр тарихы белән тыгыз бәйләнештә каралганда гына канәгатьләндерерлек итеп аңлатыла ала.

Татар-башкорт вокализмы килеп чыгышы мәсьәләсен караганда түбәндәге хакыйкатьләрне күздән ычкындырмаска кирәк.

[31] Кара: Тюркские языки. М., 1966. С.21.
[32] Г.П.Мельников. Геометрические модели вокализма и причины перебоев башкирско-татарских гласных//Проблемы лингвистического анализа. М., 1966. С. 26-33.

Беренчедән, татар-башкорт вокализмы кимендә мең ел элек формалашкан. Кайбер филологлор бу вокализм системасы, имеш XVII-XVIII гасырларда килеп чыккан дип уйлыйлар. Мәгълүм ки, татар-башкорт вокализм системасы Ока елгасы буйларыннан алып Җаек буйларына кадәр (XIX гасырдан соң Себер татарларына да таралып) хөкем сөрә. Ошбу киң территориядә татарлар һәм башкортлар XVIII гасырдан бирле руслар һәм башка халыклар арасында утрау-утрау булып яшиләр. Рус администрациясн аларга берләшергә, тыгыз аралашырга XVI гасырдан бирле юл куймый. Шундый шартларда сузыклар системасының сыныльш кебек тирән үзгәреш шундый зур территориягә тарала аламы?

Өстәвенә, чуваш вокализы да, җентекләп тикшерүләр буенча, татар-башкорт вокализмы җирлегеннән үсеп чыккан бит әле[33]. Чувашларның татар-башкорт вокализмын XVII-XVIII гасырларда гына үзләштереп, шуннан соң чуваш телендә *a>o>y* күчешләре һәм велярлашу күренешләре килеп чыгуы – абсурд фикер.

Тел үзенчәлекләре, сүзләрнең әйтелеш нормалары массаларга таралсын өчен ул массаларгың нык берләшеп, үзара мотлак кирәк булганга тыгыз бәйләнешта яшәве шарт. Тел үзенчәлекләре, инновациядәр йогышлы чир түгел – алар җил яисә агымсу белән таралмый һәм туфракта сакланып ятмый. Алар сөйләшү-аңлашу өчен кирәкле сүзләрне әйткән моментларда бер-берсеннән әйтелеш үзенчәлекләрен бер-берсеннән отып, уртак нормаларга килергә тиешләр. Һәм, иң мөһиме, алар бу уртак нормаларны кирәксенергә тиешләр.

Тарихтан мәгълүм калганча, мәдәни телләр экономик тыгыз аралашу төбәкләрендә – сәүдә, базар-тиҗарәт үзәкләрендә таралыш ала. Гадәттә уртак аралашу, сатулашу-килешү теле булып шундый үзәкләрдә даимән яшәүче теле хезмәт итә. Ул телнең икенче бер (мәдәни һ.б.ш.) телнең акцент белән «бозылган» варианты булырга бик мөмкин. Әлеге мәдәни телнең төп ияләре аз санлы булып, төрле кавем-кабилә, төрле токымнан җыелган ишле масса үзара аңлашу өчен теге аз санлылар телен кулланса, әлекке сәвәтсез заманнарда «мәдәни» телнең «саф» нормаларын саклау мөмкин булмаган, бозып сөйләү нәтиҗәсендә стихияле рәвештә яңа нормалар туган. Татар-башкорт вокализмы да шул юл белән, әмма, ихтимал, берничә этапта әкренләп формалашкан булса кирәк. Әлеге вокализм системасының башкача барлыкка килүен күзәфәләү кыен. Билгеле, рус хакимияте һәм колонизациясе заманнарында иҗтимагый идарә вә сәүдә үзәкләрендә рус теле хакимлек иткән һәм,

[33] Р.Г.Ахметьянов. Сравнительное исследование татарского и чувашского языков. М., 1978. С. 15-47. Б.А.Серебренников. К проблеме истории гласных чувашского языка. СТ. 1984, №2, с. 9-14.



әлбәттә, өр-яңа уртак төрки тел барлыкка килә дә, тарала да алмаган. Бу чорда диалектлар арасында аермалар бетерелмәгән. Аларны бетерү тенденциясе тик милләт – үз этник бердәмлеген мәдәни юллар илә сакларга омтылучы кешеләр тупламы барлыкка килгәч кенә мөмкин була.

«Мәдәни тел» функциясен ниндидер борынгы кыпчак теле үтәгән, ә аны үзләренчә, акцент белән яңа төскә кертүче – болгарлар, төрле финн-угорлар, Урта Азия әһелләре, норманнар, славяннар катнашмасы булуы ихтимал.

Ул мәдәни һәм экономик үзәк (яки үзәкләр) кайда һәм кайчан булган? Кайберләүләре татар теленең формалашу заманын Казан дәүләт чорына (XIII гасыр азагы – XVI гасыр уртасы, 1445 елга кадәр билек, аннары ханлык[34]) кайтарып калдыралар. Ләкин мишәр диалекты аннан күп элек формалашкан һәм бу диалектның фонетик системасы гомумтатар фонетик системасыны бер тармагы гына булып тора, ул гомумтатар фонетик системасы нигезендә генә арытабын үсеше, үз үзенчәлекләренә ия булган[35]. Мишәрләр этник группа буларак Мукшы (Наручат) дәүләте чорында формалашкан (XV гасыр) дип уйларга нигез бар, ләкин Наручат халкының теле – XIV гасырдан күп элек үк Урта Иделдән, төп Болгар җирләреннән киткән кешеләр теле булган. Алтын Урда чорында Казан белән Мукша (Наручат) арасындагы тыгыз экономик бәйләнешлар булуы билгеле түгел. Андый бәйләнешлар Болгар дәүләте чорында булган: археологик мәгълүматлар Болгар дәүләте үзәкләреннән Барыш, Алатыр һәм Цына (Цна) елгалары буйлап Киевка һәм Азов вә Кара диңгез портларына бара торган сәүдә юлы булганлыгы, ул юл буйлап утрак тормышлы болгарлылар яшәгәнлеге турында сөйлиләр. Менә шундый шартларда яңа тел – үзәнчелекле вокализмга ия булган борынгы татар теле ерак тарал алган.

Мишәр вокализмы гына түгел, чуваш вокализмы да асылда борынгы татар-башкорт вокализмы нигезеннән үсеп чыккан: тәнәйтелгән, соңгы дуен-юшкыннардан арындырылган борынгы чуваш вокализмы татар-башкорт вокализмының бөтен характерлы үзенчәлекләренә ия була. Хәлбуки, чувашларның төрки бабалары монгол яуларына кадәр үк татарларның Болгарстандагы бабаларыннан шактый дәрәҗәдә изоляцияләнгәннәр (ягыйсә чуваш халкы гомумән формалашмас иде).

§25. Китерелгән тарихи экскурс татар-башкорт вокализмм системасының борынгылыгын исбатлау өчен һәм аның пәйда булуының

[34] Карагыз: С.Х.Алишев. Казань и Москва. Межгосударственные отношения в XV-XVI вв. Казань, 1995. С. 14.

[35] Карагыз: Л.Т.Махмутов. Опыт исследования тюркских диалектов. Мишарский диалект. М., 1978.

гомуми-закончалыклы сәбәпләрен чамалау өчен кирәк. Ләкин конкрет шартлар вә сәбәпләрне ачып салу эше әле алда. Хәзергә татар-башкорт вокализмының аерым элементлары тарихын карап үтик.

**Татар-башкорт вокализ системасындагы «а» авазы**, бигрәк тә татар теленең урта диалектында, беренче иҗектә русча һәм гомумтөрки «о» кебегрәк әйтелә. Икенче иҗектә *о*-лаштыру сүрелә төшә, өченче иҗектә исә «а» гомумтөрки «а» кебек диярлек укыла. Г.Алпаров моны түбәндәге мисалда күрсәтә:

*бåла°ла˙р*[36].

Фонологик җәһәттән караганда *а*-ның беренче иҗектә *ŏ*-лашуы татар-башкорт телләрендә гомумтөрки *ŏ* авазының *у*-га күчүе һәм фонематик аваз буларак юкка чыгуы белән аңлатыла. Чагыштырма тарихи җәһәттән *ŏ*-лаштыру (*а>о*), татар телендә булган һәм булмаган төрки һ.б. сүзләрдә, тагын чуваш (вирьял диалекты), мари (улык-мари диалекты) һәм үзбәк, таҗик вә фарсы теләрендә күзәтелә. Барча бу телләр тарихта татар теле белән багланышка кергәннәр, тәэсирләшкәннәр. Шуңа күрә мәзкүр аваз уртаклыгы очраклы дип кистереп әйтеп булмый. Һәм *а*-ның *ŏ*-лашуы (дөресрәге *а* һәм *ŏ* авазларының бер фонема аллофоннары булып китүе) Урта Иделгә килмеш мөһаҗирләр теленнән калган булуы бик ихтимал (андый күченешләр X-XII гасырларда булгалаган).

§26. Гомумән *а* авазының беренче иҗекләрдә иренләшүе татар-башкорт фонетик системасында әллә ни үзгәрешгә китермәгән. Кайбер татар һәм башкорт сөйләшләренщә *а* сүз башында да иренләшми, әмма шуннан сөйләм аңлаешсызга әверелми.

Гомумтөрки у(ы) авазы татар-башкорт әйтелешендә бераз үзгәргән, ләкин бу үзгәреш тә сөйләмгә яңа сыйфат кертми шикелле. Ә менә ирен сузыклары өлкәсендә хәл бөтенләй башкача.

§27. Әйткәнебезчә, татар телендәге *у(и)* һәм *ү(ü)* авазлары гомумтөрки һәм борынгы төрки *о* һәм *ö* урынына килә, ә ул *о* һәм *ö* хәзерге татар һәм башкорт телләрендә инде бөтенләй кулланылмый (рус теленнән кергән сүзләрдәге *ŏ*-ны исәпкә алмыйбыз). Шул ук вакытта гомумтөрки һәм борынгы төрки *и(у)* һәм *ü(ү)* авазлары, татар, башкорт һәм чуваш телләрендә һәр очракта диярлек *ŏ* һәм *ө* авазларына күчкән:[37]

[36] Г.Алпаров. Сайланма хезмәтләр. Казан, 1945. 140 б.

[37] Бу күчешләр турында к. Дж.Г.Киекбаев. О передвиженииии гласныҥ в башкирском языке. Ученые записки БГПИ. Вып. 8. Серия филологических наук, №2. Уфа, 1955. С. 220-229. А.М.Щербак. Сравнительная фонетика тюркских языков. Л., 1970, с. 151-156. Р.Г.Ахметьянов. Сравнительное исследованиее татарского и чувашского языков. М., 1978. С. 14-44.



| борынгы һәм гомумтөрки | татарча | борынгы һәм гомумтөрки | татарча |
|---|---|---|---|
| *bor* "известьташ" | > *бур* | *bur-* | > *бŏр-мак* |
| *qol* | > *кул* | *qul* | > *кŏл* |
| *köl* | > *күл* | *kül* | > *көл* |
| *tök* | > *түк-мәк* | *tük* | > *төк* |
| *öç* | > *үч* | *üč* | > *өч* h.б. |

Бу үзара багланышлы процессларны түбәндәгечә тәгъбирләп була:

*o>y//u>ŏ* [*о>у//у>ŏ*]
*ö>ü//ü>ө* [*ö>ү//ү>ө*].

Мондый күчешләрне эшелонлы яисә аффинлы күчешләр дип атыйбыз.

Гомумтөрки *о* һәм *ö* Идел-Урал регионындагы төрки телләрдә бөтенләй беткән, әмма гомумтөрки *и(у)* һәм *ü(ү)* кайбер очракларда саклана шикелле, мәсәлән, гомумтөрки *бу* (алмашлык), *су, ту, туг* («байрак») сүзләре шул ук яңгырашта киләләр.

Ирен сузыкларының югарыда китерелгән рәвештәге, эшелонлы күчешенең башлангычлары нугай һәм казах телләрендә дә күзәтелә (анда да *у>о, ү>ө* очраклары бар, әмма *о* һәм *ö* югалмаган). Шуннан чыгып, әлеге эшелонлы күчешнең башлануы – борынгы субстраат (төркиләшкән халыкның элекке) телендә төрки *и(у)* һәм *ü(ү)*нең беренче иҗектә зәгыйфьләнеп, *ő* һәм *ө* кебегрәк әйтелеше булса кирәк, дибез. Андый субстрат ролен мөгаен угор телләре үтәгән дип әйтеп була. Тарих һәм археология мәгълуматлары буенча угор халыклары безнең эраның I меңъеллыгында, Обь елгасыннан алып Иделгә һәм Чулманның югары агымнарыннан алып Арал диңгезенә чаклы киң территориядә таралып, күчмәнчелкетә яшәгәннәр. V-IX гасырларда аларның бер өлеше төркиләр басымы астында яисә төркиләр белән бергә көнбатышка күченгән, ә калганнары төркиләр һәм удмуртлар (ихтимал тагы марилар) тарафыннан ассимиляцияләнгәннәр.

§28. Эшелонлы аваз күчешләренең тагын берсе – аеруча татар теленә хас булганы – беренче иҗектә гомумтөрки *э(е)* авазының *и(i)*гә, шул ук вакытта гомумтөрки *и(i)* авазының *е* авазына күчеше, мәсәлән:

| борынгы һәм гомумтөрки | татарча | борынгы һәм гомумтөрки | татарча |
|---|---|---|---|
| *ber- (бәр-)* «бирмәк» | > *бир-* | *bir (бир)* «бер» | > *бер* |
| *teri (тәри)* «тире» | > *тире* | *tirig* (*тириг*) «терек» | > *терек, тере* |
| *et (эт)* «ит» | > *ит* | *it (ит)* «эт» | > *эт* h.б. |

Бу очракта барлык элекке *и*-ләр э-гә күчеп беткән булсалар да, барча элекке э-ләр *и*-гә күчкән дип әйтеп булмый, чөнки кайбер сүзләрдә элекке *е(э)* тагын да ачылып *ä(ə)* авазына әверелгән һәм хәзерге телебездә шул рәвештә кулланыла, мәсәлән:

| борынгы төрки | татарча |
|---|---|
| *teŋri* (тәңри) | > *тәңре* |
| *teke* (тэкэ) | > *тәкә* |
| *čeček* (чэчэк) | > *чәчәк* һ.б. |

Шулай итеп, югарыдагы схемада да (§21) чагылганча, татар телендә борынгы *е(э)*, сүзенә карап, ике төрле чагылыш таба:

*е(э)* → *i (и)*
*е(э)* → *ä (ə)*

Бу тармакланышның тирән тарихи сәбәпләре бар һәм алар татар теленең һәм халкының килеп чыгышына турыдан-туры кагыла.

Шуны ачыклап үтү кирәк ки, борынгы төрки *е(ә)* ул киң, ачык аваз һәм ул җич кенә дә татар-башкорт-чуваш *ĕ*-сенә тиң, охшаш түгел. Хакас һәм казах әдәби телләрендә е авазы да (бу телләрнең кириллицага корылган алфавитында ул (хәреф белән билгеләнә), гомумтөрки *е(э)* авазы да бар – аларны буташтыру, берсе урынына икенчесен әйтү аңлашмаучылыкка китерә, чөнки алар аерым мөстәкыйль фонемалар.

Икенче яктан *е* һәм *ä(ə)* авазлары да, кайбер телләрдә (мәсәлән, борынгы төркидә) бик үк аермасалар да, икенче бер телләрдә аерым-аерым ике фонема булырга мөмкин. Мәсәлән, хәзерге фарсы телендә *ä* һәм *е* – мөстәкыйль фонемалар һәм руслар фарсыча *ä* –не үзләренең телләрендә дә булган *е* кебек әйтергә маташсалар, «бу тупас ялгышларга китерә – фарсы кеше синең әйтергә теләгәнен урынына бөтенләй бүтән нәрсә аңларга мөмкин»[38].

Кайбер телләрдә *ä(ə)* һәм *е*(э), икенчеләрендә (татарча һ.б.) *ä(ə)* һәм *е* кискен аерылса, өченчеләрендә, мәсәлән, казах әдәби телендә *ә*, *е* һәм *ĕ* – өчесе дә фонема. Ләкин мондый телләр сирәк.

Тагын шуны искәртеп үтү зарур ки, *а(ä)* авазы *и(i)*, ә борынгы *i(и)* урынына *ĕ* килү күренеше татар һәм башкорт телләреннән тыш (ягъни Идел-Урал регионынна тыш) тагын ерак хакас телендә (Енисей буйларында) күзәтелә. Һәм, беренчедән, ул – эшелонлы күчеш, икенчедән, вә иң мөһиме, ул – татар һәм хакас телләрендә бер үк сүзләрдә килә, мәсәлән:

[38] К. Персидско-русский словарь (В.С.Расторгуеваның фарсы теле грамматикасы буенча зур рисаләсе). М., 1960. С. 617.



| гомумтөрки | татарча | хакасча |
|---|---|---|
| *esik* (эшик) | *ишĕк* | *исĕк* (хакас телендә *ш>с*) |
| *kendir* (кэндир) | *киндĕр* | *киндĕр* |
| *terlig* (тэрлиг) | *тирлĕ* | *тирлĕг* һ.б. |

**Моның кебек мисаллар һичшиксез** уртак чыганактан киләләр[39].

Шуның белән бергә, татар һәм башкорт телләрендә һәм, бигрәк тә татар теленең Бараба сөйләше белән курык мари (тау ягы марилары) телендәге күпсанлы төрки сүзләрдә борынгы түрек (гомумтөрки) *е(э)* урынына *ä(ə)* авазы килү очраклары да күп кенә. Бу күренеш тагын нугай, казах, каракалпак телләрендә бар, аннары тоталь рәвештә *е>ä* *(э>ə)* уйгур һәм азәрбайҗан телләрендә күзәтелә.

Шулай итеп, кайбер телләрдә *е>i (э>и)* өстенлек итеп, шул ук вакытта е>ä (э>ә) очраклары да бар, ә икенче бер төрки телләрдә *е>ä* *(э>ə), е>i (э>и)* күренеше юк.

Борынгы язма телләр дә бу җәһәттән ике төркемгә бүленә: кайбер руник язмаларда беренче иҗектә *i*, икенчеләрендә *ä* яисә *е*. Барлык бу мәгълүматлар төрки шивәләр арасында борынгы бер *i* (и) группасы аерылып торган һәм шул мәдәни (үз язуы булган) шивәләрдә сөйләшүчеләрнең варислары иң беренче чиратта татарлар һәм хакаслар икәнлеген күрсәтәләр (өстәвенә, *i* – телендәге руник ядкәрләкләр башлыча хәзерге Хакасиядә һәм аның тирәләрендә табылганнар).

Гомумән сирәк очрый торган һәм кыска текстлы руник язмаларга карап кына борынгы *i-* (*и-*) диалект таралган өлкәне төгәл генә күрсәтеп булмый, әлбәттә. Ләкин *е>i* күренешенең хакас диалектларында киң таралган булуын исәпкә алып һәм татар халкының борын-борыннан уртак игенче булуын, ә Хакасия шулай ук борынгы сугарулы игенчелек регионы икәнлеген искә төшерсәк, татарларның иң борынгы бабалары (яисә шуларның берсе) Хакасиядән килгән булырга тиеш, дип әйтеп була.

Урта Идел-Чулман бассейнына баштарак килгән төркиләр *ä-* телдә сөйләшкән булса кирәк: бу нәтиҗәгә ä- телнең рефлексларын (*ä-* һәм *ä->а-* булган сүзләрне) картага төшерү юлы белән киленә. Ул рефлексларның иң куе булган мәйданнары – марилар һәм чувашлар яшәгән җирләр. Татарларның мишәр һәм Казан тирәсе сөйләшләрендә алар сирәк, әмма Көнчыгышка – Башкортстанга таба алар тагын куера башлый һәм Барабада алар Мари-эл һәм Чувашстандагы кебек куелыкка җитә. Менә шул өлкәләрне татар теленең *i-* сөйләшләре өлкәсе бәреп

[39] Ошбу татар-хакас тел уртаклыклары, без белгәнебезчә, тәүләп Ф.Исхаковның «Хакасский язык» (Абакан, 1965) дигән китабында бәян ителде, аннары бу турында М.И.Боргояковның «Источники и истории изучения хакасского языка» (Абакан, 1981) һәм Р.Г.Әхмәтьяновның «Общая лексика материальной культуры народов Среднего Поволжья» (М., 1989) дигән китапларында язылган.

кергән дулкын теле шикелле аерып тора. Ләкин *i-* өлкәсе (*ä-* өлкәләре кебек үк) бөтенләй чиста түгел – анда да *ä-* телнең рефлекслары (ә *ä-* тел өлкәләрендә *i-* тел рефлекслары) бар.

| | |
|---|---|
| *Käŋ, täŋ, čärü; än, är, äš; käbär, kärtä, käštä, känäš, tären* | Бараба татарлары, курык-мари |
| *kaŋ, taŋ, s'ar; an, ar, aš; kaban, karta, kašta, kanaš* | Улык-мари теле |
| *kiŋ, tiŋ, čirü; iŋ, ir, iš, лəкин bäk, käbän, kärtä, käštä* | Көнбатыш Башкортостан татар теле |
| *kiŋ, tiŋ, čirü; iŋ, ir, iš; bik, kibän, kirtä, kištä, tirän* | Татарстан, мишәр татар теле |
| *Kan, tan, s'ar; an, ar, kaban, karta, kašta, kanaš* | Чуваш теле |

Менә шушы картада чикләре чамаланган *ä(ə)-* телләр хакимлеге регионына – аның уртасына кайчандыр бер *i(u)-* тел (шул телдә сөйләшүчеләр массасы) килеп кергән. Нәкъ шул *i(u)-* тел, мәдәни тел буларак, татар теленең оеткысын тәшкил иткән (к. §24) булса кирәк. Җирле *ä-* төрки телләр белән тәэсирләшерәк, борынгы *i(u)-* тел алардан күп нәрсә, күп сүзләр, шул хисаптан кайбер *ä-* сүзләр дә үзләштергән (ә гомумән – тел вәкилләре җирле *ä-* сүзләрне *i-* сүзгә әйләндерә башлаганнар).

Бу процесслар, әйткәнебезчә, әлбәттә, рус колонизациясенә чаклы һәм, мөгаен, монгол яуларына кадәр барганнар.

*Ә(ä)-* һәм *u(i)-* диалектларының бер этнос эчендә тәэсирләшү, гомумхалык теле тәшкилләнү процессында кайбер очракларда бер үк сүзнең *ə*-варианты бер мәгънәдә, ә *u-* варианты икенче мәгънәдә карарлашкан. Шуның мисалын без *бәр-* һәм *бир-* фигыльләрендә (бу сүзләргә беренчеләй Ләтыйф Җәләй игътибар иткән), *дәу* һәм *дию* сүзләрендә күрәбез. Диалекталь лексикада тагын *кәртә* «уртача юанлыктагы озын агач кәүсәсе, чош (жердь)» һәм *киртә* «тоткар; тоткарлау корылмасы» аерымланганнар. *Дәфтәр* (гади сөйләмдә *тәптәр* булган) һәм *типтәр* сүзләре дә әйтелгәнгә мисал.

Гомумән исә *u(i)-* һәм *ə(ä)* вариант лексикада төрле сөйләшләрдә төрле дәрәҗәдә, әмма бер үк сүзләрдә сакланып киләләр. Ул сүзләрнең иң билгелеләре түбәндәгеләр:

*бик – бәк*
*ирлән – әрлән*
*кибәк – кәбәк*
*кибән – кәбән*
*киңәш – кәңәш*
*кирмән – кәрмән*
*киртә – кәртә*
*кирәк – кәрәк*
*китмән – кәтмән*
*миргән – мәргән*
*нимә – нимә* «нәрсә»
*сике – сәкә*
*тигәч – тәгәч* «тоз савыты»
*тик – тәк*
*фирештә – фәрештә*
*чичән – чәчән*



Диалекталь лексикада андый парлар тагын берничә дистә: *кипкер – кәпкер* «аш сөзгече; өре алгыч кашык» (фарсыча *кәфкгир* «күбек алгыч» сүзеннән), *кипрән – кәпрән* «мендәр һ.б. тышлыгы, сүрү», *кәрәп – кирәп* «кәрап, зур көймә», *пәке –пике* «пәке, катламалы пычак», *пәри – пире* «пәри, җен», *тикле – тәкле, тигәр – тәгәр* «тәгәрмәччек», *чирмә – чәрмә* «күн сумка» (фарсыча *чәрм* «күн» сүзеннән); башкорт телендә *пистәр – тәстер* «дус-иш» пары бар (фарсыча *дәстгир* «кул бирүче, ярдәм итүче» сүзеннән).

Шулай ук тик башкорт телендә һәм Бараба диалектында гына сакланган *ə*-вариантлар бар. Мәсәлән, *кәрәм* «агачка менү өчен аркан җайланма, кирәм», *тәрән* «тирән» һ.б.ш.

Аннары Бараба диалектына һәм курык (тау) мариларына уртак булган (улык мариларда һәм чувашларда велярлашкан) *ə(ä)* очраклар бар:

| Бараба | Курык-мари | Улык мари һәм чувашча |
|---|---|---|
| *äр* | *äр* | *ар* «ир» |
| *äт-* | *äт-* | *ат-* «эшләмәк, итмәк» |
| *бäр-* | *пäр-* | *пар-* «бирмәк» h.б. |

*И-* вариантлар (яки *ə*-варианты булмаган *u*-сүзләр) арасында төптә-асылда *ə(ä)* булган гарәп-фарсы һәм юнан (грек) сүзләре булуы игътибарга лаек (мәсәлән, *кипкер, кирәп, пике, пире, типтәр, тисте, чирмә*). Бу сүзләр ничек килеп чыкканнар соң? Күрәсең, алар башта үзендә ачык *ə(ä)* булмаган, бүтән телләрдәге ачык *э* авазы э булып үзләштерелгән кыпчак шивәләренә алынган булганнар һәм соңыннан үзендә э формасы булмаган татар теленә күчкәндә ул э авазы *u*-гә әверелгән (*ä>э>u*), мәсәлән: фарсыча *кäфкгир>* борынгы кыпчакча *кэпкир>* татарча *кипкер*; грекча *кäраб(ос)>* кыпчакча *кэрап* > татарча *кирәп* һ.б. Шул вакытта үзендә ачык *ä(ə)* булган кыпчак шивәләре дә булган һәм аларда чит телдәге *ä(ə)* үзгәрешсез үзләштерелгән (*кәфкгир>кәпкер* h.б.ш.)*.

§30. Татар телендә беренче иҗектәге, ә төп төрки сүзләрдә борынгы э урынына гына түгел, бүтән кайбер очракларда пәйда була. Андый очраклар нигездә ике төрле:

а) күпсанлы гарәп-фарсы сүзләрендә гарәп вә фарсы телләрендәге *ä(ə)* саклана: *әһәмият, бәндә, бәрабәр, вәсвәсә, зәңгәр* h.б. (берничә йөз сүз);

б) татар телендә кайбер төрки вә алынма сүзләр палатальләшү (нечкәрү) процессын кичерәләр (к. §31) һәм шул нигездә *а>ä(ə), ы>ĕ*

---

* Русча тюркологик хезмәтләрдә **татар телендә** *ə>u* күчеше турында сөйләнүләр очрарга туры килә. Хәлбуки татар теленең үзендә генә андый күчеш мөмкин түгел һәм мөмкин булмаган да.

күренешләр күзәтелә; ул сүзләрнең иң кулланышлылары түбәндәгеләр (мәгънә төгәллеге өчен русча аңлатмалар да бирелә).

| **Гомумтөрки** | | **Тат.** |
|---|---|---|
| *ajit-, ajt-* | «сказать» | *әйт-* |
| *ajlan-* | «кружиться» | *әйлән-* |
| *ajran* | «пахтанье» | *әйрән* |
| *baγyr* | «печень; сердце» | *бәгырь* |
| *baγ, baj* | «привязь» | *бәй* |
| *baγla-, bajla-* | «привязать» | *бәйлә-* |
| *bajram* | «праздник» | *бәйрәм* |
| *baqal* | «лодыжка» | *бәкәл* |
| *jaj-, заj* | «стлать; лето» | *җәй* |
| *jaš I-II* | «молодой»; «слеза» | *яшь* |
| *jašyl* | «зеленый» | *яшел* |
| *jašyr-* | «прятать» | *яшер* |
| *mačy* | «кошка, кот» | *мәче* |
| *čajyr* | «смола» | *чәер* |
| *čajna-* | «жевать» | *чәйнә* |
| *sanč-* | «колоть» | *чәнеч-* |
| *čač* | «волосы» | *чәч* |
| *čač* | «сеять» | *чәч-* |
| *čača-* | «поперхнуться» | *чәчә-* һ.б. |

§31. Бу рәттәге кайбер сүзләр татар телендә хәзерге көндә дә һәр ике (калын һәм нечкә, палаталь һәм веляр) вариантларда очрыйлар. Аларның бер варианттагысы әдәби, икенче варианттагысы диалекталь яисә гади сөйләм сүзе дип исәпләнә. Гомумән мондый парлар сингармоник параллелизм дип аталалар.

Аеруча таралган сингармоник параллелизмнар түбәндәгеләр (башкортча вариантлар җәяләр эчендә):

*аз – әз (әҙ);*
*акырын – әкерен;*
*арлы-бирле – әрле-бирле;*
*арчымак – әрчемәк (әрсемәк);*
*ачмак – әчмәк (асмак);*
*ачы – әче;*
*ачымак – әчемәк;*
*җанкай – җәнкәй* (чагыштыр: башкортча *йәнем* «җаным»);
*кычымак – кечемәк;*
*кычыткан – кечерткән;*
*ятышлы – ятешле* һ.б.



Тора-бара пардашлар аерым мәгънә ала башлыйлар ягъни аларның бер сыңары яңа бер мәгънәдә карарлаша. Шул юл белән диалекталь *атач* «атасына охшаган, иркәк (кош)» сүзеннән *әтәч, балакай* сүзеннән *бәләкәй, янаша (янашып, янына утырып)* сүзеннән *янәшә, ярашмак* сүзеннән *ярәшмәк* («кызны алырга килешмәк») сүзләре килеп чыккан. *Пычмак* һәм *печмәк, харам* һәм *хәрәм* сүзләре дә мәгънә ягыннан да шактый аерымланганнар.

Мондый очраклар этимологик дублетлар дип аталалар. Аларның шактый катлаулы нигездә ясалганнары һәм бик борынгылары да була (мәсәлән, *яшь* һәм *ел* икесе бер сүзгә кайтып калалар). Әмма теге палатальләшү нигезендә туган этимологик дублетлар татар телендә (яисә татар, башкорт телләре даирәсендә) яңарак барлыкка килгәннәр.

Палатальләшү һәм дублетлашу нигезендә татар телендә *абагай>абай>әбәй>әби, анай>әнәй>әни, атай>әтәй>әти* сүзләре дә ясалган.

Бу юнәлештә асылда яңа сүзләр түгел, ә яңа тамырлар ясала. Шуңа күрә бу очраклар фонетик сүз ясалышы дип атау дөрес түгел – монда тамыр ясалышы күзәтелә.

Палатальләшү мәйданында яңа тамырлар ясалу һаман дәвам итә. Газит-журналларда *ябышу* урынына *ябешү, янчык* урынына *яньчек* дип язгалыйлар.

Татар һәм башкорт телләрендә сингармоник параллелизмнар турында заманында Л.Җәләй һәм Җ.Киекбаев язганнар[40].

§32. Әйтелгәннәрдә аңлашылганча, гомумтөрки монда башкорт-татар вокализмы түбәндәге үзенчәлекләре белән аерылып тора:

а) *а* фонемасының беренче иҗекләрдә бераз иренләшүе;
б) *о>у//у>ŏ* һәм *ö>ү//ү>ө* эшелонлы күчешләре;
в) *э>и//и>ĕ* эшалонлы күчеше;
г) кайбер сүзләрдә палатальләшү очраклары.

Бу күренешләр хәзерге көндә бер-берсен тулыландырып, беркадәр бер-берсенә сәбәпле бәйләнешләр системасы хасил итеп торалар. Ләкин аларның сәбәпләре бәйләнешләры мотлак характерда түгел. Һәм, мөгаен, бу үзгәрешләр дүрт чордан, дүрт этнолингвистик вазгыятьтән калган күренешләр. Алар тарих дәвамында берсе өстенә берсе өстәрелгәннәр. Һәм, күрәсең, бу аерым процессларның иң соңгысы – палатальләшү күренеше.

Палатальләшү күренше кайда кына булмасын бер үк сүзләрдә күзәтелгәнлектән, аның тарихи үзәге – таралыш ноктасы булган дип уйларга ярый. Әмма хәзер ул ноктаны билгеләү кыен.

---

[40] Дж.Г.Киекбаев. Вариантные словаа или сингармонические параллелизмы в башкирском языке. Ученые записки БГПИ. Вып.5, серия филол. наук, №1. Уфа, 1955, 143-158 б.

§33. **Сингармоник чылбырлар** (СЧ). Һәрбер телдә иҗек калыплары булган кебек, тамыр вә нигезләрнең типик фонетик калыплары да була.

Төрки телләрдә сүз фонетик калыпларының бер чагылышы – сингармоник чылбырлар ягъни сузык авазларның сүзләрдә кайсы вә ниндиләре артыннан кайсы вә ниндиләр килүчәнлеге. Һәр сузык аваз артыннан теләсә нинди сузык киләлми. Югарыда бер борынгы телдә *ŏ* һәм *ö* авазлары беренче иҗектә генә була алганлыгын, шуңа күрә татар телендә әлеге *о* һәм *ö* –ләрнең чагылышы булган *у* һәм *ү* авазлары башлыча беренче иҗектә кулланылганлыгын әйттек. Сингармоник чылбырларның да тарихы бар. Һәм алар да системалары структур үзгәрешләргә дучар.

Хәзерге татар теленең урта диалектындагы гади сөйләмдә һәм башкорт телендә барча сузыклар да гомумән сүздәге беренче иҗекләрдә генә килә алалар, икенче иҗекләрдә *и, у* һәм *ү* булалмый. Ә өченче иҗектә, инде, болардан тыш, *о* һәм *ө* авазлары да килә алмый; өченче, дүртенче һ.б. иҗекләрдә, димәк, дүрт аваз – *а, ә* һәм *ы, е* авазлары гына килә. Һәм шул кагыйдәгә ярашлы рәвештә барлык кушымчаларда – ясагычларында да, төрләндергечләрендә дә – шул *а, ә* һәм *ы, е* авазлары гына кулланыла. Схеманы карагыз:

| арткы рәт (калын сузыклы) сүзләрдә | алгы рәт (нечкә сузыклы) сүзләрдә |
| --- | --- |







Мисаллар: *урынга, уйлана, буярлык, алама, алдына; алгарыш; озатам, озынча, амтылыш, ышанам; үкенәм; үзәге; икеләп; иртәгә; иртәнгә; әбәләк; бәрәнге; көтәләр; өрәңге; өтерге (өтөрге); көрәшә; электән; беләүгә; этәргеч.*

Шушы схемалар тулы көчендә булганда *барыйк, килик,* кебек әйтелешләр дә, *уку, көтү* кебек яңгырашлар да мөмкин түгел. Алар урынына *бараек, киләек* кебек әйтелешләр (кушымча варианты *–айык//-әйек*) һәм *укыу, көтүе* яңгырашлар килә. Әмма татар теленең мишәр (көнбатыш) диалектында, шулай ук ерак хакас телендә борынгы кыскарыш законны кяр итү нәтиҗәсендә, әлеге схемалар җимерелгән һәм әдәби тел дә мишәр сингармоникк чылбырларын кабул иткән. Шуны әйтергә кирәк, бу яңа СЧ схемалары хәзерге мишәр диалектында тагын да җимерелә төшкән – анда *ŏ* һәм *ө* авазлары гомумән юкка чыккан сөйләшләр бар.

Әмма башкорт телендә күрсәтелгән схемалар бүген дә тамм көчендә.



§34. СЧ үзгәрешләре конкрет сүзләрдәге аваз күчешләренә дә тәэсир иткән. Мәсәлән, борынгы төрки телләрдәге СЧ-ларында *о – у* һәм *ö – ү* төземе бик еш очраган. Бу төземнең авазларын аерым-аерым татарчага күчергәндә *у – ŏ* һәм *ү – ө* төземнәре хасил булыр иде. Ләкин татар телендә андый төземнәр мөмкин түгел. Һәм әлеге борынгы төземнәр татар теленә бөтенләй башкача – түбәндәгечә күчерелгәннәр:

| *о – у > у – а* һәм *у – ы;* | | *ö – ү > ү – ә* һәм *ү – е;* | |
| --- | --- | --- | --- |
| борынгыча: | татарча: | борынгы уйг.: | татарча: |
| *олук* | *улак* | *кöбүк* | *күбек* |
| *орун* | *урын* | *öрӥ* | *үрә (тору)* |
| *токуч* | *тугач (күмәч)* | *öлуксә* | *үләксә* һ.б. |

Татарчада икенче иҗектә *ә*-дән соң *ө* булмаганга күрә борынгы *бәлгүк, бәлүк* «подарок» сүзе *бүләк* булып күчкән һәм борынгы *бöлүк* «гаскәри яки административ бүлек» сүзе дә *бүләк* буларак күчерелгән. Нәтиҗәдә *бүләк* «подарок» һәм *бүләк* – «әлекке заманнарда (Казан Дәүләтендә һ.б.) административ берәмлек» омонимнары килеп чыккан. Бу *бүләк* сүзе борынгы *бöлүктән*, ләкин ул фонетик яктан бераз аерымланган.

*Бәлүктән бүләк* килеп чыккан шикелле, борынгыы фарсы сүзе *бәдүннән бүтән* сүзе ясалган.

§35. Борынгы *а ~ ы* тәңгәллеге: кайбер төрки телләрдә күпчелек очраклардагы *а* авазы урынында беренче иҗектә *ы* авазы килә. Мәсәлән, түбәндәге татар-чуваш тәңгәллекләрен алып карыйк:

| татарча | чувашча |
| --- | --- |
| *алмаш* | *ылмаш (ыйлмаш)* |
| *алтын* | *ылтӑн (ыйлдын)* |
| *авыр* | *йывӑр (йывыр)* |
| *агач* | *йывӑҫ (йывычс)* |
| *ару* | *ырӑ (ыйры)* |
| *бал* | *пыл (пыйл)* |
| *балчык* | *пылчӑк (пыйлҗык)* |
| *базык* | *пысӑк (пыйзык)* |
| *бар-мак* | *пыр- (пыйр-)* |
| *кап-мак* | *хып- (хыйп-)* |
| *карын* | *хырӑм (хыйрым)* |
| *кат-мак* | *хыт- (хыйт-)* |
| *сау* | *сывӑ (сыйвы)* |
| *сак* | *сыхӑ (сыйхы)* |
| *талкы* | *тылӑ (тыйлы)* |
| *тана* | *тына (тыйна)* |
| *тару* | *тырӑ (тыйры) «игеннәр»* |
| *хәбәр* | *хыпар (хыйбар)* һ.б. |

Шуның кебек мисаллар якут һәм тува телләрендә дә шактый:

| татарча | якутча |
|---|---|
| *ай* | *ый* |
| *канат* | *кынат* |
| *кашау* | *кыһнах (кысыах)* |
| *катыш-мак* | *кыттыш-* |
| *йанак, җанак* | *сынаах* |
| *йаз-мак, җаз-мак* | *сыс- «ялгышлык, юлдан язмак»* |
| татарча: | тувача: |
| *сап* | *сып «сап, кулса»* |
| *там-мак* | *дым-* |
| *тара-мак* | *дыра-* |
| *тарт-мак* | *тырт-* |
| *йат-мак, җат-мак* | *чыт-* һ.б.[41] |

Татар һәм башкорт телләренең үсеш юлы *а ~ ы* тәңгәллеге даирәсеннән читтә үткән. Шуңа күрә кайбер кушымчалардан тыш (к. түбәндәрәк) *а ~ ы* мисаллары бу телләрдә аз. Булганнары да бик катлаулы юллар белән килеп чыкканнар. Мәсәлән, *тал ~ тыл*: борынгы телдә *тал* төз агач кәүсәсен, бамбукны һәм арка үзеген, умырткалыкны белдергән; шуннан аның «арка, арт ак» һәм «тыл» мәгънәләре килеп чыккан. Борынгы төрки телләрдән *тыл* мәгънәсендәге *тыл* рус теленә алынган, рус теленнән татар теленә киеп кергән.

Иске татар әдәби телендәге *а ~ ы* тәңгәллеге мисал итеп *йыгач//җигач* һәм *агач* сүзләрен китерергә була (чаг.: чувашча *йывыч* «агач»).

Чуваш телендәге *а ~ ы (ый)* күчешенә мисалларның кайберләре (мәсәлән, гарәп теленнән кергән *мәсхәрә > мыскара, хәбәр > хыпар, хыбар,* рус теленнән кергән *арыш > ыраш*) яңарак сүзләрдә күзәтелсә дә, бу телдәге күп кенә *а ~ ы* очраклары борынгыдан килә (мәсәлән, *тына* «тана» сүзендәге *ы-ның* борынгылыгы венгерча *tina, tino* «тана» сүзе белән таныклана).

Борынгы *а ~ ы* тәңгәллегенең чагылышлары түбәндәге кушымчаларда да күзәтелә[42].

[41] К. А.М.Щербак. Сравнительная фонетика тюркских языков. П. 1970. С. 145.

[42] А.Н.Кононов. Грамматика языка тюркских рунических памятников. Л. «Наука», 1980. С. 36-39.



| кушымча төрләре | *а-* вариант | *ı*-вариант |
|---|---|---|
| чыгыш килеш кушымчасы | *-дан//дән, -тан//тән* | *-дыйн/дин, тыйн//тин* |
| йөкләтү юнәлеше кушымчалары | *-ар//әр* | *-ыр//ер* |
| | *-гар//гәр, -кар//кәр*<br>*-дар//дер, -тар//тәр* | *-гыр//гер, -кыр//кар*<br>*-дыр//дер, -тыр//тер* |

§36. Гаҗәп рәвештә, борынгы *а ~ ы* тәңгәллеге, безнеңчә, *кызган-мак ~ карган-мак* фигылендә чагыла. *Кызгану* сүзеннән ике мәгънәсе («берәрсенең авыр хәлдә булуын күреп, аның өчен ачыну» һәм «сораганны яисә сорамаганны бирмәскә теләү, бирәсе, сарыф итәсе килмәү») бары тик *каргану* сүзеннән генә килеп чыга ала (һәр ике мәгънә очрагында кеше кемнедер, нәрсәнедер каргый, каргана). Димәк, борынгы заманда *карган-мак* сүзеннән *кырган-мак* варианты булган (шуннан чывашча *хĕрхэн* – «кызганмак»); *кырган* – нигезеннән зетацизмлы телләрдә *кырган- > кызган-* варианты килеп чыккан:

→ чувашча *хĕрхен-*
qyryγan- > qyrγan-
→ төркетчә *ķызган-*

Бу шактый ышандырырлыклы этимология *r>z* күчешенә мисал вә дәлил булып тора (к. §51-52).

Бу тәңгәллекнең тагын бер киң чагылыш тапкан мисалы: кыргызча һ.б. *албар* мифик «утлы барыс» – көнчыгыш төрки (тува һ.б. телләрдәге) *ылбырс > илбирс, ирбис* «Себер барысы».

## КОНСОНАНТИЗМ

§36. Хәзерге татар әдәби телендә түбәндәге тартык авазлар кулланыла:

парлылар – *б, п; в, ф; г, к; ғ, қ; д, т; ж, ш; җ, ч; з, с;*
сонорлар – *й, w; л, м, н, ң, р;*
парсызлар – *х, һ.*

Аннары, язмада рус теленнән кергән сүзләрдә *ц* һәм *щ*, урта *к* һәм урта *г* авазлары очрый. Ләкин безнең темага алар карамый.

Башкорт телендә татар телендә булган *җ, ч* авазлары юк, тик интердентал *ҙ* һәм *ҫ* авазлары кулланыла. Калган барча фонематик авазлар татар һәм башкорт телләре өчен уртак. Әмма тарихи яктан караганда нәкъ менә консонантизм өлкәсендә татар һәм башкорт телләре арасында кискен тоталь һәм позицион аермалар күзәтелә.

§37. Татар телендә хәзерге көндә барча күрсәтелгән тартык авазлар диярлек сүзләрдәге барлык позицияләрдә фонема буларак куллаиы-

лалар; бары тик *–ң* авазы гына сүз башында кулланыла алмый һәм төп татар сүзләрендә сүз азагында (ауслаутта) *б, ғ* һәм *г* авазлары да кулланылмый.

Әйтелгән расламалар татар теленең характеристикасы өчен бик мөһим; ни өчен дигәндә, күп кенә төрки телләрдә тартык авазларның кулланылышында төрле позицион чикләүләр күзәтелә. Мәсәлән, күрше чуваш телендә сүз башында тик саңгырау тартыклар гына релевант ягъни фонематик мәгънәгә ия. Барлык тартыклар бу телдә интервокаль позициядә ягъни ике сузык арасында яңгырауланалар. Шуңа охшаша закончалыклар кайбер Себер төрки телләрендә дә күзәтелә. (Мәсәлән, алтай һәм хакас телләрендә).

Татар телендә төрләнеш процессында интервокаль позициядә торып калган *–п-, -ќ -* һәм *-к-* авазлары гына яңгыраулаша – алар урынына яңгырау парлары килә; *с, т, ф, ч, ш*авазлары исә яңгыраулашмый (чаг. *китап – китабы, казык – казыгы,* ләкин *тас – тасы, тазы* түгел! һ.б.).

§38. Элекке төрле язма ядкәрлекләрдә – гарәп хәрефләре белән язылганнарында бигрәк тә – вокализм үзенчәлекләре бик начар һәм төгәллексез чагыла. Еш кына *ы* һәм *е* авазлары берничек тә бирелмәгән – аларның барлыгын бөтен сүзне укыгач чамалап була; *о, ö, о, ө, у, ү* сузыклары барысы бер хәреф *уау* белән белдерелгәннәр; *ә* авазы да борынгырак текстларда фәтхә белән генә белдерелгән (ә өчен махсус хәреф бик соң гына кереп киткән) һ.б. Рус хәрефләре белән язылган ядкәрлекләрдә *у, ү* һәм *о, ө* – барысы да *у* яисә *ю* белән генә белдерелгәннәр һ.б. Шуңа күрә язма ядкәрлекләр буенча татар-башкорт вокализмының тарихын эзмә-эз билгеләп бару кыен.

Ә менә тартык авазлар гарәп хәрефләре белән бик төгәл биреләләр. Рус хәрефе белән язылган элекке (XV-XIX гасырлардагы) текстларда андый ук төгәллек булмаса да, нинди аваз язылганлыгын һәрвакыт диярлек чамалап була. Латин хәрефләре белән язылган элекке язуларда да әхвәл шундый.

Шуңа күрә татар теленең консонантизмы тарихын язма ядкәрләргә карап тәнәйтеп була (нинди язма ядкәрлекләр барлыгын без беренче бабта күрсәтеп үткән идек – Р.Ә.).

Борынгы ядкәрлекләрдән татар теленә иң якын телдәгеләре, беренчедән, атаклы «куман мәҗмагасы» – Codex Cumanicus – Алтын Урда чорында XIII гасыр башларында куманнардан-кыпчаклардан язып алынган һәм куманнар өчен язылган төрле текстлар җыентыгы, икенчедән, монгол яулары алдыннан – XII гасырның икенче яртысында хәзерге Казахстан һәм Үзбекистан туфрагында яшәгән төркиләр телендә язылмыш дини эчтәлекле шигырьләр – Әхмәт Яссәви һәм Сөләйман



Бакыргани әсәрләре. Боларга тагын язылу урыны һәм датасы бик үк билгеле булмаган бер сәеррәк ядкәрлек – «Угызнамә»не өстәргә була.

Шуны әйтергә кирәк ки, нишләптер, XII гасырда язган Ә.Яссави һәм С.Бакыргани теле татар гомумхалык теленә шактый якын булып та, XIII гасырда һәм Алтын Урда чорында язылган әдәби әсәрләрнең теле шактый катлаулана, аларга күпләп угыз һәм гарәп-фарсы элементлары керә башлый («Йосыф китабы», Сәиф Сараи, Котб һ.б. әсәрләре).

§39. Әхмәт Яссави теленең фонетикасындагы тартык авазлар составына тулысынча татар әдәби теленекенә туры килә дип әйтеп була. Бер үк сүз нигезләрендә Ә.Яссави телендә дә, татар телендә дә бер үү тартык авазлар кулланыла. Ә уртак сүзләр, уртак фразеологизмнарга килгәндә, алар татар теле белән Ә.Яссави теле арасында нәселдәшлек бәйләнешләре булуына шик калдырмый. Ә.Яссавинең кайбер шигырьләрен алып, моны XX гасыр башында бер татар әдибе язган дисәң, моңа бик ышанып була, мәсәлән:

*Гариб, фәкыйрь, ятимнәрне кылгыл шатман,*
*Хаклар кылып газиз җаның, әйлә корбан,*
*Тәгам тапсаң җаның белә кылгыл ихсан*
*Хактан ишетеп, бу сүзләрне әйттем менә!*
*Бәндә булсаң минминлекне, зинһар ташла,*
*Сәхәрләрдә җаның кыйнап, танмый эшлә.*
.................................................................
*Йөз мең гөнаһ садир булды – белелмәдең,*
*Тәүбә кылып, дәргаһыга киләлмәдең,*
*Хезмәт кылып, яхшы дога алалмадың,*
*Гашыйклардин сине ни дип сива кылсын?*[43]

Бу юлларда татар әдәби телен яхшы белгән кеше өчен аңлашылып бетмәгән ике генә сүз бар: *садир (бул-мак)* килеп чыкмак, *сива (кылмак)* – аерып карамак, аеруча хөрмәт итмәк. Андый гына ят сүзләр моннан сигез-тугыз йөз еллар элек һәм Урта Иделдән ике мең чакрым ераклыкта ислам идеологиясен пропагандалаучы кеше телендә бөтенләй булмаса, гаҗәп булыр иде. Анысы гаҗәп түгел, татар әдәби теленең лексик һәм синтаксик сөлтәрен тәшкил иткән меңнәрчә фразеологизмнар, йөзләрчә фразеосхемалар (*ни дип* фразеосхемасы үзе генә ни тора!) сигез йөз елдан артык саклануы гаҗәп.

Шуның белән бергә Яссәви морфологиясендә кыпчаклык билгеләре юк диярлек.

§40. «Кодекс куманикус» («Коман мәҗмүгасы») теле көнбатыш кыпчак (карачай-балкар, караим, урум, кырым, кумык) телләре

[43] Әхмәт Яссави шигырьләре татар нәшриятларында Октябрь революциясенә чаклы күп тапкырлар нәшер ителгән.

группасына һәм татар теленең мишәр диалектына якын. Бу телдә кыпчаклыкның бөтен фонетик һәм морфологик билгеләре бар:

| | |
|---|---|
| *Узун агач башында* | *Озын агач башында* |
| *Улу битив битидим,* | *Олы бетү бетедем,* |
| *Кэнсэн овлум кэлгэй, дэп,* | *Көтеп, улым килгәй, дип* |
| *Кэнсэн туруп сакладым* | *Көтеп торып сакладым.* |
| *(Ол кармак билә балыкдыр).* | *(Ул кармак белән балыктыр).* |
| | |
| *Авә, ужҗмакның кабагы* | *Аве (котлау сүзе), оҗмахның капкасы –* |
| *Тириликниң агачы!* | *Терелекнең агачы.* |
| *Йэмишин бизгә тейирдиң* | *Җимешен безгә тиердең* |
| *Йэсусны качан туырдың.* | *Йесусны кайчан тудырдың.* |
| *Туурдакы кыз көксинэ* | *Тудырасы кыз күкрәгенә* |
| *Көкниң цыгы түшүп кирә.* | *Күк чыгы төшеп керә.* |
| *Миндиң һачка, ким биз дэ минэли,* | *Меңдең хачка, кем безгә дә менмәле,* |
| *Сөүдин бизни, ким сэни сөэли,* | *Сөйдең безне, кем без дә сөймәле,* |
| *Дүнйаны унутуп.* | *Дөньяны онытып.* |
| *Каның төктүң, ким биз йууналы,* | *Каның түктең, кем без юынмалы* |
| *Эмгәк тарттың, ким биз арыналы,* | *Имгәк тарттың, кем без арынмалы,* |
| *Йазыкларны койуп.* | *Языкларны куеп.* |

Монда *дэп* «дип» сүзе (*тэп* түгел!) Әхмәт Яссави һәм татар теленә, аннары көнбатыш кыпчак телләренә хас яңгыраштa (*чаг.,* башкортча *тип*). *Кабак* «капка» көнбатыш кыпчак телләренә һәм мишәр диалектына хас сүз. Целәштерү (*агацы* «агачы»), йеләштерү (*йәмиш* «җимеш») *сәү-мәк* «сөймәк» мишәр диалекты билгеләре; *-алы//әле* грамматик форманты да мишәрләрдә очрый (*керәле дә чагалы*).

«Кодекс куманикус» теле, исеменнән күренеп тора, куманнар (половецлар) теле ул. Шуңа карамастан кайбер рус телчеләре бу телне көнбатыш Батый монголлар белән килгән төркиләр теле дип исбатламакчы булалар. Тик монда шунсы да аңлашылмый кала – каян килде икән шулчаклы кыпчак илаты, шуңарчы кайда яшәгәннәр соң алар? Көнчыгышта XIII гасыр башларына кайда да булса күпсанлыы кыпчак халкы яшәве турында тарихи мәгълүматлар юк!

Шуны әйтергә кирәк, үзендә ярылып яткан кыпчак вә мишәр үзенчәлекләре булган Кодекс куманикус телендә дә Әхмәт Яссави теле белән уртаклыклар күп. Һәм ике ядкәрлек теленә (куман мәҗмугасындагы целештерүне исәпкә алмаганда) борынгы консонантлар составының үз функциясендә (бер үк сүзләрдә үзгәрмичә) саклануы хас. Мәдәни һәм әдәби лексиканың төп өлеше һәр ике ядкәрлеккә уртак дип әйтеп була. Безнеңчә, куманнар X-XII гасырларда ук Урта Азия төрки мәдәниятенең көчле йогынтысын кичергәннәр. Кодекс куманикус телендә Урта



Азия һәм татар тел вә диалектларында булган *җинс* «җенес», *һәйбәтле* «мөһабәт», *тәрәзү* «таразы (көянтәле «зур үлчәү»)» кебек гарәп вә фарсы сүзләре белән беррәттән Урта Азия телләрендә булып та татар телендә булмаган *мих* «кадак», *лаиһ* «каршы» һ.б. *гарәп-фарсы* сүзләре очрый.

Әхмәт Яссави телендә дә, куман мәҗмугасында да, татар телендәге шикелле, *ул* алмашлыгы кыек килешләрдә һәм сүз ясалышында да *ан* нигезе белән алмаштырыла: *аның, ангар ~ анар һ.б. (чаг.* башкортча *уның, уга,* үзбәкчә *униң, уңга һ.б.).*

Китерелгән (һәм башка) фактлар шуны күрсәтә – X-XII гасырларда ук Аму-Дәрья вә Иртеш буйларыннан алып Чулманга һәм Дунайга кадәр мәдәни бер уртак тел шәйләнә башлаган һәм ул уртак телнең фонетик (һәрхәлдә консонант) нормалары татар теленекенә якын булган. Бу фонетик якынлыкка лексик составының гаять зур өлеше, грамматик формаларның функциональ үзенчәлекләре, күпсанлы фразеологизмнар һәм фразеосхемалар уртак булу да өстәлгән.

§41. Хәзер инде *якыннан-еракка* принцибы буенча арытабан барып, борынгырак язма ядкәрлекләрне, татар теле элементларының аларда булган элгәрләрен карап үтик.

Язма ядкәрлекләр (руник язулар һ.б.) һәм, бигрәк тә эчке реконструкция (лингвистик тәнәйтү) процедуралары күрсәткәнчә, борынгы баба төрки телләрдә аерымланып бетмәгән *б/п, г/қ, г/к, д/т, з/с, ш, д/т, т, қ* тартыклары һәм *й, л, м, н, ң, нй (ñ)* сонорлары гына булган. Сүз башында тик саңгырау тартыклар гына кулланылган. Иҗекләр һәрвакыт диярлек ачык булгач, тартыклар белән тартыклар янәшмәгән һәм шунлыктан *ассимиляция-диссимиляция* күренешләре дә булмаган.

VII-VIII гасырлардан калган руник язмаларда без инде шактый үсеш алган тел белән очрашабыз. Бу телдә дә сүз башында *(анлаутта) б-, к-, ц-, м-, с-, т-, ч-* һәм *й-* авазлары гына килә[44]. Шулардан *б-, м-* һәм *ч-* авазлары икенчел – соңрак нормага кергән авазлар булса кирәк (хосусан алганда *б-* һәм *м-* авазлары борынгы анлаут *п-* урынына үсеш алганнар, *ч-* исә йомшак *т-* дан килеп чыккан); *й-* турында сүз түбәндәрәк.

Борынгы язма төрки тел (VII-VIII гасырлар) белән чагыштырганда татар консонантизмының түбәндәге аермалы үзенчәлекләре мәгълүм була:

а) татар телендә тартык фонемалар саны арткан – *в, ф, ж, җ, х, һ, w* фонематик берәмлекләре пәйда булган;

[44] А.Н.Кононов. Грамматика языка тюркских рунических памятников. Л., 1980. С.62-65.

б) татар телендә (-*ң* авазыннан башка) тартык авазларның кулланылу позицияләре чикләнми; шунлыктан яңгыравык *ғ, г, д, ж, җ, з,* шулай ук сонор *л, н, й* һәм *w* авазлары да сүз башында кулланыла; *р-* (*r-*) авазы гади сөйләмдә – гомумхалык телендә кулланылмый килгән (шуңа күрә *ёрәт,* «рәт», *ёрәхәт* «рәхәт», *ёриза* «риза») һәм түбәндләге халык җыры пәйда булган:

*Кулымдагы җөзегемнең*
*Исемләре Әрәфкәт;*
*Җырак җулны җакын итеп*
*Килеweңә ёрәхмәт.*

Ләкин XX гасыр башларында әдәби тел тәэсирендә һәм җирдә диярлек *рәт, рәхмәт, рәхәт* һ.б.ш. әйтелешләр таралган;

в) татар телендә сүз нигезләре азагында *–ķ, -к* һәм *–п* авазларының (мәсәлән, тартык кушымчалары кушылганда) ике сузык арасын *а* калганда яңгыраулашу законы пәйда булган;

г) татар телендә *нй* фонемасы инде кулланылмый;

д) татар телендә төп төрки сүзләрдә *ғ* һәм *г* авазлары ауслаутта (һәм гомумән иҗек азагында) киләлми; *баг, бағланыш, сағлам* кебек сүзләр бүтән әдәби-язма төрки телләрдә алынган.

Тартык авазлар составының киңәюе, бары, бу авазларның кулланыш позицияләренең артуы барча бүгенге төрки телләргә хас. *Ķ /к* һәм *ғ /г* авазларының күрсәтелгән кулланылыш үзенчәлекләре кыпчаклык галәмәте.

Шулай итеп, татар теле борынгы төрки язма телләргә нисбәтән бүтән төрки телләрдән (бигрәк тә кыпчак телләреннән) бигүк аерылмый кебек. Ләкин чынлыкта әхвәл бераз башкачарак.

Татар теленең консонантизмы борынгы язма руник төрки телләргә ике җәһәттән аеруча якын:

а) борынгы тел белән уртак сүзләрдә татар телендә, кайбер позицион үзгәрешләрне исәпкә алмаганда, борынгы тартыклар составы үзгәрмичә саклана;

б) борынгы язма телдәге кебек татар телендә дә *ассимиляция-диссимиляция* күренешләре кайбер кушымчалардагы саңгырау тартыкларның яңгыраулаушуы белән чикләнә;

в) борынгы сингармонизм закончалыклары татар телендә тулысынча саклана.

Аерым төрки телләр (мәсәлән, уйгур теле) әйтелгән җәһәтләрнең берсе яисә икесе буенча борынгы язма руник төрки телләргә татар теле кебек үк якын яки, хәтта, бераз якынрак та булырга мөмкин. Ләкин барча бу мөһим өч линия буенча да бер тел дә борынгы язма төрки телгә



татар теле кебек якын түгел. Бу хәл татар теле тарихы турындагы-туры борынгы язма телләр тарихына ялганганлыгына дәлил.

§42. Инде аермаларның, бигрәк тә татар телендә күптән булынып та, руник язма телдә булмаган тартык фонемаларның каян килгәнлеге мәсьәләсе алга баса.

*В-ф пары.* Бу ике фонема борынгыы гомумтөрки телдә дә, моннан мең ел элекке төркет төрки телләрендә дә булмаган булса кирәк.

Руник хәрефләр арасында *в* һәм *ф* авазларын белдергән хәреф юк. Мәхмүт Кашгари сүзлегендә инде һәр ике аваз төрки сүзләрдә дә бар, алар еш кына борынгы *б* яисә *ғ* һәм *г* урынына киләләр. Шуннан бирле *в* һәм *ф* гомумтөрки *б, ғ, г* – гомумкыпчак *w* урынында угыз һәм уйгур телләре группаларында очрыйлар (бу телләргә *w* авазы ят – хәтта гарәп алынмаларында да, гарәпчәдә *w* булса да, ул *в* белән алмаштырыла). Урта Азия һәм угыз-төрки телләрендә *в* һәм *ф* авазлары, гомумән, күпсанлы фарсы, сугди, тохри һ.б. телләрдән килгән алынмалар белән кереп урнашканнар булса кирә.

Кыпчак телләренә *в* һәм *ф* кереп урнаша алмаганнар һәм сөйләм телендә алар соңгы гасырдарга кадәр булмааган. Татар һәм башкорт телендә гади сөйләмдә *в* русча белмәүчеләр телендә һәрдаим *б-* яисә *w* авазлары илә алмаштырылып килгән (мәсәлән, *вор>бур, вагон>багун, вот> wәт* һ.б.). *«Ф»* авазы исә, гомумән, татар телендә күптәннән бар: чөнки бу аваз гарәп һәм фарсы телләрендә бик еш кулланыла һәм күп кенә гарәп-фарсы алынмаларында *ф-не* бозып әйтергә һич ярамый (Коръән аятьләрендә, мәсәлән, *ма фис-сәмавәти wә ма фил-арз* «күкләрдә дә вә җир өстендә дә юк» дигәндә *ф* бозып әйтелсә көферлек килеп чыга). Шуңа да карамастан «кара халык» телендә *«ф»*авазы *п(р),* хәтта *б(b)* авазы белән алмаштырылып килгән һәм килә. Мәсәлән, асылда мәҗүси ырым сүзе булган *минем кулым түгел – Әйшә-Батман кулы* дигән җөмләдә *Әйшә* соңгы сөекле хатынының – *Гаишә*нең исеменнән, ә *Батман* Мөхәммәт пәйгамдәрнең кызы *Фатима* исеменнән бозылган.

Хәзерге әдәби татар телендә «ф» авазы гарәп-фарсы һәм рус сүзләрендә генә түгел, төп төрки сүзләрдә дә кулланыла, мәсәлән, *йефәк* [<jipäk – йеп «җеп» сүзеннән], *туфрак* [<toprak<toburγaq], *йафрак* [<japraq<jalburγaq], *уфтанмак* [<owtanmaq<obutanmaq, борынгы obut «оят» сүзеннән], *җилфердәмәк < җилбердәмәк, уфырмак* һ.б. Болар рәтенә кайбер төптә – «үзләрендә» *ф* булмаган алынмалар да керә: *калфак<калпак* [< ирани källapak «башкаплагыч» сүзеннән дип карала], *зифа* [<фарсыча *зиба*], *җофар* [төрки-фарсы јуу par «мускуслы мәче»]. Шуннан тагы *ф* кайсы телдә килеп чыгуы бәхәслерәк булган *кафтан* [<<төрки qap ton], *сарафан* [<<фарсыча *сәру-пай* яисә *сәрбанд* «озын баш яулыгы»] сүзләре дә бар. Диалекталь сөйләмдә *ф>п* күчеше

(*Гафифә>Әпипә, Фәварис>Паwарис, өлфәт>олпат* һ.б.) белән беррәттән әдәби телдәге п- авазлын да *ф*-кә күчерү күзәтелә (*пәрдә>фәрдә, пәри>фәри, җибәр, җиббәр>җиффәр* һ.б.).

Мәзкүр *ефәк, зифа, йафрак, туфрак, уфтанмак* кебек сүзләр Урта Идел регионында килеп чыкмаганнар – алар Урта Азияя төркиләре теленнән (мәсәлән, Алтын Урда сорында) телдәнге аралашу яисә китап (Әхмәт Яссәви, Сөләйман Бакыргани һ.б. әсәрләре) теле аша татар әдәби һәм халык теленә килеп кергәннәр.

Төрки сүзләрдә *ф* авазының пәйда булуы *п* авазы һәм аның тарихы белән баглы.

Борынгы төрки язма телдә *п* авазы сүз уртасында – еш кына интервокаль позициядә (*апа-таркан, апар*) һәм азагында (*алп*) кулланыла, ләкин сүз башында очрамый диярлек (алынма сүзләрдә генә килә). Ләкин хәзерге Синьцзянда җирләшкән яңа уйгур телендә күп кенә очракларда *б>п* күчеше килеп чыккаан (субстрат тәэсирендә булса кирәк). Шул уйгур теленең тәэсире буларак, кайбер төрки телләрдә, шул хисаптан татар телендә дә, п-гә башланган бер төркем төрки сүзләр калган: *паллама, пеш-мәк, пешер-мәк, пот* (Будда), *почкак, почмак, почык, пош-мак, пычкы, пышлак* һ.б.ш. (чагыштыр: башкортча *беш-мәк, бос-мак, быскы* һ.б.). Һәм бу күренеш уйгур теле аша кергән гарәп-фарсы алынмаларында да күзәтелә: *пырак>* гарәпчә *бурак* (гарәп телендә дә *п* юк!), *питрач < фитыр ачысы* (чагыштыр: үзбәкчә *пәтир «әче камыр*), *пута* (фарсыча *фута)* һ.б.

Төр төрки сүзләрдә *–п* авазы (*-қ* һәм *–т* белән беррәттән) *л* һәм *р* сонор тартыкларын алдан (к. башкортча һәм күп кенә бүтән телл»рдә *тупрак, япрак,* татарча *чүпрә* <чөбэрәч> русча *чебурек* «әче камырдан пешерелгән ашамлык») яки, күбесенчә, арттан «чикләү» өчен кулланыла (к. *салпы, сүлпән, талпа, талпан, толпар/тулпар, талпынмак, тилпенү, җилпенмәк, чалпу, чәлпәк, чулпан, чулпы, элпә; арпа, керпе, курпы, сарпат, сирпемәк, тырпа* һ.б.). Төрки сүзләрдәге *ф* авазы да татар телендә еш кына шул позициядә үк килә: *җилфердәмәк, керфек* һ.б.

**Ж авазы**. Бу аваз татар телендә һичкайчан бик актив кулланылмаган, әмма ул күптәннән бирле билгеле булса кирәк. Башкорт телендә, шулай ук казахча *ж* авазы бүтән телләрдәге *җ* авазын субституцияләү өчен еш кулланыла: димәк, ул кыпчак телләренең нииндидер субстратында булган.

Татар гомумхалык теленә бу аваз әдәби-язма телдән кергән дип уйларга нигез бар: ул фарсы телендә дә, рус телендә дә шактый актив кулланыла һәм шул телләрдә алынган сүзләрдә берни белән дә алмаштырылмый, мәсәлән, *аждар, жәл, жирәбә*һ.б.ш. Саф төрки-татар сүзләрендә *ж* авазы башлыча тәкълиди сүзләрдә (мәсәлән, *гөж итү, жу итү, жулау, ыжылдау* һ.б.) очрый. *Жумба* (балык атамасы) сүзе финн-угор телләреннән кергән булса кирәк. Хәзерге телдә үзендә *ж* авазы булган сүзләрнең күпчелеге рус теленнән соңгы гасырдагы алынмалар (*дежур, жандарм, жетон, жулик, журнал* һ.б.) һәм рус теленә алар еш кына француз теленнән кергән булып чыгалар. *Ж* авазы булынган саф рус сүзләреннән *уже, даже, абжур (<обжора), жулап (*<желоб) һ.б. гади сөйләмдә кулланыла.



Татар теленең кайбер сөйләшләрендә сирәкләп читтән килгән *ж* авазын *җ* белән алмаштырырга теләү сизелә, мәсәлән, ул *аҗдаһа (*<фарсыча *аждаһа*), *тәҗе (*<русча *тяж*) сүзләрендә күренә. Бу хәл *ж* авазының татар телендә соң гына карарлашкан булуы турында сөйли. Әмма күрше башкорт һәм чуваш телләрендә (соңгысында – *ш* фонемасының ике сузык арасындагы аллофоны буларак) бу аваз күптән килә.

***Ж(ʐ)* авазының тарихы.** *Ч* авазының яңгырау пардашы борынгы язма ядкәрлекләрдә кулланылмый – татар телендәге сүз башы (анлаут) *җ(ʐ)* урынында анда *j- (й-)* кулланыла *jer* «җир», *jetmek* «җитмәк», *jojmaq*, *jojumaq* «җуймак» һ.б. Сүз уртасындагы һәм сүз азагындагы *җ* борынгы гомумтөрки телдә булмаган. Хәзерге кушымчалардан *–ч(č)* авазына башланганнарының яңгырау авазга *(җ*-гә) башланган парлары юклыгы да (к. §20) шуны күрсәтә. Хәзерге татарчадагы *баҗа, боҗра, гуҗ, калҗа, канҗыга, кинҗә, кыҗрамак, таҗ, хуҗа* һ.б. сүзләр ул заманнарда бөтенләй кулланылмаган.

Югарыда, төрки телләр классификациясе мәсъәләләренә баглап, без борынгы сүз башындагы *ʐ* авазының чагылышы, рефлекслары һәм тәңгәллекләре турында сөйләдек инде (§12). Борынгы бер төркем төрки (башлыча кыпчак) телләрендә аңлау *–d'* (*дй*) ж-авазына, күпчелек (шул хисаптан кайбер кыпчак) төрки телләрендә *j* – (й-) авазына әверелгән. Татар теленең урта диалектларында шул позициядә тотал *җ*- кулланылып килгән (*җазу, җаман, җөри*), көнбатыш (мишәр) һәм көнчыгыш (Себер) диалектларында, шулай ук башкорт телендә тотал *й*- кулланыла (*йаман, йыр, йер*). Татар әдәби телендә мәгънә аеру кирәклегенә карап *й*-дә, *җ*-дә була ала (*җан, җаным*, ләкин *ян, янында* һ.б.).

Татар телендәге иңлаут һәм ауслаут *җ* авазы:

а) мәдәни алынма сүзләрдә очрый: *таҗ, хуҗа* – фарсычадан, *гаҗәп, гуҗ, әҗер* – гарәп теленнән;

б) аерым позицияләрдә (ике сузык арасында, сонор тартыклар, бигрәк тә *р*- янында) элекке *ч*- яңгыраулашкан булып чыга: *баҗа<абаача, кинҗә<кейинчә, кәҗә<кечә, кыҗрамак< кычырамак, морҗа<мурича*);

в) монгол алымнарында очрый: *канҗыга, әгерҗе* (варианты – *игәрче*), *тоҗын* һ.б.

г) рус алымнарында русча *з-* урынында (*кәҗүл<козёл* «күн сорты», *кәҗүнни<казённый, рәҗе<разве*) һәм сонор тартыклар янындагы *й*-не алмаштырып килә: *жалованье>жалунҗа, Макарьев>Мәкәрҗә, Марья>Марҗа.*

***w* авазы**. Бу авазның теге яки бу төрки телдә булу-булмавы бик мөһим классификацион хасият. Авазлар составында *w* булу – кыпчаклык билгесе. Һәм, безнең фикеребезчә, кыпчак телләренең фонетик үзенчәлекләре шул *w* авазыннан башлана да.

Галимнәрнең фикеренчә, кыпчак халыкларының (ләкин конкрет бер кыпчак дип аталмыш борынгы кабиләнең генә түгел) бабалары – динлиннар. Алар башта төрки телдә сөйләшмәгәннәр. Һәм аларның әүвәлге телләрендә иҗек азагында «*γ*» һәм «*g*» авазлары килә алмаган, ләкин билабиаль *w* авазы еш кулланылган. Динлиннар иҗек азагындагы *γ*(*г*) һәм *g*(*г*) авазларын *w, j* һәм *q, k* авазлары белән алмаштырып, яисә төшереп, үз акцентлары илә сөйләгәннәр. Нәтиҗәдә *baγ>baw, taγ>taw* һәм башка сүзләрдә *γ>w* күчеше пәйдә булган; вокализмы алгы рәт булган сүзләрдә исә күбесенчә *g>j* күчеше күзәтелгән (*bey>bej*). Шул ук вакытта борынгы кыпчак кабиләләре телендә ике сузык арасында калган *p, q* һәм *k* авазлары үз рәтенчә, *b, γ* һәм g авазларына күчкән (*baqun->baγun-, saqyn->saγyn-, tapyn->tabyn-, tükäl>tügäl* һ.б.). Кыскасы, борынгы төрки телләрнең фонематик авазлар составына *w* авазын кертеп, бу яңа өстәмәне төрлечә реализацияләгәннәр. Арсеналда бер аваз арттыру тирән структур үзгәрешләргә китергән: *q>γ//γ>w; k>g,j//g>w.*

Угыз һәм уйгур группасы телләрендә *w* авазы бүгенгә кадәр кулланылмый. Кыпчак телләреннән кергән сүзләрдә угыз һәм уйгур телләрендә сөйләшүчеләр *w* урынына *v*(*в*) яки *f*(ф) авазын әйтәләр (мәсәлән, *аулак* урынына *авлак* диелә һ.б.)

Борынгы иҗек авазындагы *-γ* һәм *-g* кыпчак телләрендә еш кына төрле җирдә төрлечә алмаштырылган. Нәтиҗәдә бер үк борынгы сүз кыпчак кабиләләрендә берничә рефлекс (филиация) биргән һәм бер сүздән ике, хәтта өч сүз килеп чыга алган, мәсәлән:

кыпчак диалектларында (татарча)
борынгы *aγdar-mak* → *аудар-мак*
→ *актар-мак* булып тармакланган
борынгы *baγ* → *бау*
→ *бай, бәй* рефлексларын биргән.

**X һәм h авазлары**. *X* авазы күп төрки телләрдә – Себер төркиләрендә (бигерәк тә Тувада), кайбер кыпчак диалектларында, әзәрбайҗан, һәм чуваш телләрендә тоталь яисә позицион рәвештә *г, ғ к* һәм *қ*



авазларын алмаштыргалый. Еш кына ул *x* фонемасының *h* аллофоны була. Без ул телләрдәге *x* һәм *h* авазларын, аларның килеп чыгышын, кулланыш үзенчәлекләрен һ.б. тикшерүне өстебезгә алмыйбыз.

Татар теленең кайбер Себер сөйләшләрендә дә *к,>х* чиратлашуы бар, ләкин ул бик соңгы күренеш – угор субстратының йогынтысы булса кирәк[42].

Татар әдәби телендә һәм аның элгәрләрендә *x* авазы башлыча китап телендә яшәгән һәм шуннан таралган. Бер яктан Урта Азия төрки язма телләрендә үк *хан, хакан, ханым* сүзләре традицион рәвештә *x* белән язылып килгән. Икенче яктан *x* авазы гарәп-фарсы сүзләрендә бик еш очрый. Болар барысы да *x* авазының аерым фонема буларак халык теленә үтеп керүенә китергәннәр. Әхмәт Яссәви телендә *яхшы* сүзе кулланыла: ул сүз башта *якшык* «ягышлы» булып, ниндидер төрки тирәлектә *яғышығ >яхшы* яңгырашларын алган. Бу сүзнең әдәби телдә кулланылуы аның киңчә таралуына китергән. Татар теленә дә ул *яхшы* яңгырашында китап теленнән үтеп кергән (татар сөйләшләрендә һәм башкорт телендә *якшы*).

*Ахшам* сүзе, *охша-мак* фигыле һәм аның дериватлары турында да шуны ук әйтергә мөмкин.

Ләкин *ахшам, охшамак, яхшы* кебек үзендә дә *x* авазы булган саф төрки сүзләр татар телендә бик аз. *X* авазы башлыча гарәп, фарсы һәм рус алынмаларында очрый.

*Һ* авазы татар телендәге төрки сүзләрдә бөтенләй очрамый диярлек. Ул тик гарәп-фарсы алымнарында гына була.

Башкорт телендә *h* авазы тоталь рәвештә гомумтөрки һәм татар *с* авазы урынында кулланыла (*с* авазы исә гомумтөрки һәм татар *ч* авазын тоталь алмаштыра: *ч>с//с>h*).

**§43. Борынгы ñ (нй) авазының язмышы**. Борынгы руник язмаларда аерым билгеләнгән һәм шул чордагы телдә яхшы сакланган борынгы *ñ (нй)* авазы соңыннан бер шивәләрдә *j(й)* авазына, икенчеләрендә *n(н)* авазына әверелгән, ягъни:

*ñ* → *j*
*ñ* → *n*

Мәсәлән, борынгы *čyγañ* «ярлы фәкыйрь» сүзеннән бер шивәдә *čyγaj, čyjγaj, čıγaj* «фәкыйрь» сүзе калса, икенче шивәлдә *čaγan, čiγan* (татар сөйләшләрендә *чыйган*) «чегән» сүзе калган.

Татар (мишәр) сөйләшләрендә, чуваш һәм мари телләрендә кайбер сүзләрдә *нй* бүгенгә кадәр сакланган, мәсәлән, мишәр *кань* ~ чувашча *хунь* «кайнана яисә кайната» борынгы төрки *qañ* «ыру башы» сүзеннән булса кирәк. Чувашча *чохынь* «ярлы, гидай» сүзе дә мәзкүр *čaγañ* сүзеннән.

[42] Д.Г.Тумашева. Диалекты сибирских татар. Казань, Издательство КГУ. 1977. С. 166-170.

**§44. Ауслаут һәм иңлаут *j(й)* авазының чыганаклары**. Бүгенге татар һәм башкорт сүзләрендә иҗек азагындагы *j* һәм ике сузык арасындагы *j* (*й*) авазы гетероген (төрле чыганаклардан килгән) характерга ия. Беренчедән, ул борынгы *j* –дан килгән булырга мөмкин. Икенчедән, әйткәнебезчә, борынгы *ñ* (*нй*) авазыннан да татар телендә *j* (*й*) гына торып калган. Өченче һәм иң кызыклы чыганак – «җиде аваз рәте». Күп кенә сүзләрдә бер-берсен алмаштырып килә торган ул авазлар түбәндәгеләр:




Барлык җиде вариантта да килә торган сүзләрне табу хәзер кыен. Борынгы төрки сүзлектә (ДТС, 1969) тик бер генә сүзнең биш варианты килтерелә *kej~keδ~ked~ket* һәм *kez~kes* «ныклы, төпле, тынлы, нык; арт як»; борынгы *eδ* «күн, эшкәртелгән тире» сүзенең телләрдә сакланган *äj, är, it* һәм *is* вариантлары билгеле һ.б. һәм менә шул тәңгәллекләр рәтендә торган борынгы тамырлардан вә тамыр сүзләрдән татар һәм башкорт телләрендә гадәттә *j* вариантындагысы очрый: китерелгән мисаллар рәтенә татарча *кәй* «үсешендә артта калган, чибек, начар» һәм *әйбер* сүзендәге *әй* (бу сүз *әй* «күн товар» һәм *бир* «тукыма товар» сүзләреннән кәш, к. диалекталь *әйбир* – «әйбер»). Татар һәм башкорт телләрендәге интервокаль, сүз уртасындагы *й* авазы да еш кына шул «җиде аваз» рәтеннән килеп чыккан була, ягъни бүтән (башлыча борынгы һәм Себердәге) телләрдә аның урынына *r, δ, z, s, d, t* авазларының берсе очрый. Мәсәлән, *аю* (айыу) сүзендәге интервокаль -*й*- урынына *d, t, z, δ* килә ала: борынгы язма телләрдә *aдүү, aδүү*, якутча *amaax* «аю». *Аяк (айак)* сүзенең дә *adaq, aδaq* һәм *araq* (шуннан чувашча *ора>ура*) вариантлары булган. Монда шуңа игътибар итү зарур: интервокаль *j~δ~d~t~z~r~s* авазлары башта интервокаль булмаган, ә берәр тартык янында булган булуы да ихтимал, мәсәлән, *аю* сүзеннән борынгы язмаларда *aδүүү* варианты теркәлгән.

Башкорт телендә, шулай ук татар теленең кайбер (Себер, Әстерхан һ.б.) сөйләшләрендә *j(й)* авазы сүз башында гарәп-фарсы алынмаларындагы *ӡ(җ)* урынына куела, мәсәлән, башкортча һәм татарча диалекталь *йаза* "җәзә", *йафа* "җәфа", башкортча *Йәлил* "Җәлил", *йәмәӻ әт* "җәмагать", *йән* "җан" һ.б. Ләкин сүз уртасында һәм сүз азагында гарәп-фарсы сүзләрендәге *ӡ(ж)* авазы -*j*-(-*й*-) белән түгел, *ž(ж)* авазы белән алмаштырыла: мәсәлән, *ӻ аҗәп* (*ӻ айәп* түгел), *дәрәҗә* (*дәрәйә* түгел), *миграж* (*миграй* түгел) һ.б. әмма элекке төрки-монгол



сүзләрендә сүз уртасында да *j(й)* очрый, мәсәлән, монголча *тэлмэрчин ~ тәлмәрҗин* «дастан сөйләүче; җырчы» > башкортча *тәлмәрйен* «сайраучы бака (баканың бер төре)»; шулай ук башкортча *ынйы-мәрйен* ~ татарча *энҗе-мәрҗән*; башкортча *бөрйән* ~ татарча *бөрҗән* һ.б.

§45. Башкорт телендә *ч>с//с>h* эшалонлы күчерешләренең килеп чыгышы бүгенгә кадәр хәл ителмәгән мәсъәлә. Бу бабта хәзергә түбәндәгеләрне генә әйтергә мөмкин.

Беренчедән, күрәсең, башкорт телендә үзендә *җ-ч* авазы пары бөтенләй булмаган кыпчак телләре даирәсенә карый: ул даирәгә казах, нугай, каракалпак телләре керә. Һәм, ихтимал, мишәр вә Себер диалектларының элгәрләре кергәннәр.

Икенчедән, башкорт телендә -*ч* турыдан-туры -*с* авазына күчмәгән – ул -*ц* аша күчкән дип исәпләнә. Ягъни, *ч>ц>с* күчешләре булган.

Әгәр ул шулай икән, башкорт телендәге бу күчешләр ничектер – мишәр һәм Себер татар диалектларындагы *ц*-ләштерү (*ч>ц*) белән бәйле.

Өченчедән, *ч>ц//с>h* эшалоны күчешләре башкорт теленнән тыш (һәм уртак сүзләрнең барысында да) ерак бурят теленә хас. Һәм XIX гасырның башларыннан бирле башкорт һәм бурят телләренең бу гаҗәеп уртак хәсияте очраклы түгелдер дигән фикер әйтелеп килә.

§46. Сүз башында яңгырау тартынкылар килү мәсъәләсе – шактый катлаулы.

Борынгы төрки телләрдә сөйләм процессында сүзне сүздән аеру өчен гаҗәеп бер механизм пәйдә булган: сүз башында һәр даим саңгырау тартыклар, ә сүз азагында йә сонор авазлар (*л, н, ң, р* һ.б.), йә сузыклар килгән (шуңа охшаш закончалык кытай телендә дә бар). Яңгырау шаулы авазлар исә сүз уртасында, башлыча интервокаль позициядә очраганнар. Ягъни саф *б, г, з, д, ж, җ, з* авазлары сүз уртасын билгеләгәннәр. Алар мөстәкыйль фонема булмаганнар. әмма иң борынгы язма ядкәрлекләрендә бер сүз башында *b*-(*б*-) һәм *j*(-*й*) авазларын очратабыз. Ягъни гүяки сүз башында саңгырау тартык килү кагыйдәсе шуның белән кире кагылган. Ләкин бит язма ядкәрләр заманында инде инәкә төрки тел шактый бозылган булган. Безнеңчә, башта әлеге *б*- урынында саңгырау *п*- кулланылган, дөресрәге, сүз башында *b*-(*б*-) һәм *p*-(*п*-) бер фонеманың аллафоннары булган. Аңлаут *j(-й)* авазы исә борынгы йоталанган *t'(-тй)* авазыннан килә.

Иң борынгы фонетик система җимерелгән саен сүз башында яңгырау тартыклар килү ихтималы арткан. Билгеле бер чорда, ихтимал, монгол субстакты тәэсирендә угыз халыкларында башка тартык авазларның тоташ яңгыраулашыуы килеп чыккан. Ягъни *п>б, т>д, к>г, к>ү, тй>й* күчешләре пәйдә булган (әмма *с>з, ч>җ* күчешләре булмаган, чөнки -*з* һәм -*җ* авазлары үзләре карарлашмаган була).

Ләкин угызлар чагыштырма изоляциядә озак яши алмаганнар. Алар бик тиз бүтән төркиләр белән тыгыз контактка кереп, аралашып, бүтән төркиләрдән гадәти саңгырау тартыкка башланган сүзләр алганнар һәм үз сүзләрен бүтәннәргә йоктырганнар. Шул юл белән мәсәлән, төрек телендә *т*-гә башланган күпсанлы төрки сүзләр (*taban, tak-* «тагу», *tep-* «тибү» һ.б.), ә татар телендә кайбер сүзләрдә аңлаут *-д* пәйда булган (*дала, дан, ди, диңгез, дүрт, дулкын, дуадак, дүдәк, дөге, дөя*). *Д*-гә башланган кайбер сүзләр монгол теленнән кергән булса кирәк; шундыйларга *дага, дуга, дилбегә, дирбия, дуен, дүләнә, дүнән* (дүрт яшлек ат) керә. Әмма татар телендә «*д*»-гә башланган сүзләрнең гаять зур күпчелеге гарәп-фарсы сүзләре, мәсәлән, *дөнья, дәрья, дау, дәү, дүшәмбе, дус, дошман, дар, дару, дөрес* һ.б. Гарәп-фарсы сүзләренең кайберләре төптә (шул телләрдә) *т*-гә башланып та, татарчада *д*-гә башланган сүзләр рәтенә керәләр, мәсәлән, *давыл* (гарәпчә *табл* «гаять зур сугыш барабаны»), *дисбе* (гарәпчә *тасбих* сүзеннән). Бу сүзләр безгә угызлар аша килгән булса кирәк. Ниһаять, *д*-гә башланган кайбер сүзләр татар теленең үзендә пәйда булганнар, мәсәлән, *дәшү* (эндәшү өндәшү); *дерелдәү, дөбердәү, дөңгердәү* һ.б. тәкъвлиди сүзләр шундый. Аннары, кайбер сүзләр татар сөйләшләрендә *д*-гә башланып, әдәби телдә *т*-гә башлана, янсә, киресенчә, диалекталь сөйләмдә *т*-гә башланган сүз, әдәби телдә *т*-гә башлана, мәсәлән, *даган~таган, дары~тары, түнү~дүнү, тулкын~дулкын* һ.б.

Сүз башында *г(γ)* һәм *ғ (g)* килү очраклары турында да нәкъ *-д* турында сөйләгәннәрне кабатлап әйтеп чыгарга мөмкин. Ягъни алар составында угыз сүзләре бар, әмма күпчелекне гарәп-фарсы алынмалары тәшкил итә. Аннары, *г* һәм *ғ* авазлары татар телендә тамам карарлашкач, татар теленең үзендә дә *г* һәм *ғ* авазлары башланмыш кайбер сүзләр килеп чыккан (бигрәк тә бу хәл тәкълиди сүзләрдә күренә).

**§47. Морфологик ятышмауга мисал**: ***б~м* мәсъәләсе**. Төрки телләрдә күптәннән бирле *б*-телләре һәм *м*-телләре аерыла, ягъни кайбер телләрдә «*б*» авазы килгән урында икенчеләрендә «*м*» кулланыла. Гомумән, бу күренеш төп классификациягә ярашып бетми. Чөнки, сүз башында күпчелек төрки *м*- урынында *б*- кулланылу угыз телләренә хас:

| угыз телләре | уйгур телләре | гомум кыпчак | татарча һәм башкортча |
|---|---|---|---|
| *бән* | *мән, мэн* | *мэн* | *мин* |
| *бан-мак* | *ман-мак* | *ман-мак* | *ман-мак* |
| *буң* | *муң* | *муң* | *моң* |
| *биң* | *миң, мың* | *мин* | *мең* |
| *бэң* | *мэң* | *мэң* | *миң* |
| *бунда* | *мунда* | *мунда* | *монда* һ.б. |



«Б» телләр җөмләсенә тагын чуваш теле дә керә: анда *пусч<банч*, «-ман, -манчы», *пин<биң* «мен». Кайбер очракларда татар телендә дә башка кайбер телләрдәге башка *б-* урынына *м-* очратыла: *боз* (чаг. үзбәкчә *муз*).

Гомумән, сүз башында *б~м* тәңгәллеге чикләнгән санлы һәм башлыча бер үк сүзләрдә (югарыда китерелгәннәрдән) күзәтелә.

*Б~м* тәңгәленең икенче бер табышмаклы чагылышы - беренче зат күпчелек кушымчасының татар, башкорт, кыргыз, кумык, карачай-балкар, караим телләрендә *–быз//биз* (*без*), (сирәгрәк *бүз//буз*), алтай, шор, хакас телләрендә *–быс//бис* булып, иске татар (әдәби), уйгур, үзбәк, нугай, каракалпак, казах, гагауз телләрендә *-мыз-миз* (*мез*) (сирәгрәк *–муз//муз* булуы. Тарихи яктан *–быз//биз* варианты борынгырак булса кирәк: чөнки переферияль телләрдә (ә алардагы уртак һәм охшаш элементлар закончалыклы рәвештә борынгырак булучан) без әлеге аффиксның *б*-гә башланган вариантын күрәбез (палаталь пардашны китереп тормыйбыз): якутча *–быт* (*<-быс<-быз*); чувашча *–пыр* (*<-быр<-быз*), тувача *–выс* (*<быз*), угыз телләрендә (гагауздан башкаларында) *–ыз* (*<-выз<-быз*). Ләкин *-быз* варианты татар һ.б. телләрдә берлектәге формант *–м* (*-мын*) белән контраст, ятышмаучанлыкны китереп чыгара һәм бу хәл үзе татар һ.б. *-быз* телләрнең соңрак төрле элементлардан тәшкилләнүе турында сөйли. Бу хакта кайбер ачыкламалар *р~з* һәм *л~ш* тәңгәллекләре турындагы параграфларда, киләсе бабта бирелер.

## ДҮРТЕНЧЕ БАБ
## ИНӘКӘ ТӨРКИ ТЕЛНЕҢ РЕКОНСТРУКЦИЯСЕ

§49. Иң борынгы язма телләр дә тарихи ретроспентивада – чагыштырмача соңгы телләр. Теге яки бу телнең язма тел булып әверелүе – еш кына очраклы хәл. Бүгенге сөйләм теленең аерым элементлары яисә бөтен бер бүгенге тел яисә диалект тулаем алганда иң борынгы язма телдән дә күпкә борынгырак булырга мөмкин.

Сөйләм телендә борынгылыкның гаҗәеп сакланучанлыгын Һинд-Европа телләре материалы ачык күрсәтә. Борынгы (б.э.к. I меңъеллык) һиндча санскрит – «изге язу» дигән сүз (*сан* «изге», *скрит* «язу») һәм бүгенге Италиядә сөйләм телендә дә *сан скрит* «изге язу». Ә бит борынгы Һинд-Европа бергәлеге безнең заманнан кимендә биш мең ел элегрәк таркала башлаган һәм борынгы һиндләр (дөресрәге арийлар, һиндиранилар) иң беренчеләрдән булып әлеге бергәлектән аерылып чыкканнар. Исәпсез-сансыз тарихи давылларга карамастан, борынгы Һинд-Европа телендәге *сан скрит* (тел тарихлары бу сүзне *swänk skripto* дип тәнәйтәләр) сүзе үзгәрмичә яисә бик аз үзгәреп алты мең ел буе саклана.

Төрки язма тел V-VI гасырларда гына барлыкка килә. Билгеле, ул үзенең грамматик үзенчәлекләре буенча иң борынгы, инәкә (прото) төрки телдән шактый аерылып торган, шактый үсешкән, үзгәргән тел нигезендә корылган. Ул хәзерге төрки телләр белән иң борынгы гомумтөрки телгә кадәрге араның уртасындарак тора дип әйтергә була. Шуның белән бергә хәзерге кайбер төрки телләрдә руник язма телнекенә караганда шактый борынгырак аерым элементлар табылырга мөмкин.

Шундый ягъни үзендә бик борынгы элементлар сакланган төрки телләрнең берсе – татар теленә күрше чуваш теле.

Баштан ук шуны аерым-ачык әйтергә кирәк ки, чуваш телендә күп кенә борынгы элементлар сакланганлыктан чыгып, бу тел гомумән борынгы тел (аның барлык элементлары борынгы) дип әйтергә һич кенә дә ярамый. Һәм чынлыктан да, чуваш теле инәкә төрки, соңгы төрки (угыз вә татар) һәм финн-угор элементларыннан оешкан иң яңа төрки телләрнең берсе. Татар теле бөтенлекле бер система буларак чуваш теленнән өлкәнерәк һәм борынгырак, тик татар телендә чуваш теленеке шикелле уникаль үзенчәлекләр юк – ул урта, эталон төрки телгә якын.

§49. Фонетика өлкәсендәге чуваш телендә (һәм төрки телләрдән бары тик чуваш телендә генә) сакланган үзенчәлекләрнең берсе – гомумтөрки *з* һәм *ш* авазлары урынына күп кенә сүзләрдә *р* һәм *л* авазларын куллану[43].

Түбәндә без башта татар һәм чуваш сүзләре чагыштырып, *r (р), z(з)* тәңгәлләренең бу телләрдәге очракларын күрсәтәбез. Тикшеренүебез өчен кирәк булганлыктан татар сүзләренең гомумтөрки яисә борынгы төрки яңгырашлары, ә чуваш сүзенең фонетик үзгәреш закончалыклары нигезендә тәрәнәйтелгән формалары җияләр эчендә латин хәрефләре белән язылып күрсәтелә.

| Татар (<гомумтөрки һәм руник төрки) | Чуваш (<тәнәйтелгән яңгыраш) |
|---|---|
| *-аwыз (<aγyz)* | *счывыр* (<тәнәйтелгән яңгыраш: *jaγyz)* |
| *айаз (<ajaz)* | *уйар<ойар (<ajar)* |
| *аз- (<az-)* | *ур-< ар- (<ar)* |
| *балдыз (balduz* «яшь, житлекмәгән; балдыз») | *полдыр, пултăр* «хатынның кеше туганнары» |
| *бәз (<bez)* | *пир (<bir<ber)* |
| *без (<biz)* | *эпир (<ěvě bir)* |
| *биз (<bez)* | *пар (<bär<ber)* |
| *бозау (<buzaγu)* | *пыру (<byjraw)* |
| *бугаз (<boγaz, boγuz)* | *пыр (<byjr<bojur<boγur)* |
| *игез (<egiz)* | *йĕкĕрĕш (jĕgĕrĕsĕ),* |
| | *йыгырĕ* «игез сыңары» |
| *изү* «вырез для воротника» *(<egiz)* | *счырых (<зerex)* |
| *йозак (<juzγaq)* | *счыра (<зurγaq)* |
| *йолдыз (<julduz)* | *счылдыр (<зuldur)* |
| *йөз (<jüz) I* | *счĕр (<зөr<зür)* |
| *йөз (<jüz) I* | *счĕр (<зөr<зür)* |
| *йөзек (<jüzük)* | *счĕрĕ (<з* |
| *кайыз (<qajuz)* | *хуйыр (<qajur)* |
| *каз (<qāz)* | *хур (<xor<xar<qar)* |
| *казан (<qazγan)* | *хуран (<xoran<xaran<qaran)* |
| *каз-, казы- (<qaz-, qazy-)* | *хур- (<xor-<xar-<qary-)* |
| *казы (qazy-)* | *йур (<jor<jar<k'ary)* |
| *козан (<quzγan)* | *хĕрен (<xөrän<qorγan<qurγan)* |
| *коңгыз (<quηγur)* | *хымыр (xomyr<quηγur)* |
| *кондыз (<qunduz)* | *хынтыр (xondur<qunduz)* |
| *көз (<küz)* | *кĕр (kөr<küz)* |
| *көндез (<kündüz)* | *кынтыр (kondyr<kөnder)* |
| *көяз, күәz (<küjäz, küwäz)* | *кывар (<küär)* |
| *куз (<qoz, qooz)* | *кывар (quar<qoor)* |
| старотатарский *кукез* | *кыкыр (<көкөр<küküz)* |
| *кыз (<quz)* | *хĕр (xyr<qyr)* |
| *кызган- (<gyzγan-)* | *хĕрхен- (<xyrxan-<gyrγan-)* |
| *кыз- (<quz)* | *хĕр- (<xyr-<qyr-)* |
| *кызыл (<gyzγyl)* | *хĕрлĕ (<xyryl<gyrγyl)* |
| *мегез (<mügüz)* | *мыйыра (<müjüra<mügrägä)* |
| *озак (<uzaq)* | *вырах (<wuraq)* |
| *озын (<uzun)* | *вырым (<wurum<wurun)* |
| *өзәнге (<zängü)* | *йырана (<jөränĕ<j ürängü)* |
| *сагыз (<sagyz)* | *счыхыр (<зyγyr ?)* |
| диал. *саез (сайыз) (<sajyz)* | *суйыр (<sajyr)* |
| *саз (<saz)* | *шур (šor<šar<sar)* |
| *сез (<siz)* | *эсир (ěvě sir)* |
| *сигез (<segiz)* | *сакыр (<sägir<segiz)* |
| *сез- (<süz-)* | *сĕр- (sөr-<sür-)* |
| *сыз-I (<syz-)* | *шыр- (<syr- «майда кыздырмак»)* |
| *сыз-II (syz-)* | *чĕр- (čөr-)* |
| *сызган- (syzγan-)* | *шыхран (<šyrγan-<syrγan-)* |

[42] Әдәбият бай: к.Р.Г.Ахметьянов. Сравнительное исследование... С. 56-72.

| | |
|---|---|
| *сызгыр- (sysγyr-)* | *шыхыр- (syrγyr-)* |
| *сызла- (*диал. *сыз-) (<syz)* | *сур- (sor-<sar-)* |
| *тез (<tiz)* | *чер (tĕr<tir)* |
| *тоз (<tuz)* | *тоар, тывар (<tuyr)* |
| *тугыз (<toγuz, toquz)* | *тыхыр, тухыр (<toxur<toqur)* |
| *тыгыз (<toγuz)* | *тывыр (<tywyr<tyγyr)* |
| *угыз, ывыз (<oγuz)* | *ырра (<<oγuruγ)* |
| *утыз (<ottuz<oltuz)* | *вытыр (<<oltuz)* |
| *үгез (<ogüz<öküz)* | *выкыр, выгыр (<wĕgĕr<wögur)* |
| *үз (<öz)* | *вара, варă(<wörgü)* |
| *ызан (<yjran)* | *йыран, йĕрен (<yjran)* |
| *эз (<iz)* | *йĕр (<jir)* |
| *яз (jaz)* | *счур, счор (<зor<зar<jar)* |
| *яз- (jaz-)* | *счыр (<з yr-)*[44]. |

Болардан башка, чуваш телендәге *-r(р)* ле берничә сүзнең *z(з)*ле варианты бүтән төрки телләрдә табыла:

чув. *кĕрĕ* «көре» ~ борынгы төрки *küzäk*, уйгул *кузук* «көре»;

чув. *тар* «качмак» ~ бор. төрки *tez* - «качмак»;

чув. *тĕтĕр* - «төтәсләү» ~ бор. төрки *tütüz* - «төтәсләмәк».

Бу тәңгәллекләрне башта чуваш теленең сөер үзенчәлекләре дип кенә һәм ул чуваш теленең финн-угор (мари) субстракты тәэсирендә килеп чыккан дип уйларга мөмкин. Һәм кайбер галимнәр шулай уйларганнар да. Ләкин гомумтөрки (һәм татар) *z (з)* авазы урынына *r(р)* авазы килү очраклары, сирәкләп булса да, бүтән телләрдә дә күзәтелә. Иң беренче чиратта монда монгол теле материалы кызыклы: анда егермегә якын сүздә гомумтөрки з(*z*) урынына тәгаен *р*(*r*) килә.

| Чувашча | Монголча | Татарча |
|---|---|---|
| *аран (<arañ) «*аз*»* | *арай «*аз; көчкә*»* | диал. *аран «*көчкә*» (монг.)* |
| *вар (<wörü, wörgü)* («үзәк») | *öрö (<örü)* йөрәк тамыры | *үз, үзәк (<öz, özek)* |
| *вăкăр (выгыр) (<wögür)* «үгез» | *ухэр (<üker) «*үгез, *сыер»* | *үгез (<ögüz, öküz)* |
| *мыйрага (<mügrägä) «*мөгез*»* | *мүгэрэсүн (<mügresun) «мөгез»* | *мөгез (<mügüz)* |
| *пыр (<byjr<boγur)* «бугаз» | *боор (<boγur) «*бугаз*»* | *бугаз (<boγuz)* |
| *пыру (<byjraw)* «бозау» | *буру, бирагу (<buraγu)* «бозау» | *бозау (<buzaγu)* |
| *йĕкĕр - еш (<jĕgĕrĕsĕ)* | *ихэр (<ekkeri) «игез»* | *игез (<eguz, ekiz)* |
| *хуран<хоран (<qarγan)* | *карум (<qarγun)* «Казан» | *Казан (<qazan)* |
| *вăрăм (<wurun)* | *урту (<uz-tu)* «озын» | *озын (uz-un; uz «буй»)* |
| *йыранă (jürene) «өзәңге»* | *дүрүгэ (d'ürüge)* | *өзәңге (<üzängü)* |
| *пар (<ber)* | *бэр (<ber)* | *биз (<bez)* |
| *пăс - (татарчадан)* | *бори- (<buri-)* бор. монгол *eteri* | *боз-мак (<buz-)* диал. *әпиз* «басу, кыр» һ.б. |

[44] к. Рясянен М. Материалы по исторической фонетике тюркских языков. Изд.иностр.лит. М.-Л., 1955, с.153; Щербак А.М.. Сравнительная фонетика... с.55, 86; A.T. Tekin. Курс. Хезмәт, 93-96 битләр; Федотов М.Р. История чувашского языка, I... с. 83-86.



Монгол мисаллары тунгус-манъҗур телләрендәге берничә мисал белән тулыландыра алалар: чув. *хур<хор*, манъҗур. *кару* «аккош, каз» ~ гомумтөрки каз.

Китерелгән чуваш мисалларын Чыңгыз һәм Батый монголлары теленнән алынган дип уйларга нигезләр юк. Чөнки монгол телендә ротацизм мисаллары унбиш-егерме тирәсендә генә, ә чуваш телендә дүрт-биш тапкыр күберәк. Чыннан да монгол телләреннән кергән ротацизм мисалы итеп бер генә сүзне күрсәтергә мөмкин: чувашча һәм татарча (диалекталь) *аран* «аз, көчкә» ~ гомумтөрки *аз* (чуваш телендә бу сүз электән килгән булса *уран* яңгырашында булдырга тиеш иде.

Ротацизм мисаллары (күбесенчә чуваш теле материалы буенча таныш сүзләр) венгр телендә дә табыла:

| | | |
|---|---|---|
| венг. | *ökör* | (чув. *выгыр*, монг. *үхер*) ~ тат. *үгез*, |
| --“-- | *iker* | (чув. *йотер*, монг. *экэри*) ~ тат. *игез*, |
| --“-- | *borju* | (чув. *пыру*, монг. *бирагу, бурагу*) ~ тат. *бозау*, |
| --“-- | *harang* | «чаң, колокол» (чув. *хуран, хоран*, монг. *карум*) ~ тат. *Казан*, |
| --“-- | *ir* | (чув. *счыр-*) ~ гомумтөрки *йаз-мак*, |
| --“-- | *sar* | (чув. *шур< шор*) ~ гомумтөрки *саз, сазлык*. |

Чуваш телендә булмаган сүзләр:

| | | |
|---|---|---|
| венг. | *bor* | гомумтөрки *боза* «буза» |
| --“-- | *göreny* | тат. *көзән*; |
| --“-- | *sarkany* | нугай. *сазаган* «өермә, аждаһа»; |
| --“-- | *tenger* | гомумтөрки *тәңгиз* «диңгез». |

Борынгы Дунай болгарлары ядкәрләкләрендә *колобур* «кулавызм (җитәкче)».

Ротацизм мисаллары татар һәм бүтән төркет төрки телләренең үз эчләрендә дә күп кенә.

Татар теленең төрле диалектларында һәм сөйләшләрендә теркәлгән *кайыр ~ кайыз, коңгыр ~ коңгыз, коран ~ козан* (козгын сыман кош), *кубыр ~ кубыз, кур ~ куз, (балык) сөрмәк ~ (балык) сөзмәк* сүзләрендә *р ~ з* күзәтелсә кирәк. Телара мисалдан *беләрек ~ беләзек*, татарча диалекталь *таңгырмак* ~ чыгтайча (Галишир Нәваидә) *таңгызмак* «таң калмак», борынгы төрки *тангырка-мак* ~ чыгтайча *таңгызга-мак* «гаҗәпсенмәк» кебекләрне китерергә мөмкин.

Гомумтөрки характердагы *күрмәк – күз, симермәк – симез* сүзләрендә уртак тамырда *р ~ з*.

Кайбер төрки телләрдә *бармар – бармаз* (бармас), *күрмәр – күрмәз* (күрмәс) шикелле тәңгәллекләр булгалый. Чувашта *мар* «түгел (не)» < болгарча **мәр* < борынгы төрки *эмәр<эрмәр* «булмас, имәс» сүзеннән килсә кирәк.

Татар-башкорт телендә һәм башка телләрдә *үткәр- ~ үткәз- ят-кыр- ~ яткыз-, тигер- ~ тигез-* кебек вариантлашу мисаллары аз түгел.

Борынгы төрки язма телләрдә *gyrγa- ~ gyzγa* «каргамак» пары теркәлгән. Башкортча (эпос телендәге) *мауз* (манголча *мангус*) «аждаһа, шайтан» сүзенең борынгы төрки язма телдәге тәңгәле *manir, maŋir* h.б.

§50. Шулай итеп, башлыча күпчелек төрки телләрдә *йөз бир*, очрактагы *з(z)* урынына *р(r)* килү күренешенә мисалның күпчелеге чуваш телендә булса да, шундый мисалның унбишләбе монгол, унлабы венгр һәм берничәшәре тунгус-манъҗур, финн-угор h.б. телләрдә лә табыла. Ирани телләрдә хәзерге көндә төрки алымнар бик күп – меңнәрчә табылса да, ротацизм мисаллары юк, диярлек (бәхәсле очраклар исәп түгел). Казан һәм гарәп телләрендәге төрки алынмаларда да андыйлар күренми. Әмма тик барлык төрки телләрнең үзләрендә чуваш теленнән ерак торганнарда да, ротацизм очраклары күренгәли. Икенче яктан, ротацизм очраклары күпсанлы гарәп-фарсы алымнарында да юк. Ягъни гарәп яки фарсы телендәге берәр сүздә *-з-* авазы булып та, ул сүз төрки телләргә кергәч әлеге *-з-* урынына *-р-* пәйда булган очракны – ышанычлы мисалны без белмибез (ә ышандырыр өчен кимендә өч шиксез мисал кирәк).

*Р(r) ~ з(z)* тәңгәленең нинди эчке күршеләр җирлегендә пәйдә булуы да билгеле түгел.

Барлык бу мәгълүматлар түбәндәге нәтиҗәләргә китерәләр:

а) *р ~ з* тәңгәллеге бер чуваш теле белән генә баглы түгел; ул гомумтөрки күренеш;

б) *р ~ з* тәңгәллеге төрки фарсылар һәм гарәпләр белән очрашканчы ук йөз биргән;



в) *р ~ з* тәңгәллегенең төрки телләрнендә килеп чыккан төрки телләрнең «эчке» эше, чөнки төрки телләрдә дәвамы – филиациясе булмаган *р ~ з* тәңгәллеге ротацизм очраклары монгол телләрендә дә, венгр телендә дә, бүтән телләрдә дә билгеле түгел, ә шул телләрдә билгеле булмаган ротацизм очраклары төрки телләрдә йөзгә җитә;

г) үзендә ротацизм очраклары күп булган борынгы төрки тел (телләр) яки (диалекталь) белән заманында венгр һәм монгол телләре якын контактта торган;

д) башта монгол телләләр белән аралашып, соңыннан угорлар (венграларның бабалары) белән тыгыз багланышка кергән борынгы төрки һунн кабиләләре, авазлар һәм болгарлар билгеле, һәм ротацизмнарга бай төрки шиваләрдә башта шул кабиләләр яисә шулар арасында булган кабиләләр сөйләшкән бәләы бик ихтимал.

§51. Барлык тел тарихчыларын *r ~ z* тәңгәллегенең юнәлеше бик кызыксындыра: *r(р)* авазы *z(з)* урынында килеп чыкканмы яисә, киресенчә, *z(з)* авазы элекке *r(р)* урынындамы яки, бу ике аваз өченче бер авазданмы?

Артикуляция җәһәтеннән *r* һәм *z* авазлары үзара бик үк якын түгелләр – алар арасында *r(рҗ)* һәм *-δ* (башкортчадагы *ҙ* ) авазлары бара. Шуңа күрә әлеге сорауларны түбәндәгечә формалаштырып була:

*z>δ>r?   r>δ>z?   δ — r*
*\ z ?*

Бу фаразның кайсы ихтималрак булуы турында бик күп фикерләр әйтелгән. Без биредә ул фикерне бәйнә-бәйнә бәян итеп тора алмыйбыз. Тик шуны әйтергә кирәк: рус галимнәре – Б.А.Серебренников, А.С. Щербак h.б *-z>r* дип, чит ил галимнәре *r>z* дип баралар.

§57. Без дә беренче авазны биредә -ч дип барабыз һәм фикеребезне түбәндәгечә нигезлибез*.

§52. Иң тәүдә әлеге күчешләрнең артикуляцион шарты булган *δ(ҙ)* авазы төрки телләрдә гомумән булганмы дигән сорау туа. Башкорт һәм төрекмән телләрендә бер үк сүзләрдә гомумтөрки *з(z)* урынына *δ(ҙ)* авазы кулланылу, безнеңчә, бик борынгыдан килгән күренеш. Ул инәкә төрки телдә үк булган булса кирәк һәм шул төрки телдәге *r(р)* авазы билгеле бер позициядә башта *δ(ҙ)* авазына алмаштырылган. Гомумән *r(р)* әйтелешкә авыр авазларның берсе – сөйләшергә өйрәнүче нарасыйлар аны иң соңартып үзләштерәләр. Кайбер телләрдә каты *r(р)* фонематик аваз буларак гомумән кулланылмый яисә чикләнгән дәрәҗәдә генә кулланыла (мәсәлән, кытай телендә, хәзерге инглиз

* §44-тә бәян ителгән җиде аваз (s-z-r-δ-d-t-j) тәңгәллеге ошбу r ~z мәсьәләсенә кагылышлы түгел.

телендә һ.б.). Безнең күзәтүебездән күренгәнчә, *r(р)* авазын әйтә алмаучы балаларның кайберләре аны *δ* белән алмаштырып карыйлар. Борынгы заманнарда төркиләр яулап алган бер зур төркем хатыннар һәм аларның балалары да төп төрки *r(р)* урынына *δ(ҙ )* дип сөйләшеп китүләре бик ихтимал.

Шуны әйтергә кирәк ки, *r(р) > δ(ҙ )* күчешенә мисаллар башкорт сөйләшләрендә бүгенге көндә дә табыла. Мәсәлән: башк. сөйл. *киҙәгәй* «трахея» < бор. тк *kergegej*, к. бор. тк. *kerdük* «сарыкның челтәрле карындыгы» («сетка-желудка овцы», к. ДТС: 301), татарларда *кирәгә*, гомумтөрки һәм монголча *кэрэгэ* «тирмәннең аркылы-торкылы таяклардан торган каркас челтәре»;

башкорт сөйләшендә *киҙәм* «кире, тискәре» << кирәмәй;

башкорт сөйләшендә *миҙгә* башкорт диал., татар диал. *миргә* «ниргә, бурада чираттагы бер рәт бүрәнә»;

башкортча *сиҙ әм* <сирәм << тат. һ.б. *чирәм*, якут. *сирэм*, бурят. *шэрэм* «чирәм, кәз»;

башкорт сөйләшендә: *сөйз, ә* «балтаның, пычакның һ.б. үтмәс ягы» << татарларда *чөйрә, чүрә,* кумык, карачай-балкар телләрендә *чюйри* «балтаның, пычакның һ.б. үтмәс ягы» ~ тат. *чөкрә* «башның арт чүмече» һ.б.

Тик башкорт сөйләшләрендә генә булгач, *киҙәмәй*, *киҙәм*, *миҙгә*, *сиҙәм*, *сөйҙә* сүзләрен (*ҙ* - вариантларны) бик борынгыдан калган яңгырашта дип әйтү кыен. Китерелгән мисаллар р-вариантлар, һичшиксез, борынгырак, элеккерәк.

Тагын шунысы игътибарга лаеклы ки, ошбу очракларда *р>з* күренеше *-и-* сузык авазыннан соң гына күзәтелә (*-ир>-из*). Борынгы *р>з* шартлары икенче булган, әлбәттә. Ләкин башкорт теленнән алынган мәзкүр мисаллар төрки телләрдә *р>з* күчешенең принципта мөмкин булуына дәлил.

§54. Безнең *r>δ>z* фаразы файдасына булган саф лингвистик дәлилләребез түбәндәгеләрдән табыла:

а) иске тамырлардан төшеп калган яисә, үзгәрелгән авазларны тәнәйтү процедурасыннан;

б) тәкълиди сүзләрдән ясалган нигезләрне тикшерүдән.

§55. Иске тамырлардан төшеп калган, яки үзгәрелгән авазларны тәнәйтү процедурасы түбәндәге ике закончалыкка таяна:

а) фонетик үзгәрешләр морфологик системаны, логиканы җимерәләр. Моның ачык мисалы – татар телендәге *китеру* һәм *үтеру* сүзләре: аларның элекке (башкорт телендә дә сакланган) вариантлары *китеру* һәм *үлтереу*; алар, күренеп торы ки, *килу* һәм *үлү* фигыльләренең йөкләтү юнәлеше формалары; фонетик процесс – редукция *-л* төшеп калу нәтиҗәсендә *китеру* һәм *үтеру* яңгырашлары пәйда булып, бу



фигылләрнең *килү* һәм *үлү* белән багланышы томанланган, онытыла башлаган.

Шуның шикелле, татар телендә (һәм күп кенә төрки телләрдә) *барыр-бармас*, искечә – *бармаз*; *килер – килмәс* (искечә *килмәз*) (барлык һәм юклык) формаларының борынгы багланышы да онытылган. Монда үзгәрешләр ике төрле булырга мөмкин.

| Барлык | Юклык |
|---|---|
| *бар-ыр*<br>яисә, *бар-ыз* | *бар-ма-р > бар-маз > бар-мас*<br>*бар-ма-з > бар-мас* |

Бу вариантның кайсысы ихтималрак соң? *Бар-ыр* формасына логик яктан туры килә торган бармар (килмәр) яңгырашлары татар сөйләшләрендә (Ставрополь якларында, Себердә) һәм угыз диалектларында бар. әмма *барыз* («барыр» мәгънәсендә) яңгырашы беркайда да теркәлмәгән. Шуңа күрә *барыр* һәм *бармар* (*-ыр* һәм *-ма-р*) яңгырашларының борынгырак булуы ихтималрак шикелле. Ягъни нәкъ менә *-р* авазы борынгырак һәм фигыльнең мондый юклык формасында *р>з* күчеше булган шикелле.

б) Фонетик инновация (яңалык, яңарак күренеш) сүзләрнең иң үзгәрүчән өлешләрендә – тамыр яисә нигезнең азагында (аслаутта) пәйда була. Еш кына тамыр сүзнең абсолют азагы төрләнеш процессында һ.б. фонетик үзгәреш кичерә, әмма шул тамырдан ясалган мөстәкыйль нигез сүздә тамырның элекке азагы искечә, элекке яңгырашта саклана. Мәсәлән, борынгы *улуг* «олы» һәм *сарыг* «сары» (хәзерге телләр өчен тамыр) сүзләрендәге азаккы *γ* кыпчак телләрендә төшеп калган, редукция кичергән. әмма ул – *γ* әлеге *улуг* һәм *сарыг* сүзләреннән борынгы заманда ук ясалган *олҗ аймак* (*<улуҗ -ай-мак*) һәм *саргаймак* (*<сарыг-ай-мак*) сүзләрендә сакланып килә.

Чуваш телендә борынгы *йэтти < җите* сүзе *счич* (*счичĕ*) яңгырашын алган (ягъни сүз азагында *т>ч* күчеше йөз биргән), әмма *считмел* «житмеш» сүзе эчендә борынгы *т(t)* үзгәрешсез сакланып калган. Шул ук чуваш телендә болай бик нык үзгәргән тартым кучымчасы *–сы//се*, *-сымыр//сĕмĕр* кушма кушымча составында (мәсәлән, *иксĕпĕр* татар сөйләшләрендә иксебез «икебез») сакланып килә һ.б.

Менә шул китерелгән мисалларга аналогик, охшаш хәл түбәндәге *р ~ з* тәңгәллеге очракларында да күзәтелсә кирәк:

| Тамыр (борынгы нигез) эчендә *-р-* | Яңа нигез (тамыр) азагында *-з-* |
|---|---|
| *балтырҗ ан* (чаг. чувашча *кулдыр, полдыр < балдыр* «балдыз; җитлекмәгән»; к. казахча *балдырган* «яшь үлән, бәбәк, бөре»); | *балдыз* (төптә «җитлекмәгән яшь кеше»); |

| | |
|---|---|
| *боғарлану* «богазга килгәнче ашау» | |
| *богардақ, бугардақ* «тамак төере»; | *буғаз* |
| *бирчәю* «сөял булып кату»; | |
| *бирту* «бәреп сөялләндерү» (чаг. чувашча *пар<бәр* «биз»); | *биз* |
| *борчу* «кәефне бозу» чаг. монголчада *бори-* «бозмак»); | *боз-мак* |
| төрекчә *докурчин* «тугызлы уен»; | *тугыз<тоқуз>докуз* |
| *егерме* (*<йигир-им он* «икенче ун» сүзеннән); | *игез* |
| *кабырға*; | үзбәкчә *кабыз* «култык асты» |
| *күкрәк, күкерәк* (чаг. чув. *когыр<көгер* «күкрәк»); | иске тат. *күкез* «күкрәк» |
| *умрау*; | төрекчә *омуз* «умрау» |
| *терсәк*; | *тез* |
| *тимрәү*; | алтайча *тэмиз* «тиренең йонсыз төше» |
| *каwырсын, каруый*; | тат. диал. *каwыз* «каурый» |
| *ниргә* (*<нэгиргә*) «рәт, нигез; | *нигез* |
| *симрәү, сүрмәү* | *сизү* һ.б. |

Безнең тикшеренүләребез буенча *сигез*<сэккиз ~ чувашча *сăккар* сүзе бор. *сэк қорғу* «язгы кузый», ә *тугыз<токкуз* ~ чувашча *туххăр* сүзе бор. *тоқ қорғу* «көзге кузый» сүзеннән (бу тәгъбирләр кузна сөягенең сигезенче һәм тугызынчы почмакларын белдергәннәр) (к. Р.Г.Ахметьянов. Слово *қозу<qorɣu* и термины игры в альчики в татарском языке//Материалы по татарской диалектологии. Казань, 1988), к. тат., башк *қоралай<куралай<қорғулаң* «косуля».

Бүтән төрки телләрдән тагын күп кенә шундый мисаллар табып була. Шунысы игътибарга лаек ки, китерелгән мисалның күпчелеге кеше һәм хайваннарның тән әгъзаларының атамалары яисә шуларга баглы сүзләр – ягъни, алар иң тотрыклы лексикага карыйлар.

Күренеп тора ки, китерелгән мисаллар *z(з)* авазы һәр вакыт сүз азагында, ә аның урынындагы *r(р)* авазы этимологиясе, морфологик составы күптән онытылган нигезләр уртасында торып калган. Чуваш-төрки (гомумтөрки) чагыштырмаларда да *р>з* тәңгәллеге башлыча сүз яки иҗек азагында килә. ә *z(з)* сүз уртасында (ике сузык арасында) булган очракларны тикшереп карасак, аларда элек шул *з* авазы артыннан берәр тартык аваз, бигрәк тә *γ, g (ғ, г)* авазлары булганлыгы мәгълүм була. Мәсәлән, бороынгы төрки язма теләрдә *йозак* сүзенең *йузғак*



варианты, *қазан* сүзенең *қазған* варианты, *кызыл* сүзнең *кызғыл* варианты билгеле. Шундый вариантлары табылмаган *бозау, көзән, өзәңге* кебек сүзләргә килгәндә, аларның да ул вариантлары булган, әмма язуда теркәлмичә калган, онытылган дип уйларга бөтен нигезләр бар (аннары, интервокаль *-з-* булган кайбер сүзләр, *азан, базар, таза* кебек чагыштырмача соңгы алынма сүзләр булуы да ихтимал).

Кайбер интервокаль *-з* очраклары шулай ук чагыштырмача яңа төрки ясалма сүзләрдә күзәтелә, мәсәлән, *озак, аза-мак, озай-мак* һәм *озын* сүзләренең уртак тамыры *оз<уз* гагауз телендә «озынлык» мәгънәсендә сакланган (*уйниң узу* «өйнең озынлыгы» диләр).

§56. Сонор тартыкларның нисби борынгылыгына тагын бер дәлил итеп түбәндәгеләрне алабыз.

Бүгенге төркет телләрендәге *-з-* авазы еш кына парлы органнарны яисә, икелекле нәрсәләрдә белдерелә, сүзләр составында (башлыча аларның азагында килә).

| Татарча: | Чувашча; |
|---|---|
| *игез* | *йĕкĕр* (*йегер*) «икеләр» |
| иске татар *күкез* | *кăкăр* (*кыгыр*) «ике ими» |
| *күз* | *кусч* «ике күз» |
| *мөгез* | *мыйрака* (*мыйрага*) «ике м-гез» |
| *тигез* | *тэңиз* «тиңләр» |
| *тез* | *ҫĕр* «ике тез» |
| бор. төрки *отиz* | *ăмăр* «ике умрау» |

Бу очракта *z(з)* борынгы икелек кушымчасы *-r (-р)* дән килеп чыгуы гөман ителә. Чөнки кардәш дип уйланылган тунгус-манъҗур телләрендә күплек һәм икелек кушымчасы *-р* бар.

Күплек кушымчасы буларак *-з-* ~ *-р* (*-z* ~ *-r*) *без* < *biz* ~ чув. *эпир* (*эбир*) һәм *сез* < *siz* ~ **sir* → чув. *эсир (эзир)* алмашлыкларында һәм беренче вә икенче зат күплек кушымчасы *-з* (*-z*), -ыз//-еҙ, (-yz//iz)-дә (*атыбыз ~ атымыз, атыгыз ~ атыңыз, барыбыз ~ барамыз, барасыз ~ барасыңыз*) ачык чагыла.

Әгәр *-r* вариантлар беренче дип алсак бу формалар түбәндәгечә тармакланганнар (транскрипция шартлы):

| | | | |
|---|---|---|---|
| **атыбыр,* | ↗ *атыбыр, бараббыр* | → чув. | *утăмăр, пыраппăр (удымыр, пыйраппыр)* |
| **барабыр* | ↘ төркетчә | | *атыбыз ~ атымыз, барабыз ~ барамыз* |

| | | |
|---|---|---|
| **атыңыр*, | → чув. | *отăр>утăр (одыр>удыр), пыратăныр (пыйрадыныр)* |
| **барасыңыр* | → төркетчә | *атыңыз* > тат. *атыгыз, барасыңыз* > тат. *барасыз* |

§57. Тәкълиди сүзләр (аваз ияртемнәре) шаһитлеге. *Р ~ з* мәсъәләсендә тәкълиди сүзләр дә җитди шаһит, дәлил була алалар. Монда түбәндәге мисаллар гыйбрәтле.

а) Татар, карачай-балкар һ.б. телләрдәге *сыбызғы, сывызғы* кайбер төрки телләрдә *сыбызгы* вариантына ия (Räsänen, 1969. 414); шул ук вакытта алтай теле диалектларында аның *сыгыргы, сыгыртқы* варианты да бар. Төрки телләрдә күп кенә сүзләрдә (бигрәк тә кыпчак телләре даирәсендә) *г ~ в ~ б* чиратлашуы бар: *эгир-, эбир-* «әвермәк, әйләндермәк», *огурт ~ обурт* «урт», *тагар ~ тавар ~ табар* «олау; товар» һ.б. *Сыбызгы ~ сыбыргы ~ сыгыргы* шулар җөмләсенә карый (к.ш.ук якутча *сыбызгаа* ~ кыргызча *сыбызгы* – «селтәгәндә камчы очы сызгырмак»).

*Сыбызы<сыгыргы*, һичшиксез, татарча диалекталь һ.б. *сыргырмак, сыгыр-мак* «сызгырмак» фигыльленнән ясалган. Чөнки бу сүз нигезендә тәкълиди (иярчемле) сүзләрдән фигыльләр ясый торган *-ғыр//гер, -қыр//кер* аффиксы ярылып ята (ул аффикс *аҗғыру, ақыру, бақыру, выҗғыру, чаҗғыру, чақыру, чөңгерү, җикерү, йөткерү, қақыру, қайғыру, қычқыру, кикерү, өшкерү, өскереү, өфереү* (шуннан – *өрү*), *пошкыру, сеңгерү, төфкерү* (шуннан – *уфыру*), *үкерү* һ.б. фигыльләрдә күренә). Бу *-кыр* аффиксы элек мөстәкыйль фигыль булган булырга тиеш (чагыштыр- инглизчә – *край*, русча – *крик*, гарәпчә – *карә* «кычкыру»). Аның *-қ ыз//кез* варианты беркайда да теркәлмәгән.

*Сызғыр-мак* фигылендәге *-з-* авазы, димәк, элекке *-р*-дан булса кирәк (*сырғыр->сызғыр-*).

б) Татар диалектларында *қŏран* (*қарга-қоран*) һәм *қозан* «козгын» сүзләре бар. *Козғын* һәм *карға* атамасы барча телләрдә бу кошлар чыгарган *қарр//қорр//қурр* авазлары нигезендә ясала (мәсәлән, латинча *корвус*, гарәпчә *ғураб, қураб*, японча *карасу*, немесчә *краһе*, мордва телләрендә *кранч*, марича *курныж* һ.б. Димәк, төрки телләрдә дә *қорған, қорғын* «козгын» сүзе булган һәм *-р* авазы беренчел.

в) *Саескан* борынгы төрки һәм кыргызча *сагызган* сүзе борынгы *сагырган* вариантыннан: дөнья телләрендә *саескан* исеме еш кына *сагыр//шагыр* тәкълиди сүзеннән (саесканнар еш кына чыгарган аваз нигезендә) ясала. Мари телендәге *шогертен, шогуртан* «саескан» борынгы телләрдәге *сағыртқан* вариантыннан булса кирәк.



г) Чыгтай, госманлы, кырым-татар телләрендәге *йалдыз* ~ төрекчә *йалдыр* «ялтырка, ука» парында *йылдыр* (*-р*) варианты борынгырак, чөнки бу сүз һичшиксез, *йалтыр* (*ялтыр-йолтыр*) тәкълиди сүзе белән баглы. *Йалтыр* сүзе *–лтыр//-лтер* аффиксы белән ясалган бик күп тәкълиди сүзләр рәтендә тора (чагыштыргысыз: *калтыр, келтер, пылтыр, чылтыр, челтер, шылтыр, шалтыр* һ.б.)

Гомумтөрки *йулдуз* чувашча *счылдыр* (*жолдор*) сүзе дә әлеге *йалдыз – йылдыр* сүзе кебек үк һәм, асылда, шул ук тәкълиди нигездән ясалган.

д) Чувашча *йанкăс* «яңгыравыклы, шыңгырдап торган» сүзе татар теленең үзендә онытылган *йангыз* сүзеннән булуы бик мөмкин (сүз башында *й-* һәм сүз азагында *-с* - чуваш телендә татар алынмаларына хас күренеш). әгәр *йангыс<йангыз* «яңгыравыклы» мәгънәсендә икән, ул элекке *йаңгыр* (ява торган *йаңғыр* сүзе тарафыннан кысрыклап телдән чыгарылмыш) тәкълиди сүзеннән. Шул тәкълиди *йаңгырдан йаңгыра-мак* фигыле ясалган (чаг. *дыңгыр-дыңгырау, сыңгыр-зыңгырау, чылтыр-чылтырау, челтер-челтерәү, шалтыр-шалтырау* һ.б.). Димәк, монда да төптә ауслаутта *-р* булган.

Шулай итеп, китерелгән барлык фактлар һәм логик хөкемнәр күрсәткәнчә, *r ~ z* тәңгәлендә *r* беренчел, ә *z* икенчел булып чыга.

§55. Шунысы кызык ки, *з(z)* авазының *р(r)* авазыннан килеп чыгуы файдасына өстә генә яткан, күренеп торган бер дәлил бар: *-з(z)* авазына беткән гомумтөрки сүз нигезләргә, сонор авазларга беткән нигезләргә ялганган шикелле үк, һәрвакыт яңгырау тартыкка башланган кушымчалар ялгана (чаг.*кар-да, тау-да, ян-да, боз-да*, ләкин *ас-та, ут-та, кыш-та* һ.б.) Парлы тартыклардан *-з-* төрки сүз нигезе азагында килә ала торган бердән бер яңгырау тартык аваз! Гомумән, борынгы язма телләрдә лә, хәзерге төрки телләрдә дә *–з(z)* авазы төп төрки сүзләрдә, нәкъ *-й, -л, -н, -ң, -р*-лар кебек үк, тамыр сүз азагында, яисә, сирәгрәк, сүз уртасында, ләкин (хәзерге яки элекке) иҗек азагында килә. Бу хәл, ягъни *–з(z)* авазының сонор авазлар урынында, сонор тартыклар шикелле үк кулланылуы – аның борынгы бер сонор аваздан килеп чыкканлыгын күрсәтә. ә ул борынгы сонор тартык *-з*-ның элгәре әйтелеш шартлары буенча тик *-р* авазы гына була ала.

Әле һаман *-з-* авазы беренчел, ә *-р-* икенчел дип баручыларның шушы өстә яткан фактны күрмәүләре гаҗәп.

§59. Гомумтөрки һәм татарча *–ш(š)* урынына чуваш телендә *–л(l)* килү очраклары азрак:

| Татарча: | Чувашча: |
|---|---|
| *биш < beš* | ~ **belik>bilek> пилĕк* «биш» |
| *иш < eš-* | ~ **el->äl - ал* – «җир сөрмәк», |
| *ишек < ešik* | ~ **elik>älĕk> алăк (алык)* «ижек» |
| *ишет < ešit-* | ~ **elit>ilĕt> илт* – «ишетмәк» |
| *йомыш < jumuš* | ~ **jumul>jŏmŏl> çăмăл (счŏмыл)* «йомыш» |
| *кŏйаш < qujaš* | ~ **quwal>xөwäl> хĕвел (хөвәл)* «кояш» |
| *көмеш < kümüš* | ~ **kümül>kөmөl> кĕмĕл (көмел)* «көмеш» |
| *кыш < qyš* | ~ **gyl>xĕl, hĕl> хĕл (хĕл)* «кыш» |
| *таш < taš* | ~ **t'al>t'ol>čol> чол>чул* «таш» |
| *теш < tiš* | ~ **t'yjl>čyjl>šyl> шăл (шыл)* «теш» |
| *төш < tüš* | ~ **tül>tөl → tөlek> тĕлĕк* «төш» |
| *алтмыш < altmyš* | ~ **altymyl>otmyl> утмăл (утмыл)* «алтмыш» |
| *җитмеш < jetmiš* | ~ **jetimil>зitmel>çитмĕл (считмĕл)* «җитмеш». |

Болардан тыш *л ~ ш (l ~ š)*, чуваш телендә булмаган кайбер мисалларда да күренгәли. Мәсәлән, мари телендәге *хал* «наш» < болгар телендәге *һал* < борынгы төрки **qal* «каш» сүзеннән дип уйланыла. *Л ~ ш* тәңгәллеге төрки телләрнең үз диалектләрендә дә күзәтелә. Мәсәлән, татарча диалекталь *төлер-мәк* «йокымсырау, өнле – төшле нәрсәдер күрү» сүзе борынгы *түл (<tül<tüül)* сүзеннән булса кирәк. Гомумтөрки *йыл//йал* һәм *йәш<йаш* (шуннан ук *йәшел<йашыл*) бер сүздән тармакланган булуы бик ихтимал (ягъни биредә *l ~ š* тәңгәллеге күзәтелә).

Л ~ ш күзәтелгән очраклар бу аваз күчешенең сәбәпләре турында киң мәгълүмат бирмиләр. Тик күчеш *l > š* юнәлешендә иҗек азагында *-lč* чатлашуыннан булган (чаг. венг. *bolcsö* «бишек», *gyümölcs* «җимеш»).

§60. Гомумтөрки *z* урынында *r(р)* һәм *š* урынында *l(л)* булган төрки тел Урта Идел регионында бер чуваш теле генә түгел: шундый телдә хәзерге Татарстан Республикасы чикләрендә, Куйбышев вә Ульянов өлкәләрендә табылган һәм башлыча XIV гасырга караган башбата (кабер ташы) текстлары да язылган (алар турында к. §60). Алардан тыш борынгы Дунай Болгариясеннән – VIII гасырдан ук калган славян һәм грек хәрефләре илә язылган язмаларның кайберләрен дә «*r*» вә «*l*» төрки телендә укыйлар. Кайбер укылышлар бәхәсле булса да, ул язмаларда ротацизмлы сүзләр барлыгы шиксез.

Аннары, кайбер галимнәр Төньяк Кавказ кыяларында чыеп язылган билгеләрне дә төрки руник хәрефләргә охшатып, язмаларны ротацизмлы телдә укып маташалар. Безнеңчә монда шикләнерлек урын бар. Чөнки руник Урхун-Енисей язулары «*z*» вә «*š*» төрки телдә язылганнар һәм бу язу системасы да шундый телдә сөйләшүчеләр тарафыннан иҗат



ителгән булса кирәк; «*r*» вә «*l*» телендәге төркиләрнең төрки руникасын куллану үзе исбат ителүгә мохтаҗ.

Шуңа күрә без «чуваш руникасы» турындагы публикацияләргә дә бик сак карыйбыз.

§61. *R ~ z* вә *l ~ š* тәңгәллекләре һәм чуваш теле материалы безгә түбәндәге нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә.

Нисби хронологиядә иҗек (сүз) азагындагы *z* һәм *š* - соңрак күренешләр. Алар килеп чыкканга кадәр төрки телләрдә *z* һәм *l* мөстәкыйль аваз булмаганнар (ә, бәлки, *s* һәм *č* авазларының аллофоннары гына булганнардыр). Ул чорда күп очракларда иҗек һәм сүз азагында алар урынында *r* һәм *l* авазлары торган.

Шул ук чорда әле *–lar//ler* (-лар-ләр) күплек кушымчасы да булмаган, аның урынына *-r* кушымчасы кулланылган. Аннары, еш кына, күплек аерым сүзләр белән белдерелгән булса кирәк (мәсәлән, чуваш телендәге *-сем*, болгар язмаларындагы *-сам* шундый сүзләрнең бересе булырга мөмкин: *самъчин* «хисапчы, санчы» Дунай болгарларында кулланылган сүз).

Билгеле бер чорда төрки телләр икегә аерылган: аларның беренче тармагында *-p(r)*, *-л(l)* һәм, ихтимал, *-сам (-sam)* торып калган: икенче тармагында *-з(z); -ш(š)* һәм –лар//ләр (*-lar//ler/lu*) кулланыла башлаган.




Без беренче (уң як) тармакны һунн төркеме, икенчесе төркет төркеме дип атау яклы.

Бу ике төркем үз-ара чагыштырмача аерымлану, изоляцияләнү шартларында пәйда булсалар да, алар арасындагы бәйләныш бөтенләй үк өзелмәгән: төрке телләрендә элекке *-r* һәм *-l* авазлары саклану очраклары шуны күрсәтә.

Башкорт теленең морфологик кагыйдәләре буенча *з* һәм *ҙ* авазларының *-р-* белән бер группада йөрүе дә аларның борынгы *-р-* дан килеп чыгуын күрсәтсә кирәк (к. §65).

Ни өчен һунн төркиләрендә борынгы *-r* һәм *-l* сакланган соң дигән сорауга да фаразабыз бик кулай җавап бирә: чөнки алар телендә *γ(г)* һәм *g(г)* авазлары тизрәк «коелучан» булган. Бик күп борынгы *γ* һәм *g*, *q* һәм *k* авазларының юкка чыкканлыгын без чуваш телендә дә күрәбез.

## БИШЕНЧЕ БАБ
## ТӨРКИ ТЕЛЛӘРНЕҢ ҮСЕШ СХЕМАСЫ – ГЕНЕОЛОГИК КЛАСССИФИКАЦИЯ ТӘҖРИБӘСЕ

§67. Бүгенге барча белгәннәребез буенча, иң борынгы төрки диалектлар сузык авазларга чагыштырмача бай, әмма тартыклары бик үк күп булмаган фонетик системага ия булганнар. Поляк тюркологы В.Котвич фикеренчә, баба төрки сүзләр һәрвакыт сузык авазга беткәннәр[46] һәм гомумән, барлык иҗекләр ачык булганнардыр, дип уйларга нигезләр бар. Сүзләрдәге барча иҗекләрнең ачык булуы доньядагы күп кенә телләрдә, мәсәлән, япон, индонез, меланез һәм полонез телләрендә, бигрәк тә бүгенге мари телендә күзәтелә[47]. Гомумән иң беренче иҗек төре ачык иҗек – сузык авазга беткән иҗек булган булса кирәк.

Барча иҗекләр ачык булу өстенә сүз басымы да зур роль уйнамаса сөйләмдәге сүзне сүздән аеру кыенлаша. Бу кыенлыктан котылу өчен борынгы төрки шивәләрдә тартык авазларның функциональ популярлашуы килеп чыккан, ягъни сүз башында башлыча саңгырау тартыклар *-п, -к, -с, -т* һәм башка шундыйлар, ә сүзнең азагында (барлык иҗекләр ачык булгач – бер сүз эчендәге ике сузык арасында) сонор вә гомумән яңгырау тартыклар кулланылган. Бу хәлдә, мәсәлән, *пайа, пала, пама, пана, пара* кебек яңгырашлы (ягъни соңгы иҗеге сонор + сузык булган) сүзләр бик еш очрап, гадәти хәл булып, сонорларга башланган сүз яңгырашлары, әйтик, *йаба, лаба, маба, наба, раба* бөтенләй мөмкин булмаган. Шундый вәзгыятьнең бакые – калынмасы төрки телләрдә, шул хисаптан татар телендә һәм күреп үткәнебезчә, аеруча башкорт телендә бүген дә сизелә.

Менә шундый полярлашу билгеле бер үсешкә ирешү белән сүз азагында сузынкылар кирәксез булып калганнар: һәр тел (шул телдә сөйләшүчеләр) кыскалыкка омтыла һәм әгәр сүз башы саңгырау тартык ярдәмендә, ә сүз азагы сонор тартык илә билдергәч, сонор аваздан килгән сузык авазлар торган саен ешрак төшерелеп калдырыла башлаганнар. Нәтиҗә, мәзкүр *папа, пала, пама, пан, пара* кебек ике иҗекле сүзләр урынына *пай, пал, пам, пан, пар* кебек бер иҗеклеләр килеп чыккан. Бу үзгәрештән соң тагын бер мөмкинлек – кайбер сүз башы тартыкларның (димәк, әйткәнебезчә, саңгырау тартыкларның) яңгыраулашыу мөмкинлеге туган. Чөни сүз азагы сонор тартык белән билдерелә икән, сүз башын аеруча билдерүнең кирәклеге дә азая. Менә шул шартларда иң тәүдә шактый авыр әйтелешле *-п* авазы *-б* булып яңгыраулашкан булса кирәк.

---

[46] В.Котвич. Исследования по алтайским языкам. -М., 1962.
[47] В.В.Шеворошкин. Звуковые цепи в языках мира. М., 1969 С. 19-111.



Кайбер тикшерүчеләр, мәсәлән, Н.И.Баскаков[48], иң борынгы төрки иҗек ТСТ (татар-сузык-тартык) калыбында булган дип бара. Ләкин бу фикер хакыйкатьне өлешчә генә чагылдыра: сүзләр, бигрәк тә сүз нигезләре башлыча ТСТ калыбында булган чордан да булып үткән, әмма ул чор төрки телләр үсешенең бер стадиясен генә тәшкил иткән.

Иң борынгы – инәкә төрки шивәләрдә сүзләрнең иҗек калыбы өлкәсендә барган тирәнтен үсешләр-үзгәрешләр белән беррәттән телнең архитектоник төзелеше дә үсешә барган.

Күп кенә (ихтимал барлык) телләр үсешендә шундый стадия булган ки, сүзләр аерым җенесләргә (русча род) бүленгәннәр. Һәр бер аерым җенестәге сүзләр аерым фонетик һәм морфологик үзенчәлекләр белән бирелгән. Бу җенес категориясеннән тыштагы җанлы һәм җансыз нәрсәләрне белдерергә сүзләр дә әйтелештә – төрләнештә аерым тамгаланганнар. Шул рәвештә телдә сүз класслары килеп чыккан.

Бик ихтимал, борынгы төрки телләрдә дә шундый сүз класслары булгандыр. Безнең гөманыбызча, борынгы төрки сүз мәгънәви классларның берәсе (әйтик, җанлы нәрсәләрне белдергән яисә, мөәннәскәженсани *родка* караган сүзләр) сүз азагында килгән махсус *-си* элементы белән белдерелгән. Мәсәлән, *баласы* «баласы», *бөрүси* «бүре» сүзләре билгеле бер сүз классына караганнар һәм аларның бу хасияткәләре башка бик күп сүзләр белән беррәттән *–сы//си* компонентына карап танылган, ди. Сүзләр азагындагы сузыклар төшеп калган чорда *баласыдан балас* кына, *бөрүсидән бөрүс* кенә торып калган. Һәм гомумән *-с* авазына тәмамланган бик күп сүзләр килеп чыккан. Алар бүтән тартыкларга беткән сүзләр шикелле төрләнгәннәр: мәсәлән, тартым кушымчасы *–ы//и*, -улы кушылганда: *кырыс-*«ы» «кыры», *өр-ү* «үре», *бала-с* «баласы», *бөрүс-ү* «бүресе» рәвешендәге сөйләм сүзләре пәйда булган. әмма тора-бара, сүзләрне мәгънәви-семантик классларга бүлү онтылгач, *балас-ы* сүзе *бала-сы*, *бөрүс-ү* сүзе *бөрү-сү* булып аңлашыла башлаган.

Менә шуннан соң инде *–сы//си* кушымчасы сузык авазларга беткән нигезләргә вә формаларга ялгана торган аерым төрләндергеч аффикс булып аңлана һәм кулланыла башлаган.

Менә шундый күренеш – сүз нигезенә караган авазның, иҗекнең кушымча яки хәтта бүтән бер сүз составына кереп китеүен тел гыйлемендә *кабаттаркалыш* (русча переразложение) дип атыйлар.

Кабаттаркалышның борынгы заманда ук килеп чыккан тагын бер үрнәге – фигелләрдән *-т, -ыт//ет* кушымчасы ярдәмендә ясалган исем нигезләргә тартым кушымчасы *–ы//е* ялгану нәтиҗәсендә үткән заман кушымчасы *–ты//те, -ды//де* килеп чыгу хадисәсе.

---

[48] к.Языки народов СССР. Тюркские языки. М., 1966. С. 16-18.

Хәзерге телебездә дә берәр эш-шөгыльнең нәтиҗәсен, азагын белдергән һәм *-т*, *-ыт//ет* кушымчасы ярдәмендә фигыль нигезләреннән ясалган бер төркем сүзләр бар:

*болыт<булут*, боронгы *бул-* «болгану» фигыленнән;

*карт<кары-т*, борынгы *кары-мак* «картаймак, күп яшәмәк», төп асыл мәгънәдә «кар (кыш) кичермәк» фигыленнән;

*корт<коры-т – коры-мак* фигыленнән;

*көрт<көрет* «көрәп алына торган нәрсә»;

*саркыт* – «суы саркыган катык»;

*сагыт* – «елау, яшь сыгу»;

*сырт<сыр-ыт – сыр-сырлар салу* фигыленнән һ.б.

Заманында бу *-т, -ыт//ет* һәм фигыльгә кушыла торган киң кулланышлы регуляр кушымча булган. Ләкин бу кушымчага беткән исемнәргә тартым кушымчасы кушылганда барлыкка килгән сүзләр ничектер үткән заман фигыльләре дип аңлашыла башлаганнар:

*барыт* «бару күренеше» → *аның барыты* «аның барганлыгы», шуннан *ул барыты > ул барты* «ул барды»,

*корыт* «кору нәтиҗәсе» → *аның корыты* «аның корыганлыгы» → *ул корыты* «ул корыды»,

*үсеш* «үсеү нәтиҗәсе» → *аның үсете* «аның үскәнлеге» → *ул үсте* һ.б.

Бу процессның булганлыгы иң беренче чиратта үткән заман фигыль зат кушымчаларының исем зат кушымчалары белән бердәй булуыбелән исбат ителә.

Аннары кайбер татар һәм башкорт сөйләшләрендә *каранты* «каранды», *күнте* «күнде»; *көйте* «көйде» кебек аваз чатлашмалары булуы да әйткәнебезгә дәлил[49].

Бу процессны билгеләү төрки телләр тарихындагы нисби хронология өчен зур әһәмияткә ия. Атап әйткәндә мәзкүр кабаттаркалышүзе үк башкорт телендәге *караны* «карады», *көрәне* «көрәде» һ.б. очраклардагы *–ны//не* аффиксы вариантын да, шулай ук чуваш телендәге *вуларĕ* «укыды», *тупрĕ* «тапты» һ.б. очраклардагы *-рĕ* аффиксы вариантының да икенчел күренеш булуларын, борынгы гомумтөрки заманынан килмәгәнлгнн күрсәтеп тора.

Кабаттаркалыш фразеологизмнарында да күзәтелә. Мәсәлән, татар теле тарихында *иргәҗел байчәчәк (байчәчәге)* ягъни *иргәҗел* дигән фантастик бармак буе кешеләрнең *байчәчәге*, ягъни «нәсел чәчәге, бәхет чәчәге» (*байчәчәге* сүзе үзе татар сөйләшләрендә дә, бүтән төрки телләрдә дә

[49] к. Ф.Г. Хисаметдинова. Генезис башкирских консонантных сочинений типа сонат – глухой смычный. СТ, №5, 1982. С. 52-57.



билгеле) сүзеннән *иргәҗелбай//эргәзелбай чәчәге* (умырзая, примула) дигән тәгъбир килеп чыккан. Ошбу процессны түбәндәгечә дә күрсәтеп була:

*иргәҗел байчәчәге > иргәҗелбай чәчәге.*

Бу күренеш аерым-аерым алынган *иргәҗел* һәм *байчәчәк* сүзләренең үзләре һәм төп мәгънәләре онытылу нәтиҗәсендә мөмкин булган.

Гомумән кабаттаркалыш күренеше сүз ясалышындагы нигез һәм кушымта, ә сүз тезмәсендәге аерым сүзләр онытыла төшкән очракларда барлыкка килә.

§63. Борынгы төрки телдә информатив кыйммәте – кирүәклеге калмаган сузык авазлар, бигрәк тә югарыда каралган *корыт>корт, көрет>көрт* кебек очракларда – кабаттаркалыш хәлләрендә һ.б. төшеп кала башлаган. Бу процесс сүз басымының беренче иҗеккә туплану, шунда карарлашу процессы белән диалектик берлектә барган.

Барча тел тарихчылары бу мәсъәләдә бердәм – борынгы инәнә төрки телдә басым сүзләренең беренче иҗегенә төшкән һәм ул көчле басым булган. Озак заманнар шундый басымлы әйтелеш хөкем сөрмәсә сингармонизм күренеше килеп чыга һәм формалаша алмас иде. Угро-финн һ.б. кайбер телләрдәге сингармонизм шундый шартларда гына формалашкан. Хәзерге көндә дә кайбер, сингармонизм тулысынча сакланган телләрдә, мәсәлән, эстон телендә, басым беренче иҗеккә төшмәгән сүзне табу кыен: эстоннар хәтта Каза′н сүзен дә Ка′зан дип әйтәләр. Беренче иҗекнең башлык сөрүе, ияртүче булуы нәтиҗәсендә генә икенче, өченче һ.б. сузыклар акустик рәр ягыннан беришле булып китә алганнар бит[49] !

Басым беренче иҗеккә төшкән чорда функциональ яктан кирәге зур булмаган очрактагы соңгы сузык һәм бүтән авазларның редукциясе, төшеп калуы ешайган.

Борынгы төрки шивәләрдә үк ике сузык арасындагы калган тартыкларның яңгыраулашыуы, сонор тартыкларга охшашлануы күзәтелгән булса кирәк. Басымның беренче иҗектәлеге дә шуңа – ике сузык арасындагы тартык авазларның зәгыйфьләнүенә – яңгыраулашуына китергән (яңгырау тартыкларны әйтү өчен саңгырау тартыкларны әйтүгә караганда азрак көчергәнеш, азрак энергия таләп ителә).

Күп кенә сүзләрнең азактагы сузык авазлары төшеп калгач ике сузык арасында яңгыраулашкан тартыклар һәм сонор авазлар сүз азагына килеп чыкканнар.

Менә шулай итеп сүзнең абсолют азагында *-б,-ғ, -г,-д,-з* һ.б. башкалар белән беррәттән сонор тартыклар *-й,-л,-м,-н,-ң,-р* «пыксыз» хәлдә пәйда булганнар. Ул гына да түгел, кайбер ике тартыклы аваз чатлаш-

[49] Бу нәтиҗә бигрәк тә М.А.Черкасскийның «Тюркский вокализм и сингармонизм» (М, 1965) китабында ачык бәян ителә -Р.Ә.

маларында да сүз азагында сузыксыз килеп серәеп калганнар. Шундыйлар арасында *-рг̣//рг* (*-rγ//rg*) чатлашмалар (комплекслары) да булган, һәм ул чатлашмалар еш кына, зәгыйфьләнеп, *-зг̣//зг* (*-zγ//zg*) булып әйтелгәннәр. Азактагы сузыклар тәмам югалып, онтылып беткәч бер группа телләрдә *-рг̣ //рг > -р* күчеше, икенче группада *-зг̣ //зг > -з* күчеше җиңеп чыккан. Шулай итеп, *-r(р)* һәм *z(з)* телләргә аеру пәйда булган. Шул ук вакытта *l(л)* авазының *č(ч)* тартыкчы белән чатлашмасы сүзләр азагында *r* – телләрдә *l* килеш, ә *z* - телләрдә *š* яңгырашында торып калган.

*R(р)*-ле телләләр, хунну (сюнну)лар белән булса кирәк, көнбатышка күченгәннәр.

*Z(з)*-ле телләләрдән бер яктан кыпчак төрки телләре, икенче яктан исә угыз төрки телләре аерылып чыккан. Кыпчаклар (кыпчак телләрендә тәүләп сөйләшүчеләр мәгънәсендә) үзәк төркиләрдән төньяктарак, ә угызлар исә көньяк-көнчыгыштарак яшәгәннәр дип уйларга кайбер нигезләр бар[45].

Югарыда әйткәнебезчә, угыз телләре сүз башындагы тоталь тартыкларның яңгыраулашуы белән, ә кыпчак телләре исә үзләрендә авазы булуы белән характерлана, һәм бу үзенчәлекләр, мөгаен, субстракт телләр тәэсирендә килеп чыкканнар. Гомумән төрки телләр Үзәк Азия һәм Себердәге бик күп телләрнең – шулар арасында тохар һәм сугди телләре кебек үз язу культуралары булган мәдәни телләрнең көчле йогынтысын кичергәннәр. Төрки тел Үзәк Азиядә халыкларның үз-ара аңлашу теле буларак киң таралып, үзенең шул функциясендә – ирани сугди телен җиңеп чыккан. Ләкин бу триумфаль процесста борынгы гомумтөрки тел нык үзгәргән – ул сүзләргә, тәгъбирләргә генә түгел, яңа фонемаларга да боерган һәм яңа фонемалар башлыча әлеге мәдәни телләрдән кергәннәр. Төрки халыклар төркиләштергән мәдәниятсез халыкларның телләре исә көнчыгыш кыпчакларда һәм Үзәк Азиядә калган угызларда фонетик ассимиляция вә диссимилияция күренешләрен китереп чыгарган. Ассимиляция – диссимилияция кишәре (полосасы) бүген якут, тува, ха-кас, алтай, кыргыз һәм казах (өлешчә каракалпак) телләрен үз эченә ала. Башта исә ассимиляция – диссимилияция ареалы Ангара бассейны һәм Енисей вә Умар (Объ) елгаларының югары агымнары өлкәсе белән чикләнгән булган булса кирәк.

Шунысы кызык ки, иң «чиста» кыпчак теле мишәрләрдә, карачай-балкарларда һәм караимнарда, аннары кумыкларда һәм Казан татарларында сакланган. Ләкин аларда да, әлбәттә, гасырлар дәвамында кыпчак теле төрле тәэсирләр кичереп һәм эчке үсеш процессында беренчел хәленнән нык үзгәргән: *ц*-ләштерү килеп чыккан, Төньяк

[45] K. F.Sumer. Oguzlar. Istanbul, 1992. С. 31-32.



Кавказ төркиләрендә *-р* авазының төшеп калу күренешләре үсеш алган, мишәр диалекты сузыкларның сыныльшын кичергән һ.б.

Себер һәм Үзәк Азиядә кыпчак элементлары көнчыгыштан көнбатышка таба кочәя баралар: якут телендә алар бик аз, тува телендә күбрәк, хакас телендә шактый сизелә, ә алтай теле кыпчак телләренә бик якын тора (кайбер телчеләр хәтта алтай-кыпчак берлеге турында сөйлиләр).

Морфологик һәм өлешчә фонетик билгеләр буенча якут һәм тува телләре угыз телләренә якынрак (ләкин тува телен уйгур группасына да кертәләр).

Гомумән, безнең карашыбызча, төрки телләрнең шәҗәрәсе түбәндәгечә тәсвир ителә ала.




*Язма ядкәрләрдә генә калган телләргә «*» билгесе куелды – Р.Г.*

Бу схемада хәзерге көндә үз-ара якын телләр мөмкин кадәр бер-берсенә якын куелды (тик телләренең үз-ара якынлыгын гына масштаб сыйдырмады).

Схемадан күренгәнчә, генеологик яктан бигүк якын булмаган телләр бүгенге көндә үз-ара бик якын булырга мөмкин. Бу икенчел якынлыклар йә күп гасырлар тыгыз мөнәсәбәтләрдә яшәү (мәсәлән, татар-башкорт якынлыгы), яисә тирәнтенге мәдәни уртаклык (мәсәлән, татар-уйгур якынлыгы) нәтиҗәсе була.

Совет власте елларында төрки генеологик якынлык шактый онытылды, кайбер очракларда төрки халыклар махсус рәвештә бер-берсеннән ераклаштырылды. Мәсәлән, казах әдәби теле патша Россиясе заманында татар теленә якын булса, 20- еллардан башлап яңа казах әдәби теленә күпләп кертелгән «автохтон» фәнни-техник һәм иҗтимагый-политик терминология бу телне күрше төрки телләрдән шактый ераклаштырып куйды.

Төркиядә госманлылар династиясе чорында кулланылган әдәби тел иске татар әдәби теленә шактый якын булса, шул ук 20-че еллардан барлыкка килгән яңа төрек телендә бу якынлык бетерелде, дияргә була.

**§65. Көнбатыш кыпчак берлеге**. Монгол яуларына кадәрге бер аралыкта X-XIII гасырларда Дунайдан алып Иртешкә кадәрле урман-дала кишәрлегендә гомум көнбатыш кыпчак тел һәм мәдәният берлеге шәйләнә башлый. XII гасырда борынгы татар-кыпчак теле Урта Иделдә дә хакимлек итә. Шул чорда рус кенәзләре Идел болгарларының һәм «половец»ларның «телләре бер» икәнлеген фиксациялиләр.

Кыпчак телләре гомумтөрки чыганаклардан безнең эра башларында аерымланганнар. Угыз халыклары төркиләшкән монголлардан килеп чыккан кебек, кыпчаклар төркиләшкән динлиннәр булса кирәк. Тел җәһәтеннән караганда кыпчакларның төп билгеләре булып түбәндәге тоталь фонетик күренешләр исәпләнә :

I) (иҗек) һәм сүз азагындагы *-ӷ* һәм *- г-* авазларының йә *-w-* азагына, йә, сирәгрәк очракларда, *-й-* авазына әврелүе яисә бетенләй җуелуы;

II) шул күренешкә баглы рәвештә интервокаль торыштагы борынгы төрки *-қ* һәм *-к* авазларының *-ӷ* һәм *-г* -гә көчәеүе. Ошбу процессларны түбәндәгечә күрсәтеп була:

*-қ, -к > -ӷ, -г //ӷ, г >w* яки *й*[46].

Бу фонетик билгеләргә кайбер уртак грамматик вә лексик билгеләр дә өстәлә. Соңгылары көнбатыш кыпчакларга күпләп кергән фарсы һәм гарәп мәдәни алымнары исәбенә дә арта барган.

[46] к. К.Г.Менгес. Восточные элементы в слове о полку Игореве. Л., 1979. С. 100. һ.б.



Гомумкыпчак этникосы VIII-IX гасырларда кинәт бик ишәеп китә – хәзергечә әйтсәң, демографик шартлау кичерә. Шуннан кыпчаклар яңа җирләр яулап алыр өчен Көньяк Себердән кузгалып көнбатышка юнәләләр. Шул ук чорда һәм шул ук максатлар белән, әмма көньяктарак угызлар да көнбатышка агылалар. Бу ике төрки агым кайбер урыннарда бер-берсенә ишелеп-кушылып, каты көрәшләргә сәбәп була. Нәтиҗәдә угыз телләренә кыпчак элементлары, ә кыпчак телләренә угыз элементлары күпләп керә. Угызлар гарәп хәрефләре белән бүтән төркиләрдән элегрәк яза башлыйлар һәм шунлыктан кыпчаклар да, болгарлар да «гарәпчә» язма телдә угызча формалар вә сүзләр күп була.

Гомумән, хәзерге төрки телләр элгәрге төрки телләрнең аерым элементлары кыйпылчыклары, өлтеләре яңача чатлашып, «халык төшкилләнү (ясалу)» чорларында уртак нормаларга китерелеп барлыкка килгәннәр. «Халык ясалу чоры» исә төрле халыкта төрле заманда булган.

Бу уңайдан тагын бер тапкыр шуны әйтергә кирәк: татар теленең нигезендә яткан көнбатыш кыпчак берлегенең теле һичшиксез XIII гасырга кадәр формалашкан. Көнбатыш кыпчак телендә төрки сүзләр генә түгел, гарәп-алынмалары да күп булган. Моны атаклы «Куман мәҗмүгасы» (СС – Codex Cumanicus) текстлары күрсәтеп тора. Мәсәлән,

| | |
|---|---|
| *Таму кабакыны бузуп,* | *«Тамуг капкасын бозып [ватып]* |
| *Тутгунларны сэн куткардың,* | *Тоткыннарны син коткардың,* |
| *Тушманны йэңдэчи булуп,* | *Дошманны җиңүче булып,* |
| *Атага тэңдэш олтурдуң.* | *Атага тиңдәш [булып] утырдың.* |
| | |
| *Ош ол рэхимиңа кőрэ* | *Шул рәхимеңә күрә* |
| *Йаманымызны кэчиргил.* | *Яманыбызны кичергел.* |
| *Мурадымызга тэйирэ,* | *Муратыбызга тиереп [җиткереп]* |
| *Йүзүң кőргүзүп тойурӷул.* | *Йөзең күргезеп туйдыргыл.* |

Бу юлларда хәзерге татар телендә булмаган бер сүз дә, бер грамматик форма да юк (*=дачы//дәче* кушымчасы мишәр сөйләшләрендә бар). Иң әһәмиятлесе шул – аларда әдәби телебездә хәзер дә кулланылган *тушман – дошман, рэхим – рәхим, мурад – морат* гарәп-фарсы алынмалары бар. Һәм барча текстларда да шул хәл. Шунлыктан атаклы алман тюркологы А. фон-Габэйн куман телен татар теленең турыдан-туры элгәре дип саный. Аның фикеренчә куман әдәби-поэтик теле озын традициягә ия – XIII гасырдан күп элек формалашкан булган (к. аның Kuman edebiatı//Türk dünyası edebiatı. Istanbul, 1991:18).

Куәтле куман-кыпчак мәдәнияте һәм теле бүтән төрки (һәм төрки түгел) телләрне, мәсәлән, үз юлына очраган угыз диалектларын йоткан. Моның кызыклы мисаллары чуваш телендә күренә. Чуваш теле белән угыз телләре арасында ачык беленгән фонетик, морфологик һәм лексик уртаклыклар бар. Һәм ул уртак моментлар кайбер очракларда кыпчак телләре иләгеннән үткәннәр. Моның кызыклы бер чагылышы – болгар башбаталарның *уафат блтуы* сүзе: монда *блтыуы ~ ултыуы* угызча *булдыгы* сүзенең кыпчаклашкан яңгырашы гына ул.

Кыпчакларның (һәрхәлдә көнбатыш кыпчакларның) көнбатышка – Көнчыгыш Европага табан хәрәкәте һәм һәм киң таралуы, әлбәттә, монгол яуларыннан берничә гасыр элек башланган. Рус елъязмаларында теркәлгән половец (кыпчак-куман) исемнәре, мәсәлән, *Башкорт, Сююнч* (*Сөенеч*), *Каялы* (елга атамасы), *чага* (кол кыз) сүзе һ.б. татар һәм көнбатыш телләренең фонетик вә лексик нормалары буенча төзелгәннәр.

Рус тарихчылары һәм филологлары кайчакта монгол яулары белән бергә «гаять зур төрки массаллар күченеп килгәнлеге (эмиграция огромных масс) һәм нәтиҗәдә Көнъяк-Көнчыгыш Европа илатының бөтенләй алмаштырыуы турында язгалыйлар, к., мәс., Я.Р. Дашкевичных Codex Cumanicus турында «Вопросы языкознания» журналында (өч санда – № 3,4, 1985, № 2, 1988) чыккан зур макәләсе шуны күрсәтә. Ләкин бу фикер тарихи чыганаклар белән дә, тел тарихы материаллары белән дә расланмый. Аннары, югарыда әйткәнебезчә, шундый сорау туа: аңарча кайда яшәгәннәр соң ул «массалар»?

§66. Тарихи чыганакларда Көнчыгыш-Европаны яулап алу өчен килгән Батый явында төп монголлар нибары 2000-10000 генә булып, 120-130 меңлек гаскәрдән калган өлеш аларга ияргән бүтән кавем-кабилә вәкилләреннән гыйбарәт булган. Барча гайри-монголлар Батый гаскәрендә татарлар дип аталганнар. Ләкин ул татарлар арасында элек Монголиянең көнчыгышында яшәп, Чыңгыз хан тарафыннан туздырылган-кырылган татар[47] кавеме калдыкларыннан башка төрле кыпчак, чиркәс һ.б. халык вәкилләре, шулар җөмләсеннән хәтта руслар да булганлыгы билгеле. Бу чуар масса монгол яуларында толпа ролен уйнаган ягъни иң алдан сугышка кертелгән. Шуңа күрә алар күпләп кырылганнар да. Билгеле, Батыйның хәрби эспедицияләре тәмамланган чорда ул чуар токымлы «татарлардан» иң күп дигәндә 40-50 мең кеше калган булырга тиеш. Хәтта ул заманда да илле меңлек тупламны

[47] Ул «татарларның» төрки телле булуы да бик ихтимал, ләкин аларнын теле кыпчак группасына каравы шикле. Ул көнчыгыш татарлар һәм аларның токымнары турында к. P.Fahretdin. Altınordu devleti ve tatarlar//Türk yurdu, №7 (cilt16). Ankara, 1993, C. 17-23.



«гаять» зур массалар»» дип әйтеп булмый. Аннары бу илле мең (хәтта йөз мең дип алсак та) Көнчыгыш Европа вә хәзерге Казахстанның гаять зур киңлекләренә сибелгән, һәм аларның нәкъ Урта Иделгә күчеп утырулары турында бер хәбәр дә юк. Юк инде, Көнчыгыш Европаның, Урта һәм Түбән Идел буйларының этник йөзен монголлар берничек тә кискен рәвештә үзгәртә алмаганнар. Дөрес, халыклар болгатылуы нәтиҗәсендә элекке этнослар югалган, яңалары барлыкка килгән, ләкин алар иске материалдан барлыкка килгәннәр. Һәм аларның тел материалы да югалып бетмәгән.

## АЛТЫНЧА БАБ
## БОЛГАР ТЕЛЕ МӘСЬӘЛӘСЕ. БОЛГАР ҺӘМ ТАТАР ФОНЕТИКАСЫ

§67. Галимнәр борынгы болгар кабиләсе һуннар союзы (IV-V гасырлар) кергән һәм аерым бер төрки телдә сөйләшкән; Азов буе болгар дәүләте VII гасырда эчке каршылыклар һәм хазарлар ясаган ударлар нәтиҗәсендә таркалгач, ул чагында берничә кабиләгә бүленгән болгарлар төрлесе-төрле якка киткәннәр һәм шуларнаң бер өлеше (Батбаян группасы) Урта Идел регионына килеп Идел болгарлары дәүләтен нигезләгән, дип баралар.

Бу концепциягә каршы кешеләр күп булса да, алар әлегә аны җимерә һәм үзләренең фәнне канәгатьләндерерлек концепцияләрен тудыра алмадылар. Һәм без дә, кайбер искәрмәләр белән, әлеге концепцияне кабул итәбез.

Батбаян болгарлары Азов буйларыннан киткәч тә Урта Иделгә килеп җитмәгәннәр булса кирәк. Алар башта кайдадыр Жигули тауларында күчмәчелек итеп, VIII гасырда гына Урта Иделгә (хәзерге Татарстан территориясенең Көнъяк-Көнбатыш өлешенә) килепултырганнар һәм дәүләт корганнар дигән фикер бар.

Монда шуны әйтергә кирәк: кайбер тарихчылар болгарлар монда килгән беренче төркиләр булган дип уйлыйлар. Бу безнеңчә дөрес түгел: кайбер археологик һәм язма чыганакларга караганда, бу җирләрдә, төрле финн-угор халыклары белән аралашып, төрле төркет төркиләре дә яшәгән. Язма чыганаклар, мәсәлән, VII гасырда Урта Иделдә *гурк* һәм *майҗар* дигән төрки кабиләләр яшәгәнлеге турында таныклык бирәләр. Аларга кадәр үк биредә *акацир* дигән һунн кабиләсе яшәве мәгълүм. Ибне Фадлан язмаларында һәм шул чордагы бүтән язмалар Болгар дәүләтендә болгарлардан тыш *бәрәнҗәр (баранжар), эсегел, барсыл берсула, тәмтүз* һәм *сувар* этнонимнары искә алына. Аларның барысы да болгарча сөйләшкән булулары бик икеле. Күрәсең, әзәлдән үк Урта Идел – Көнъяк Урал регионындагы ике типтагы – төркет һәм болгар тибындагы телләр янәшә яшәгән булса кирәк.

XII гасырдан башлап биредә борынгы *берсула, бәрәнҗәр, эсегел, тәмтүз* кебек кабиләләр түгел, *йәмәкләр* һәм *хомоллар* (куманнар?) гына искә алына. Күрәсең, элекке Болгарстан үзәкләрендә кыпчак халыклары һәм кыпчак шивәләре өстенлек ала.

Шул чорда болгарларның бер өлеше төньяккарак китеп, хәзерге Чабаксар тирәләрендә Веде Суар шәһәрен нигезлиләр. Анда шул чордагы рус вә көнбатыш чыганакларында *Вяда, Видин, Видавия* дигән ил – халык искә алына. Хәзерге мордва телләрендә *ведене, ведьке* дип чувашлар атала. Чуваш фонетикасында мари (чирмеш) теленең көчле йогынтысы күренеп тора. Шуның белән бергә, олык мари һәм чуваш телләре өчен уртак үзенчәлекле хасият бар: элекке (гомумтөрки һәм борынгы мари) палаталь – йомшак әйтелешле сүзләр боларда веляр – каты әйтеләләр: чув. *кун* – «күнмәк», *кура* «(шуңа) күрә», *паранкă* «бәрәңге» һ.б. Барлык бу фактларны бүтән тарихи мәгълүматлар белән чагыштырып, тарихи закончалыкларга нисбәтләгәндә шундый нәтиҗә чыга: хәзерге Чувашстанның төньягында бер умак славян яшәгән. X-XII гасырларда болгарлар һәм марилар аларны ассимиляцияләгәннәр һәм шул процесста чуваш вә улык мари халыклары формалашкан. Мордваларның *ведене* дигәне славянча *ведене*, ә *ведьке* дигәне *ведьские* сүзеннән түгелме икән? Ә *Веде-Суар* атамасы исә борынгы марича *Уда Суар* «Яңа Суар» дигәннән булырга мөмкин.

Ләкин борынгы татарлар да тик тормаганнар: XII гасырның икенче яртысында (рус чыганаклары буенча 1177 елда) борынгылар Казансу елгасы буенда Казан каласын нигезләгәннәр. Ул чорда кала тирәсендәге урман-кырларда болгарлар һәм марилар яшәгәннәр булса кирәк, чөнки Казан чувашча *Хузан<Хозан*, марича *Хозаң, Хазаң, Озаң, Азаң* (ķ >х>h ~ ноль – болгар теле билгеләре, к. түбәндәрәк), тик удмуртча гына *Казан, Кузон*. Ләкин шәһәрнең киң таралган халык-ара исеме татарча - *Казан, Казаң* булган (безнеңчә ул Казангы дигән сүздән – елга исеменнән). Бу хәл кала халкының баштан ук татар булуы турында сөйли.

Әмма ул чордагы татар теленә караган текстлар безгә килеп җитмәгән. Хәер, андый текстларның булуы да шикле, чөнки гомумтөрки (төркетчә) телдә сөйләшүче төркиләр барысы да уртак бер әдәби телдә – Әхмәт Яссәви телендә язарга тырышканнар.

Болгардан чыккан галимнәр үзләренең җитди әсәрләрен ул заман гадәтенчә гарәп телендә яза торган булганнар. Аларның гарәпчә язылган әсәрләрендә дә Болгарстан телләренең аерым чагылышлары бик булгандыр – тик ул әсәрләр дә безнең көннәргәчә килеп җитмәгәннәр.

Шул сәбәпләр аркасында Болгарстандагы борынгы телләр турында мәгълүматлар аз сакланган.



§68. Болгарстанда XIII гасырда язылган әдәби әсәр дип Колгали дигән кешене «Кыйссаи-Йосыф» дигән шигъри романы исәпләнә. Һәм бу фикергә килергә кайбер нигезләр дә бар.

«Йосыф Кыйссасы» ның Урта Иделдә XIII гасыр башында (монгол яуларына кадәр) иҗат ителүе бик ихтимал, ләкин аның шул чорда язылган төп нөсхәләре безгә килеп җитмәгән. Монголларга кадәрге болгар чорыннан бары таңкәләр калган, тик аларда ялгызлык исемнәр генә язылган.

Борынгы Урта Иделдәге язма тел ядкәрлекләренең төп нөсхәдә безнең чорга килеп җиткәннәреннән иң борынгылары – башбаталар. Алардагы иң әүвәлге язмалар исә монгол яуларыннан соң, башлыча XIV гасырда язылганнар.

§69. Борынгы кабер ташлары (гарәпчә фатиха сүзләрен исәпкә алмаганда) ике телдә «*r* вә *l*» һәм «*z* вә *š*» телләрендә язылганнар. XIV гасырның беренче яртысында язылганнары башлыча «*r* вә *l*» телендә, ә шуннан соңгыларында «*z* вә *š*» ягъни татар теле өстенлек итә һәм торабара бердәнбер «эпитафик» тел булып кала.

Эпитафияләрдәге *r* вә *š* тел, чиксез, чуваш теленең күп кенә аергыч үзенчәлекләренә ия. Чуваш теле белән болгар эпитафияләрендәге «*z* вә *l*» теле арасында түбәндәге уртаклыклар бар:

а) гомумтөрки *о, и(у), ö, ӥ (ү)* урынына *иа(уа), иŏ(уŏ), ӥä(үә), ӥө(үө)* килү (чуваш телендә бу дифтонгылар *-ыва, -ыйва, -ĕве* булып әверелгәннәр);

б) гомумтөрки килеш кушымчаларынан *-da//de>-ra//re, -dan//den, -tan//ten>ran//ren* булып, үткән заман хикәя фигыль кушымчасы *–dy//dĕ, -ty//te > ra/re* булып әверелүләре (ягъни кушымчаларында *–d, -t>-r*),

в) *γ, к>х, h* көчеше,

г) югарыда әйтелгәнчә, ротацизм һәм ламбдаизм, «*r* вә *l*»,

д) кайбер яңгырау тартыклар урынына саңгырау тартыклар килү (мәсәлән, угыз формасы *boldyγy>byltuy*),

е) *t>č*

ж) кайбер очракларда *r* һәм *l* авазларының төшерелүе,

з) күплек аффиксы *–sam//sem*,

и) *-sa* (шарт фигыль) аффиксының хәл фигыль мәгънәсендә кулланылу, (к. чув. һәм болгар *tusa* «итеп»),

й) юнәлеш килеш кушымчасында *-γ-, -g-, -q-, -k-* төшеп калып, тик (угыз телләрендәгечә) *–a//e* торып калу,

к) кайбер исемнәрдә азаккы *–ах//ех//х* аффиксы (эпитаграфиядә *ajух>*чувашча *ойăх>уйăх* «ай»),

л) тәртип, сан кушымчасы *–ym//em//m, (-ым//ем//м),*

м) кайбер уртак сүзләр вә тәгъбирләр (мәсәлән, эпитафияләрдә һәм чувашча *jal* «авыл», *tu-* «итү, ясау», эпитографияләрдә *mŭn>* чувашча *мăн* «зур, бөек»)[48].

Менә бу уртаклыклардан чыгып кайбер рус галимнәре (Н.И.Ашмарин һ.б.) һәм чуваш тикшернүчеләре болгар эпитафияләре телен «борынгы чуваш теле» дип игълан итәләр. Ләкин бу дөрес түгел. Эпитафияләрдә «*r* вә *l*» телендә чуваш теленең түбәндәге үзенчәлекләре күренми:

а) бик күп сүзләр велярлашу (*-а>й, -и, -е, -у,* һ.б.)

б) сүз башындагы тартыкларның тоталь саңгыраулашуы (*-в>р, γ-, g->k-, d>t, з>s', z>s* һ.б)

в) тоталь *v>w*,

г) күп очракларда *s>š*. Бу үзенчәлекләр чуваш телен болгар теле белән түгел, мари теле белән берләштерәләр. Болардан тыш чуваш теленең үзендә килеп чыккан интервокаль яңгыраулашу һәм *a>o>u(y)* күренешләре дә эпитафияләр телендә юк. Ә бит әйтелгән үзенчәлек һәм күренешләр чуваш теленең һәр сүзендә диярлек чагыла, әмма югарыдагы болгар үзенчәлекләре алай ук еш чагылмый. Шуңа күрә эпитафияләрдәге «*r* һәм *l*» телен «борынгы чуваш теле» дип, ә чуваш телен «яңа болгар теле» дип тәгърифләүне кире кагарга туры килә. Чуваш телендә болгар теленең аерым элементлары (һәм иң кызыклы элементлары) сакланган – чуваш теле гомумән шуның белән игътибарны җәлеп итә дә, – ләкин кайбер Урта Идел болгар теле үзенчәлекләре (болгар вокализмы һ.б.) татар телендә әйбәтрәк сакланып килә.

Болгар теленең венгр телендәге сүзләрдә чагылган үзенчәлекләре ул телне чуваш теленнән тагын да ераклаштыралар. Ул борынгы болгар телендә:

а) *a>o>u* һәм *ä>a* булмаган,

б) гомумтөрки *-o* һәм *-ő* сакланган,

в) сүз башында тартыкларның саңгыраулашу законы булмаган,

г) *q>x ~ h* көчеше дә күзәтелми[49],

Болгар теленең Урта Иделдә татар теленә нисбәтән борынгырак булуы бик бәхәсле вә шикле. Татар телендә язылган башбаталар XIV гасыр башында болгар телендә язылганнардан азрак булсалар да, абсолют

[48] к. Федотов М.Р. Булгарский язык и его отношение к некоторым финно-угорским языкам//«Советское финно-угроведение», 1968. №1, С. 53-66; Ул ук: Отношение чувашского и общетюркского языков к языкам хазар, дунайских и волжских булгар, а также финно-угров//СТ, №3, 1979. Хакимзянов Ф.С. Язык эпитафий волжских болгар. Изд. «Наука», М., 1978, С. 69-76; Р.Г.Ахметьянов Р.Г. Рецензия на книгу Ф.С.Хакимзянова. СТ №5, 1979, С. 108.

[49] Gombocz Z. Die bulgarisch-türkischen Lehnwörter in der ungarischen Sprache//Memoires des societe fenn-ougrienne, t. XXX. Helsingfors, 1912.



борынгылык ягыннан алар болгар телендә язылганнардан калышмыйлар. Татар телендә башбата язучы мәрхүмнәр үзләрен (XIV гасырның иң башында ук!) әс-Сувари, әл-Болгари дип атыйлар[50]. «Монголлар белән килгән килмешәкләр» һәм аларның угыл-кызлары үзләрен шулай дип атарлар иде микәнни? Менә шул факт кына да Н.И.Ашмаринның чувашларны «асаба халык», ә татарларны «соң гына килгән килмешәкләр» дип билгеләвен юкка чыгарырга җитәрлек бит! Монголлар килгәнче Болгар дәүләтендә татар телләләр күпләп яшәвен факт дип исәпләргә мөмкин.

Конкрет маглуматлар да Н.И.Ашмарин фикерен бигүк расламый.

Ибне-Фазлан язмаларында ике болгар сүзе исә алына: سجو «бер эчемлек төре» һәм سحراج «тустаган». Бу сүзләр чуваш телендә юк – алар хәзерге угыз телләренең диалекталь лексикасында гына табыла.

X гасырда шәрекънең иң бөек тарихчысы А.Бируни Болгар сувар-лары «төрки һәм хазар телләре катнашмасында сөйләшәләр» дип хәбәр итә. Төрки дигәннән монда гомумтөрки *z* вә *š* – тел күз алдында тотыла дип уйларга кирәк[51].

Коми телендәге «болгар алынмаларында» гомумтөреи яңгырашлар өстенлек итә һәм «чувашча»рак бер генә сүз бар: *чарла* «урак».

XI гасырда язган М.Кашгари болгар һәм сувар телләреннән җиде сүз китерә: *aбaq* «аяк», *avus* «балавыз», *bal* «бал», *kŏkläšti* «туганлашты», *lav* «пичәт өчен кулланыла торган балавыз», *tozdy* «туйды», *jalŋuq* «кол кыз».

Бу сүзләрнең берсе дә «*r* вә *l*» теленең яисә, чуваш теленең аергыч билгеләренә ия түгел. *Бал* сүзе татар телендә бүген дә шул яңгырашта (чувашча ул *пыйл*), *лав* сүзе (шул мәгънәдә ул кытай телендә бар икән) хәзер төрки телләрнең берсендә дә кулланылмый. Калган сүзләрне шул яңгырашларында төрле төрки телләрдән табып була, ләкин нә татар телендә, нә чуваш телендә алар йә гомумән юк, йә алай яңгырамыйлар (*күкләшмәк* Себер татарларында «тамырлашмак» мәгънәсендә йөри).

Хәер, бу сүзләр буенча гына катгый нәтиҗәләр ясап булмый: алар биргән мәгълүматлар очраклы чыганаклардан алынганнар.

Мәхмүт Кашгари китергән сүзләрдә *авус* (*awыс*) балавыз сүзе кызыклы. Бу сүз чуваш телендә дә бар: *ăвăс (авыс), ус*. Ләкин ул татар теленең мишәр диалектыннан алынган: мишәрчә *авыз, ыуыз, уыз,* татар теленең Гәйнә һәм Залтавыз сөйләшләрендә *увыз, убыз* «угыз (сыерның ул бозаулагач савыла торган сары төстәге бик куе сөте)», *бал увызы, бал*

[50] К. F.S.Hakimzjanov. New Volga bulgarian inscriptions. Acta Orientalia (Budapest). XL. 1986, P. 173-177.

[51] А.Бируни. Избранные произведения. т. I. Ташкент, 1957. С. 55.

*уыз* дип (төсе буенча) балавызны атыйлар. Димәк, М.Кашгари болгар сүзе дип тәгърифләгәнн *ауыс* сүзе – мишәрчә! Тик менә Мәхмүт Кашгариның сүз азыгында *–с* язуы гына уйга калдыра, ул йә информантның әйткәнен ачык кына ишетмәгән яисә болгарлар (чувашлар шикелле үк) сүз азагындагы з-не саңгыраулаштырганнар, «с» дип әйткәннәр. Һәрхәлдә М.Кашгари сүзлегендәге бу сүз Болгарстанда кыпчак-мишәр шивәсенең дә тәэсире булганлыгын дәлилли.

§70. Ул болгарлар белән күп гасырлар буенча бергә яшәгәч, татар телендә болгар теленнән күп кенә алынмалар булырга тиеш иде. Әмма татар гомумхалык һәм әдәби телендә болгар теле билгеләре булган сүзләр бик аз. Шундыйлардан түбәндәгеләр аеруча характерлы:

*бирән* «күп ашаучы» – болгарча **биран* > чувашча *пыран* «бирән» – *пыр (пыйр)* «тамак, бугаз» < борынгы төрки *boɣur «бугаз» (шуннан татар сөйләшләрендә *богырлану* «тамакка килгәнче ашау»); мондагы ротацизм – болгар теле билгесе.

*Түтәрәм* «чирек, нәрсәнең дә булса дүрттән бер өлеше» болгарча *тәүтәрәм* (чувашча *тăватар-ам*) «дүртенче (өлеш)» дигәннән.

Татар сөйләшләрендә *билек* «бишенче ай» (ламбдаизм).

*Хыйтлан-мак* «азап кичермәк, азапланмак» – Мөхәммәдъяр Мәхмүт телендә *кыйтланмак* диелә; *к>х* болгар теле билгесе. Ләкин әле бу гына түгел. Бу сүз йә борынгы төрки qatyɣlan-maq «тырышып эш итмәк», йә төрекчә һ.б. *каhтламак* «азап кичермәк» (гарәпчә قاهت «кыенчылык, ачлык, фәкыйрьлек») сүзеннән. Һәр очракта *а>ый* күчеше булган була, ә бу икесе – шул ук болгар теле билгесе.

*Хәситә* – эченә касыйдә язып төрелгән бөти (диалекталь сөйләмдә *каситә, хәсилтә, касыйдә* диелә). *Касыйдә* сүзен *хаситә* дип бозуда да (*к>х, д>т*) болгар теле билгеләре күренә.

*Көре* – чувашча *кĕрĕ* ~ уйгурча *кузук*. Монда ротацизм – болгар теле галәмәте (димәк *көре* – болгар теленнән).

Ошбу болгар сүзләре бу телдә сөйләшүчеләрнең шактый мәдәни һәм сәвәтле, укый-яза белә торган халык булуы турында сөйли. Ләкин ни өчен соң болгар сүзләре татар телендә шулкадәр аз? Моңа җавап шул: беренчедән, мәдәни җәһәттән татарларның бабалары – борынгы татарлар, дисәк тә ярый – болгарлардан һичкайчан калышмаганнар, икенчедән, ул болгар телләләр һичкайчан артык күп булмаганнар.

Бүген безнең бөтен белгәннәребез, кыскача әйткәндә, түбәндәгеләргә кайтып кала: болгари тел гомум төркилектән, инәкә төрки телдән иң тәүләп аерылган һәм, шуңа күрә, иң борынгы төрки шивәләрнең бүтән (хәзерге) төрки телләрдә сакланмаган күп кенә үзенчәлекләрен (шул хисаптан фонетик үзенчәлекләрне дә) үзендә саклаган тел булган.



Борынгы болгарлар Урта Идел регионына килгәч болгар теле субстрат (җирле төрки һәм финн-угор телләре) тәэсирендә тирән үзгәрешләр кичергән.

XIV гасыр болгар теленең вокализмы татар вокализмына бик якын булган һәм, гомумән, ул тел татар теленә хәзерге чуваш теленнән күп якынрак була. Ләкин болгар консонантизмы һәм морфологиясе татарныкыннан шактый аерылып торган.

## ҖИДЕНЧЕ БАБ
## АЛТЫН УРДА ҺӘМ КАЗАН ДӘҮЛӘТЕ ЧОРЛАРЫНДА ТАТАР ТЕЛЕ

§71. Төрки телләр борынгы заманнардан ук күп кенә катаклизмнар нәтиҗәсендә тармакланып яисә берләшеп килгәннәр. Тик XI-XII гасырларда әхвәл бераз стабильләшә төшкән: Үзәк һәм Урта Азиядә, Идел буйларында һәм Кара диңгезнең төньягында тотрыклы дәүләтләр оешкан. XII гасыр азагында хәтта кыпчак-рус сугышлары да басыла төшкән. Тик XIII гасыр башында килеп чыккан монгол яулары төрки халыкларга яңа бер катаклизм китергәннәр.

XIII гасырның 40-нче елларында монгол яулары нәтиҗәсендә Алтын Урда дәүләте төзелә. Ул XV гасыр урталарына кадәр азмы-күпме дәрәҗәдә бербөтен булып яшәгән дәүләт. Шуннан соң тагын өч йөз ел дәвамында Алтын Урда кешеләр аңында актуаль идея буларак яши: кешеләр аны яшәтү өчен яисә, киресенчә, аны кабат торгызмас өчен көрәшәләр, кан коялар.

Ике йөз ел гомер – кимендә алты буын алмашу дигән сүз. Шул аралыкта үз теле, үз дене булган кавем-этнос барлыкка килергә тиеш иде. Алтын Урда, һәрхәлдә аның төп өлеше, кинәт яулап алу нәтиҗәсендә туган ясалма империя генә булмаган бит: аның күптән әзерләнгән реаль этник җирлеге, көнбатыш кыпчак бергәлеге, географияк нигезләре һ.б. да булган. Ләкин аның яшәвенең уңайсыз шартлары, иң беренче чиратта тарихи перспективасы булмаган күчмәчелек тридицияләре иәэсирлерәк булып чыкканнар.

Классик күчмәчелек ул яшәү рәвеше генә түгел – аның үзенең халык үрчү законнары, мораль вә этикасы, эчке вә тышкы политикасы, сугышу-килешү рәвеше һ.б. да үзенчә. Һәм менә болар барсы да XV гасырдан башланган яңа заманнар өчен бөтенләй яраксыз булып чыкканннар.

Төрки-монгол күчмәнчелегендә «нормаль» яшәү өчен бик киң запас бул мәйданнар – борынгы кыпчакча әйткәндә, *аулаклар, абрау* җирләре кирәк. Моның өчен исә дәүләттә кешенең артык күп булмавы зарур. ҺәмАлтын Урда да илатны (население) бик чикле санда тоткан, һаман

«чәчүлекләрне көтүлекләргә әйләндерергә тырышкан». Нәтиҗәдә ул илатны (население) утрак дәүләтләр белән көрәштә ярдәмсез калган.

Күпгасырлык традиция буенча төрки-монголлар өч «кулга» (колоннага) – уң, сул һәм урта кулларга бүленеп, *урта кул* дигәненә хәрби хәзерлеге түбәнрәк составны куйганнар. Шуннан *уртакул* «бик шәп түгел» сүзе калган. Сүзе хәзер дә бик тәгъбирле, әмма *өч кул* тактикасы XV гасырга килеп тәмамән искергән, җиңү китерми башлаган.

Алтын Урда хакимлеге астында төрле халыклар – төркиләр, славяннар, төрле җенестәге Кавказ кавемнәре, финн-угорлар, Кара диңгез греклары һ.б. яшәгәннәр. Ләкин шул заманның тарихчылары бик ачык әйтеп калдырганча, Алтын Урданың төп туфрагында илатның күпчелеген кыпчак төркиләре тәшкил иткән.

Уртак нигезгә барып тоташсалар да, һәм, әйткәнебезчә (§57) гомумкыпчак берлеге шәйләнсә дә, кыпчак телләре ул заманнарда бөтенләй үк бердәм булмаган, әлбәттә. Әйтик, бер яктан Днепр буйларындагы каракалпаклар («черный клобуклар») һәм куманнар, икенче яктан Урта Идел регионындагы *каңгылар* һәм Иртеш буйларындагы *йәмәк татарлары* бер үк телдә сөйләгәннәрдер дип раславы кыен, чөнки аларның тормыш рәвешләре вә аралашкан халыклары үзгә-үзгә булган бит. Барча кыпчаклар бер дәүләт – Алтын Урда чикләрендә калгач (без соңрак формалашкан Күк Урда һәм Ак Урдаларны да Алтын Урда тәркибендә дип карыйбыз), гомумуртак кыпчак теле пәйда булу ихтималы туса да, бу мөмкинчелекк файдаланылмый калган. Ни өчен дигәндә, Алтын Урданың иң тотрыклы чорларында да дәүләт политикасы тел бердәмлеге булдыруга юнәлдерелмәгән һәм телләрнең тәңгәлләшү процессы бик авыр барган.

Моның төп сәбәпләренең берсе – Алтын Урданы нигезләүчеләр кыпчаклар һәм хәтта төркиләр дә түгел, ә монголлар булуында.

Алтын Урда корылган дәвердә монголлар, билгеле, үз телләрендә идарә итәргә теләгәннәр. Монгол теленең ул вакытларда шактый эшкәртелгән хәрби вә илдарлык идарә терминологиясе булган. Могул гарнизоннары рус теленә шул чорда *башня* (монголча *башин*), *булава* (монголча *болува, болва*), *дорога* (монг. *даруга*), *кнут* (монг. *кунту, кунт*), *мерин* (монг. *мөрин* «җигемлек ат») сүзләре кергән. Татар телендә дә күп кенә (йөзгә якын) монгол сүзе бар. Аларның кайберләре (*дүнән* – дүрт яше, тулган ат, *кодагый, елга, нарат*) бүтән төрки телләрдә дә очрый, ә кайберләре (*болагай, комагай, җилбәгәй; бакалтай, сакалтай, чаган*) башлыча татар теленә хас (ягъни бүтән төрки телләрдә сирәк очрый яисә татар теленнән кергән). Шунсы игътибарга лаек ки, рус телендәге монгол алынмалары татар телендә очрамый диярлек һәм



тематика буенча да үзгәчә. Рус телендәге монгол сүзләре башлыча ямылчылыкка карый, ә татар телендәгеләре кешене тәгърифләүгә һәм табигать объектларына карый.

Тарихтан мәгълүм булганча, Алтын Урда монголлары йөз ел эчендә тәмамен кыпчаклашып беткәннәр. Монда монголларның аз санлы булуыннан тыш, башка факторлар да үз роль уйнаган. Хәрби оешма кору җәһәтеннән бик югары торсалар да, монголлар гомуми мәдәниятләре ягыннан төркиләрдән түбәнрәк булганнар. Монголлар ямылчылыкны бик оста оештырганнар (монголлардан калган ямылчылык системасы Россиядә XIX гасырга кадәр сакланган), әмма дәүләт чикләрен саклау, кирмәннәр төзү аларга хас булмаган. Шунсы характерлы –Алтын Урданың башкаласын монголлар, үзләренең туган якларындагы коры далаларга охшашлыгы өчен генә булса кирәк, бөтенләй яшеллексез кола яланга төзегәннәр (бу хатаны Бәркә хан гына бераз төзәткән).

§72. **Дәүләт теле һәм язма теле.** Монгол теленең хәрби һәм административ йылкычылык һәм транспорт терминологиясе шактый бай булса да, дәүләт тоту өчен мотлак кирәкле бүтән өлкәләрдә – сәүдә вә һөнәрдә, әдәбият вә сәнгатьтә, диндә вә идеологиядә ул тел мөселман төркиләре теле белән ярыша алмаган. Уйгурстанда һәм Урта Азиядә XI гасырда үк Мәхмүт Кашгариның лингвистик хезмәтләре, Йосыф Баласагунының *Кутадгу Билик* («Котайткыч белек») поэмасы кебек зур күләмле әдәби әсәрләр, XII гасырда исә Әхмәт Яссави, Сөләйман Бакыргани һ.б. күп кенә шагыйрьләрнең бай эчтәлекле әсәрләре иҗат ителә. Нәтиҗәдә гаять бай язма әдәби терминология һәм фразеология барлыкка килә. Ул телнең фонетик (бигрәк тә консонант) һәм күп кенә морфологик нормалары татар теленекенә якын булган (к. §35-36).

Бу әдәби тел бөтен төрки дөньяга – шул хисаптан кыпчак-куманнарга да, Идел болгарларына да, шулай ук угыз халыкларына – төрекмәннәргә, азәриләргә, Анатолия төркиләренә һ.б. билгеле булган. Чөнки ул X-XIII гасырларда кирәгенчә үсешкән һәм шул чорда кирәкле сыйфатларга ия булган бердәнбер язма тел була. Гарәп хәрефләре Евразиянең бөтен көньяк-көнбатышын берләштергән.

Гарәп хәрефле угызчарак язма тел X-XI гасырлардан башлап барлык кыпчакларда да кулланылган дип уйларга бөтен нигезләр бар. Шул телдәге әдәбиятның гүзәл үрнәге – Колгалинең «Кыйссаи Йосыф» китабы булса кирәк. Гомумән, язма телнең угызчарык булырга тиешлеге татарның канына шулкадәр сеңгән ки, XVIII гасыр документларында *Катай* (башкорт кабиләсе исеме) сүзен *Гадай* дип язу һ.б.ш. күзәтелә.

Кыпчак телләре, әйткәнебезчә, ике зур төркемгә – көнбатыш һәм көнчыгыш асгруппаларына бүленә. Көнбытыш кыпчак телләренә татар, кырымтатар, кумык, карачай-балкар, караим телләре, ә көнчыгыш груп-

пага кыргыз, казах, каракалпак, нугай телләре карый. Башкорт теленә килгәндә, ул үзендә бик көчле төрекмән һәм монгол элементлары булмыш кыпчак диалектларын берләштергән, ләкин ул Алтын Урда чорыннан XIV гасырдан башлап татар теленең бик көчле йогынтысына эләккән һәм хәзер инде лингвистик җәһәттән татар теленең бер диалекты дип аталса да хакыйкатькә хилаф булмас.

Хәзерге көнбатыш кыпчак телләренең нигезе – куман (половец, кун) теле булса кирәк. Көнчыгыш кыпчак телләре борынгы кыпчак тибыннан ераклашулары белән характерланалар һәм аларда уртак хасиятләр соңрак пәйда булганнар.

Монголлар үзләренең төп дошманнары итеп нәкъ менә кыпчакларны исәпләгәннәр. Шуңа күрә алар кыпчак халыкларын пыран-заран китергәннәр, куманнарны кырганнар һәм кол иткәннәр, «черный клобукларны» (каракалпакларның Днепр буендагы яшәгән борынгы бабаларын) көнчыгышка күчергәннәр: аларның бер өлеше Нугай дигән монгол бие кул астына кереп, хәзерге нугай халкының башлангычы булып киткән.

Урта Иделдә лингвистик әхвәл монголлар килгәч эллә ни үзгәрмәгән. Борынгы Кубрат болгарларының теле Болгар дәүләтендә озак өстенлек итә алмаган. Тиз арада беренче урынга биредә төбәктәге вокализм белән үзенчәлекләндерелгән кыпчак теле ягъни борынгы татар теле чыккан. Чөнки шул кыпчак-татар теле генә Болгарның төп сәүдә һәм аралашу контрагентлары – һәрле ерак вә якын төркиләр белән җиңел аралашырга мөмкинлек биргән (шуңа күрә генә XIII гасыр башларында рус ядкәрлекләрендә болгар һәм половец телләренең бердәй булуы искәртелә).

Борынгы татар теленең төп фонетик үзенчәлекләре – аның башлыча җирле субстрат тәэсирендә формалашкан вокализмы һәм нигездә борынгы язма телләрдән калган, ләкин үзенә кыпчак теле билгеләрен (*к,, к>г, г//г, г>w)* дә үзләштергән консонантизмы Алтын Урда чорында да үзгәрмәгән, әлбәттә. Тик бу чорда татар теленә уйгур теле һәм Урта Азия төркисенең тәэсире тагын да көчәйгән булырга тиеш. Алтын Урда үзәкләрендә язылган әдәби әсәрләр (Котб, Сәеф Сараи, Мәхмүд бине Гали һ.б.ш.) Урта Идел һәм Чулман регионында күпләп укылганнар, Көньяк Уралга да үтеп кергәннәр.

Бу чорларда тагын бер үзенчәлекле күренеш – гарәп теленнән кергән сүзләрне фарсы сүзләре белән алмаштыру күзәтелгән.

VI-XI гасырларда гамәлдә булган һәм шактый үсеш алган борынгы төрки-уйгурча фәнни һәм иҗтимагый-мәдәни терминология бу чорда онытыла төшкән.



§73. **Татар теле** дигән тәгъбир кыпчак телләренең берсенә карата беренчеләй XIII гасыр ядкәрлеге «Кодекс куманикус»та кулланыла. Әмма татар теле нигездә Болгар дәүләтее чикләрендә X-XI гасырларда ук формалашкан. Мәгълүм ки, *чуваш* сүзе борынгы марича *сүәс* «татар» сүзеннән килә; мордвалар татарны *пичкась* дип, ә удмуртлар *бигер (бугор) вукор* дип атыйлар. Димәк, өч күрше халык татарны өч төрле атый. Өчесе дә бүтән беркайда да ишетелмәгән оригиналь атама. Моннан татар этносы татар исемен алганчы ук яшәгән дигән нәтиҗә чыга.

Борынгы бигәр-сүәҗ (сүәс-пичкась) этносы Биләр//Бүләр шәһәре тирәсендә оешкан булса кирәк (бу турында без бер язган идек инде). Аның теле тик көнбатыш кыпчак телләренең берсе генә була алган һәм лингвистик яктан Алтын Урдадагы татар теленнән бик аз аерылган.

Алтын Урда татар теле ничек килеп чыккан соң?

Мәгълүм ки, Алтын Урда дәүләте оешкан Идел буйларында вә хәзерге Мордовия тирәләрендә тиз арада дистәләрчә шәһәрләр үсеп чыга: Сараи-Бату, Сараи-Бәркә, Бәлҗәмин, Гөлестан, Үвәк, Мукшы, Сарыклыч, Кашан, Казан һ.б. Бу сәүдә – һөнәр үзәкләренең әһалесе үзара бәйланышта торган. Шәһәрләрдә кабиләчелектән аерылган кешеләр – базаркяннар, сәүдәгәрләр, һөнәрчеләр, яшелчәчеләр, гамәлдарлар (чиновниклар) яшәгән.

Чыгышлары җәһәттеннән шәһәр кешеләре бик төрле булган: үз кабиләләреннән аерылган сукбай төркиләр, аламан-голәмәннәр вә әтрәк-әләмнәр ягъни көньяк төркиләрдән чыккан ялланмыш гаскәриләр, хәрәсәннәр-фарсылар, хәчтерүшләр-әрмәннәр (әрмәнчә *хачикруш* «хач йөртүче, христиан»), руслар, финн-угорлар, Көнбатыш Европа кешеләре һ.б. Гарәп-фарсы элементлары белән баектырылган куман теле болар өчен уртак тел булып әверелгән. Әмма язма-әдәби тел буларак уйгур вә «чыгтай» телләре кулланылган. Чөнки Алтын Урда кәнсә вә мәктәп-мәгърифәт урыннарында башлыча уйгурлар һәм Харәзем – Урта Азия әһелләре эшләгәннәр.

Хәзерге татар һәм башкорт телләрендә ачык беленеп торган **уйгур элементлары** бар: *ай, әттәгенәсе* сүзе (уйгурча *әттигинә* «вәт әкият, менә гаҗәп»); *әттәк*<бор. уйгур. *әртәк* > тат. диал. *иртәк* «әкият»), җырларда еш очрый торган *–дыйн//дин, -тыйн//тин* кушымчасы һ.б. Билгеле, XIII гасыр уйгур теле хәзергедән аерылган – безнеңчә ул XIII-XV гасырлар ядкәре «Угызнамә» теленә якын торган, ә бу әдәби әсәрнең теле татар гомумхалык теленә бик якын.

Идел буе шәһәрләре формалашып килгән Алтын Урда этносының арка үзәге булган. Тик, кызганычка каршы, Алтын Урданың төп хәрби көчен тәшкил иткән һәм дәүләт башында торган күчмәнчеләр белән

шәһәр илаты арасында этник бердәмлек яисә, һич югында, килешеп эшләү булмаган. Шәһәрләр тыныч тормыш, иркен сәүдә яклы булса, күчмән аристократия талаучылык, казакъчылык, үлҗә-ганимәт табу белән мавыккан; Алтын Урда идарәчеләре, читтән кулга төшерергә җай чыкмаса, үз рәгыятьләрен колыкка сатудан да тайчынмаганнар. Шәһәрләр уртак тел булдыру ягын карасалар, күчмәнчеләр, кабиләчелек *җергә*сен – иерархиясен саклап, кабилә шивәләрен консервацияләгәннәр (мәсәлән, башкортларның ике зур кабиләсе – бөрҗәннәр һәм кыпчаклар әле XVI гасырда да үзара сугышып-талашып ятканнар). Шәһәрләр кальга-кирмәннәр төзергә омтылса, югары идарәчеләр төзелгән кальгаларны да җимертергә боерганнар. Нәтиҗәдә шәһәрләр – тел вә мәдәният берлеген саклаучылар – һәртөрле юлбасарлар (рус ушкуйниклары, төрки аламаннар) өчен җиңел табыш булганнар. Һәм үзәк хөкүмәтнең зәгыйфьләнүе белән шәһәрләр тар-мар ителгән, аларның илаты кырылган, котылганнары төньякка – Казан дәүләте чикләренә күченгән. Алар телгә әлеге уйгур һәм чыгтай элементларын алып килгәннәр.

Туктамыш хан заманында күченгән *чагатай, чыгтай* этник төркеме атамасыннан хәзерге Чувашиядәге *Четай, Чутай, Чути, Тахтамыш, Туктамыш* дигән авыл исемнәре килә. Алтын Урда этник аңыннан истәлек булып кыпчак телләрендәге *байтак* сүзе калган: ул фарсыча *пайтәхт* «башкала» сүзенең кыпчакча әйтелеше булып, башта «бөтен ил, империя» мәгънәсендә йөргән. Соңрак бу сүз «шактый күп, бик күп» мәгънәсен алган (чагыштырыгыз: гади сөйләмдә *дөнья* «бик күп»).

## СИГЕЗЕНЧЕ БАБ
## ИДЕЛ-ЧУЛМАН ТЕЛЛӘРЕ БЕРГӘЛЕГЕНДӘ ТАТАР ВӘ БАШКОРТ ТЕЛЛӘРЕНЕҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

§74. Татар теле, типик төрки тел булу һәм төрки телләрнең уртасында торудан тыш, Идел-Чулман телләрее бергәлегенә дә керә.

Бу телләр бергәлегенә барлыгы биш тел – башкорт, татар, чуваш, мари (чирмеш) һәм удмурт (ар) телләре карый. Шулардан өчесе төрки телләр, икесе – мари һәм удмурт телләре финн-угор семьялыгына карый.

Ошбу телләр уртак лексик фонд, уртак морфологик һәм фонетик чалымнар илә берләштереләләр.

Лексика дигәндә, барча бу телләрдә, күпсанлы рус алынмаларыннан тыш, 700 дән артык бер үк сүз актив кулланыла. Шуннан башка тагы 3000 чамасы сүз биредәге төрки һәм финн-угор телләре өчен төрле дәрәҗәдә уртак.

Морфология өлкәсендә Идел-Чулман телләренә түбәндәге уртаклыклар хас: а) агглютинатив морфологик төзем; б) грамматик җенес категориясенең юклыгы; в) тартым категориясенең бик көчле үсеш алуы



(тартымлы төрләнеш һ.б.); г) өченче зат тартым кушымчасының билгелелек категориясен формалаштыруы; д) бәйлекләрнең исем азагында килүе (ягъни префикслар юк, постфикслар гына бар); е) күпсанлы бәйлек исемнәре куллану (*ард, арт, баш* һ.б.ш.); ж) фигыль формаларының структур һәм функциональ охшашлыгы (ярдәмче фигыль мәгънәләрен калькалаштырулар һ.б.); з) хәл һәм сыйфат фигыль формаларының Европа телләрендәге иярчен җөмләләр мгънәсендә кулланылуы; и) гомумән, синтаксик төземнең тулысынча охшашлыгы (һәм нәтиҗәдә җөмләләрнең сүзмә-сүз укылуы).

Фонетик охшашлыклар беренче ястануда түбәндәгеләрдән гыйбәрәт: а) сингармонизм, б) накыс (редукцияләнәгән) сузыклар (*ŏ, ы, ĕ*) булу, в) сөйләмдә тартык һәм сузык авазлар нисбәтенең бер үк яисә бик якын булуы, г) аваз чатлашмаларының охшашлыгы (сүз башында ике тартык бергәлегенең кулланылмавы һ.б.ш.), д) аерым телара фонетик охшашлыклар (бәләкәй тел союзлары) системасы (мәсәлән, чуваш, мари һәм удмурт телләрендә *сч* авазы булу, татар, башкорт, чуваш һәм мари телләрендә о, ө авазлары пары һ.б.ш.).

§75. Бүгенге көндә күзәтелгән бу охшашлыклар каян килеп чыккан соң?

Уртак лексиканың барлыкка килүе аеруча мохтаҗ түгел – мәзкүр телләр инде кимендә мең ел дәвамында бер үк дәүләтләрдә һәм бердәй шартларда шактый тыгыз аралашып яшәүчеләрне хезмәтләндерәләр. Билгеле, шундый шартларда теләсә нинди телләр арасында да уртак лексика пәйда булачак.

Уртак грамматика икенче мәсьәлә. Монда Идел-Чулман телләрендә күзәтелгән уртаклык пәйда булсын өчен без хәзер белгән шартлар гына җитми.

Кайбер галимнәр, мәсәлән, Җ.Киекбаев, финн-угор һәм төрки халыкларны борынгыдан, күп мең еллар элек барлыкка килгән кардәшлеге, шул кардәшлекнең Идел-Чулман телләре берегенең тәшкилләнүенә сәбәп булуы турында сөйлиләр һәм югарыда күрсәтелгән Урал-Алтай телләре семьялыгын аерып күрсәтәләр[52]. Урал-Алтай семьялыгы мәсьәләсе безнең тармага карамый, ләкин финн-угор һ»м төрки телләрнең әзәлдән килгән системалы һәм структур охшашлыгы, һичшиксез, Идел-Чулман телләр берегенең пәйда булуында үз ролен уйнаган. Ләкин ул охшашлыклар хәлиткеч сәбәп булмаган. Бу шуннан да күренә: соңгы гасырларда төрки халыклар, бигрәк тә татарлар белән тыгыз бәйланышта яшәгән мордваларның телләре, шул ук финн-угор семьялыгына керүләренә карамастан, Идел-Чулман берегенә карамыйлар, чөнки мордва (ирҗә һәм мукшы) телләре Идел-Чулман берегендәге телләргә грамматик яктан охшашмаганнар. Моннан шундый нәтиҗә чыга: Идел-

[52] Дж.Г.Киекбаев. Введение в Урало-алтайское языкознание. Уфа, 1972.

Чулман берлегендәге кебек телләр охшашлыгы барлыкка килсен өчен телләрнең әзәлдән килгән типологик бердәйлеге дә, мең ел гына янәшә яшәве дә җитми әле. Телләр берегә, аның тәшкилләнүе өчен уңай шартлар булганда да кимендә мең ярым-ике мең еллык янәшәлек вә контакт нәтиҗәсе буларак кына килеп чыга ала. Монда, күрәсең, әлеге контактларның билгеле бер иҗтимагый-этник шартларда бар булуы, конкрет алганда, әйтик, татар-чуваш, чуваш-мари, татар-удмурт һ.б.ш. икетеллек таралган төбәкләр булу, милләтара никахларның җитәрлек дәрәҗәдәге ешлыгы һ.б. зур роль уйнаган. Бик ихтимал ки, борынгы гасырларда финн-угорларның зур төркемнәре төркемләнү (башкортлашу, татарлашу, болгарлашу) белән беррәттән төркиләрнең зур төркемнәре дә удмуртлашкан яисә марилашкандыр.

§76. Югарыда санап күрсәтелгән охшашлыклар белән бергә Идел-Чулман телләре арасында зур аермалыклар да яшәп килә.

Башкорт һәм татар телләрендә сөйләшеп бер-берсен аңлый алалар (һәрхәлдә, моның өчен уртача зирәклек җитә). Әмма чувашны һәм җирле финн-угор телләрендә сөйләшүчеләрне татар да, башкорт та, бүтән төркиләр дә аңламыйлар. Шулай ук мари белән удмуртлар да бер-берсен аңлаудан ерак торалар.

Без биредә җирле финн-угор телләренең җирле телләрдән аермаларына туктала алмыйбыз. Бары тик чуваш, татар һәм башкорт телләренең бүгенге (синхроник) һәм генеологик (диахроник) фонетик аермалыкларын карап үтик.

§77. **Башкорт һәм татар телләре.** Башкорт һәм татар телләренең лексикасы 89-96% ка уртак. Морфологик уртаклыклар да шуннан ким түгел. Шунда әхвәлдә болар арасындагы аермалар бер телнең сөйләшләре арасындагы аермалардан зуррак түгел. Ләкин ошбу телләр арасында регуляр булса да тирән синхроник вә диахроник фонетик аермалыклар яшәп килә. Татар һәм башкорт телләре арасындагы бүгенге көндәге фонетик аермалыкларны түбәндәге бүленештә карап чыгу уңайлы:

а) фонематик авазлар составындагы аермалыклар;

б) фонематик авазларны кулланудагы аермалыклар;

в) аваз чатлашмаларындагы аермалыклар.

Чөнки бүтән типтагы аермалыклар юк.

**Аваз составындагы аермалыклар**, югарыда инде әйткәнебезчә, түбәндәгеләргә кайтып кала: башкорт телендә *җ-ч* пары кулланылмый, татар телендә исә *ҙ -ҫ* авазлары юк (кайбер сөйләшләрдәге *ҙ* =δ исәпкә алынмый). Шулай итеп, фонематик авазлар саны татар һәм башкорт телләрендә үзара тигез булып чыга кебек.

**Фонематик авазларны кулланудагы аермалар** түбәндәгечә тәгърифләнә ала: башкорт телендә *җ-ч* пары булмаганлыктан, татарчадагы *җ* һәм *ч* авазлары башкортча тоталь рәвештә һәм позициясенә карамыйча *з-с* авазлары белән алмаштырыла; ә татар телендә *ҙ -ҫ* пары булмаганлыктан бу авазлар тоталь рәвештә, әмма позициясенә карап төрлечә бүтән авазлар белән алмаштырыла. Болардан тыш, һәр ике телдә булынган, әмма кулланышларында позицион аермалар күзәтелгән авазлар да бар (*б-п, з-с, й, җ, һ*). Ул аермаларны түбәндәгечә күрсәтик:






Башкортчада, бигрәк тә сүз башында, «эшалонлы» *ч>с//с>һ* күчеше күзәтелә.

Бу «классик» тәңгәллекләр кайбер искәрмә аңлатуларга мохтаҗ. Беренчедән, башкорт телендә гомумән чиста з булмаган – бу аваз хәзерге әдәби-язма телдә гарәп, фарсы һәм рус алынмаларында оригинальдәге әйтелешен бозмас өчен язма телдә генә кулланыла башлаган. Төрки һәм күптән сөйләм теленә кергән гарәп-фарсы сүзләрендә төп чыганактагы *д* һәм *з* урынына *ҙ* кулланыла (мәсәлән, *майҙан*< фарсы *майдан, вәғәҙә*< гарәп. *уәғъдә* һ.б.).

Икенчедән, татар телендәге *су* урынына башкорт телендә һәрвакыт *ҫ* яки *һ* килми: баягыча, гарәп, фарсы һәм рус сүзләрендәге *с* язма телдә күбесенчә үзгәрешсез калдырылып, тик гомумхалык телендә күптән кулланылып килгән алынма сүзләрдә генә *с>ҫ, с>һ* күзәтелә, мәсәлән, русча *самовар>* татарча *самаwыр* ~ башкортча *һамауыр;* фарсыча *дуст*, башкортча *дуҫ;* фарсыча *дастгир* «(ярдәм) кулын сузычы» > башкортча *тиҫтер* «дус, кардәш, иптәш» һ.б.ш. Өченчедән, рус алынмаларында язма телдә *ч* авазы да кулланылышка кертелә: *(хәрби) часть, училище, автоматчик* һ.б.

Ләкин башкортча *сут* < татарча *чут* < рус. *счёт*; башкортча *сирек* < татарча *чирек* < фарсы *чаруйә* «дүрттән бер» һ.б.

**Аваз чатлашмаларындагы (комбинацион) аермалар** шактый күп төрле һәм катлаулы.

Беренчедән, бичы параграфтагы схемаларда күрсәтелгән сингармоник чылбырлар башкорт телендә чигентесез бозылмый сакланган диярга ярый. Схемаларга муафыйк рәвештә башкорт телендә төрки *у* һәм *ү* авазлары икенче, өченче иҗекләрдә киләлми һәм татарча *бару, китерү* сүзләренә башкортча *баруы, килтереү* тәңгәл килә. Шуның өстенә башкорт телендә иренләшү гармониясе бик көчле.

Икенчедән, башкорт теле, икенче бабта күрсәтелгәнчә, үзләрендә ассимиляция-диссимиляция көчле үсеш алган телләр җөмләсенә карый. Бу ассимиляция-диссимиляция күренешләре башлыча кушымчалар исәбенә, аларның вариантларын күбәйтү юнәлешендә бара. Ассимиляцион-диссимиляцион вариантларга тагы иренләшү гармониясе буенча вариантлашу өстәлә[53]. Нәтиҗәдә кайбер төрләндергеч (мәсәлән, иялек һәм төшем килеш) кушымча вариантлары башкорт телендә уналтыга җитә.

| Татарча | Башкортча |
|---|---|
| *1) һawалар, күбәләр* | *1) һawалар, күбәләр* |
| *сулар, серләр* | *һыуҙар, серҙәр* |
| *саннар, көннәр* | *һандар, көндәр* |
| *атлар, эшләр* | *аттар, эштәр* |
| күплек кушымчасы дүрт вариантта | күплек кушымчасы сигез вариантта |
| *2) җаваны, күбәне* | *һауаны, күбәне* |
| *корыны, берене* | *короно, бөрөнө* |
| *суны, серне* | *һыуҙы, серҙе* |
| *корымны*[54]*, өметеңне* | *коромдо, өмөтөңдө* |
| *санны, җимне* | *һанды, емде* |
| *комны, көлне* | *комдо, көлдө* |
| *атны, эшне* | *атты, эште* |
| *толыпны, сөтне* | *толопто, һөттө* |
| төшем килеш кушымчасы ике вариантта | төшем килеш кушымчасы уналты вариантта[55] |

[53] Башкорт сөйләшләренең кайберләрендә ясагыч кушымчаларда да ассимиляция-диссимиляция күренеше күзәтелә, мәсәлән, *башла-мак >башта-мак, башлы > башты, бикла-мәк > биктә-мәк, көслө > көстө* һ.б., ләкин бу хәл кирәкмәгән омонизациягә китергәнлектән, әдәби телгә кертелми.

[54] *Корымны* сүзе ике төрле аңлашылырга мөмкин: *кор* (яшьтәшләр түгәрәге) сүзеннән беренче зат тартымлы төшем килем кормасы һәм *корым* сүзенең тартымсыыз төшем килеш формасы. Фонетик закончалыклар өчен боларның аермасы юк.

[55] К.Ахтямов М.Х. Структура слова в современном башкирском языкее. Уфа, 1996, С.15-35.



Татар телендә исә *-м, -н, -ң* авазларына беткән нигезләр генә һәм кайбер кушымчаларның гына (мәсәлән, күплек кушымчасыны) башкы (анлаут) тартыгын ассимиляциялиләр. Диссимиляция күренеше исә җанлы закончалык буларак күзәтелми: ул тик этимологиясе онытылган нигезләрдә генә ачыла, мәсәлән, *гөрелдәмәк < гөреллә-мәк, шаwылдамак < шаwылла-мак, уылдык < уыллык << оғуллуқ* (борынгы *оғул* «токым, бала» > татарча *уыл* «балкортның ашый башлаган күрчагы» һ.б.

Гомумләштереп әйткәндә, башкорт телендә тәмамланышларына күрә нигезләр дүрт төрле була: а) сузык авазларга беткән нигезләр: бер төркем төрләндергеч кушымчалар боларга кушылганда *-л, -н,* авазларына башланган вариантларда киләләр; б) сонор *й, w, p* һәм (сонор булмаган) *з* авазларына беткән нигезләр: бер төркем төрләндергеч кушымчалар боларга ялганганда *-ҙ* авазына башланган варинтта килә; в) сонор *–л, -м, -н* авазларына беткән нигезләр: бер төркем төрләндергеч кушымчалар боларга ялганганда *–т* авазына башланган вариантта килә.

**Бер төркем** дигәнебез ул нинди группа соң? Җентекләбрәк карасак, шуны күрәбез: болар төптә – гомумтөрки планда йә сонор, йә денталь тартык авазларга башланган кушымчалар икән. Күрсәтелгән кагыйдәләр сонор да, денталь дә булмаган *-ғ//г, -қ//-к, -с(<-ч), -h(<-с)* авазларына башланган кушымчаларга кагылмый – аларның вариантлашуы татарчадагы кебек, мәсәлән:

| **татарча** | **башкортча** |
|---|---|
| *ауга* | *ауға* |
| *җәйгә* | *йәйгә* |
| *кышка* | *кышка* |
| *төнгә* | *төнгә* |
| *бирсе* | *бирһе* |
| *ташсын* | *ташһын* |
| *башкортча* | *башкортса* |
| *уйчан* | *уйсан* |
| *эшче* | *эшсе* |
| *ячыл* | *ясыл* һ.б. |

Ягъни, боларда инде тоталь күчешләр генә чагылыш табып, позицион аваз күчешләре чагылыш тапмый.

Өченчедән, башкорт әдәби телендәге кайбер кушымчалар татар әдәби телендә булганнардан озынрак вариантта киләләр.

| татар әдәби норма | татар диалекталь вариант | башкорт әдәби норма |
|---|---|---|
| *1. –ыйм//им: барыйм, килим*<br>*-ыйк//ик: барыйк, килик*<br>*2. –сыз, -сез: барасыз, киләсез* | *-айым//әйем: бараем, киләем*<br>*-айык//әйек: бараек, киләек*<br>*-сыҙ ыз//сегез: барасыгыз, киләсегез* | *-айым//әйем: барайым, киләйем*<br>*-айык//әйек: барайык, киләйек*<br>*-һыҙ ыз//һегез: бараһыгыз, киләһегез*<br>һ.б. |

§78. Китерелгән аермаларны диахроник күзлектән карап чыгып, түбәндәгеләрне әйтеп була.

Авазлар составында *җ-ч* парының башкорт телендәге юклыгы, һичшиксез, икенчел күренеш. Борынгы төрки телләрдә хәзерге яңгырашындагы *җ(ʐ)* булмаса да, аның тәү прообразы булган *ч* – һәрвакыт очрый. Татар телендәге *җ* – өлешчә борынгы төрки диалектлардан, өлешчә гарәп-фарсы алынмаларда килә (һәр очракта ул башкортчада яңа *й* һәм *ж* белән алмаштырыла). Башкортча *ҙ* һәм *ҫ* авазлары бик борынгыдан калган булуы ихтимал (алар төрекмән телендә дә бар). Әмма *ҙ* авазының хәзергечә кулланылышы, бигрәк тә гомумтөрки *-д-* һәм *-л-* урынында килүе (к. түбәндәрәк) – яңалык, инновация. Аннары, хәзерге башкорт телендә *ҙ* һәм *ҫ* авазлары гарәпчәдән алынган сүзләрдә дә очравы (бу авазлар гарәп телендә дә бар), әлбәттә, борынгы төркилектән килми.

Башкортчада һәм казахчада гомумтөрки *җ* урынына килә торган *ж* авазы да инновация булса кирәк. Чөнки бүтән төрки телләрдә бу авазның кулланылганлыгы беленелми.

**Авазларны кулланудагы аермаларга** килгәндә, башкорт телендә *т*-, татар телендә *д*- булганда төрки сүзләрдә башкорт варианты борынгырак, әмма алынма сүзләрдә татар теле оригиналь яңгырашны ешрак саклый. Башкортча *ҙ* һәм *ҫ* авазлары да төрки тамырлар составында бик борынгыдан килеп, алар урынындагы татарча (һәм гомумтүрки) *з* һәм *с* инновация булса кирәк. Кайбер алынма сүзләрдә татарча *з* һәм *с* оригинальдәге *з* һәм *с* авазларына туры килә (башкортча *ҙ* һәм *ҫ* ул очракларда туры килмәскә мөмкин), әмма икенче кайбер алынмаларда башкортча *ҙ* һәм *ҫ* оригинальдәге авазга тулысынча туры килеп, татарчадагы *з* һәм *с* бары тик субституция генә була (мәсәлән, башкортча *каҙ ый*~ гарәпчә *каҙый* > татарча *казый* һ.б.).

Башкорт телендәге *ч>с//с>һ* эшалонлы күчеше, әлбәттә, инновация. Татарча *ч* һәм *с* борынгы төрки телдәгечә кулланыла һәм саклана, ә алар урынындагы башкорт *с* һәм *һ* авазлары – яңалык. *Һ* авазы татар телендә һәм барлык башкортчадан тышкы төрки телләрдә гомумән, бары тик гарәп-фарсы алынмаларында гына очрый.



*Ч>с//с>һ* тоталь эшалонлы күчеше (еш кына башкорт телендә дә булынган сүзләрдә) монгол теленә якын бурят телендә дә күзәтелә, ягъни борынгы монгол телендәге *ч* бурят телендә *с* авазы белән, ә иске монгол *с* авазы *һ* белән тоталь рәвештә алмаштырыла. Шуннан инде башкорт һәм бурят телләре уртак субстратка ия булмады микән, яисә башкорт халкының үзәген төркиләшкән бурятлар тәшкил итмәде микән дигән фикер туа. Бу мәсьәлә аерым тикшеренүне сорый.

Татарча *м-* һәм *п-* урынындагы башкортча *б* (*монда~бонда, бында, пычак ~ бысак*) борынгырак вариант булса кирәк.Ләкин шуны әйтергә кирәк, *м~б* һәм *п~б* тәңгәллекләре бик аз санлы сүзләрдә күзәтелә.

Аваз чатлашмаларындагы аермалыкларга килгәндә, чагыштырма-тарихи планда югарыда күрсәтелгән үзенчәлекләрен болай дип гомумиләштереп тәгъбирләп була: башкорт телендә *–л* һәм *–н* авазларына башланган борынгы аффикслар *-ҙ*, -з авазларына һәм сонор вә саңгырау тартыкларга беткән нигезләргә ялганганда диссимиляция күренеше пәйда була ягъни шул *-л* һәм *-н* авазлары денталь тартыклар илә алмаштырыла, ә денталь авазларга башланган борынгы аффикслар исә, киресенчә, әлеге позициядә башкы тартыкларын сонор авазга алмаштыралар. Бер яктан: *суылар>һыуҙ ар, кызны>кыҙ ҙ ы, сөтне>һөттө* һ.б., икенче яктан: *башлады>башланы, һawада>һawала, һawадна>һawанан* һ.б. Шулай итеп, башкорт телендә гаҗәп күренеш – кушымча вариантларының денталь – сонор полюслары буенча полярлашу күзәтелә. Бу күренештә әйтергә авыр булган сонор-сонор чатлашуыннан качу һәм физиологик яктан җиңел әйтелешле *-нд-, -нт-* һәм *-ст-* чатлашмаларын[56] күбәйтү тенденциясен күрергә мөмкин. Әмма, гомумән алганда, башкорт телендәге аваз чатлашуларының күрсәтелгән морфологик үзенчәлекләре ике тарафтан – эчке структур камилләшү процессы булу җәһәтеннән һәм тарихи җәһәттән (күзәтелгән үзгәрешләргә этәргеч вә мөмкинлек биргән этнолингвистик вакыйгаларны билгеләп) аңлатылырга тиеш. Кайбер галимнәр ошбу мәсьәләләр белән кызыксынсалар да[57], башкорт теленең фонетик вә морфологик үзенчәлекләрен канәгатьләндерерлек аңлату хәзергәчә юк әле.

Шунсы кызык ки, башкорт теленең морфологик группаларында *-з, -ҙ* авазлары сонор тартыклар (бигрәк тә *-р*) белән рәттән, группадаш булып килә. Бу хәл *-з* һәм *-ҙ* авазларының *-р*-дан килеп чыгуына дәлил, гүаһ булса кирәк (к. §55).

[56] К. В.В.Шеворошкин. Звуковые цепи в языках народов мира. М., 1969, С. 117-118.
[57] К. Б.А.Серебренников. О причинах превращения начального *s* в *h* в башкирском языке//Советская тюркология, №3, 1973. Ул ук: О двух случаях загадочного изменения башкирского языка и его диалектов//Башкирский диалектологический сборник. Уфа, 1959, С. 137-139.

Башкорт телендә һәм кайбер татар сөйләшләрендә кайбер кушымчаларның татар әдәби телендәгеннән озынрак вариантта килүенә тукталып, шуны әйтергә кирәк: «озынрак» вариантлар, һичшиксез, беренчел; татар фонетикасы кебек, грамматикасы да көтек (кыскару законы гомумлингвистик канун). Бу хакыйкать «озынрак» булган вариантларның системалы булуында да күренә:

| | **татарча** | **татарча диалекталь:** | **башкортча**: |
|---|---|---|---|
| берлек: | *башлагансың* | *башлагансың* | *башлаганһың* |
| күплек: | *башлагансыз* | *башлагансыгыз,* < *башлагансыңыз* | *башлаганһыгыз,* < *башлаганһыңыз* |

Ягъни, «озын» вариантлардан *-сыз<сыҕ ыз<сыңыз~ һыҕ ыз<һыңыз* кушымчасы 2 – зат берлек кушымчасы *сың*га (башкортча *һың*га) күплек күрсәткече *–ыз (<*-ырг)* ялганып ясалганлыгы ачык күренә. Чувашча да шул ук нәрсә күзгә ташлана: *пултăн* «булдың» – *пултăнăр* «булдыгыз» һ.б. Шулай итеп, бу очракта татар телендә элекке система бозыла төшкән, тел мантыйксызланган.

## ТУГЫЗЫНЧЫ БАБ
## ТАТАР ҺӘМ БАШКОРТ ӘДӘБИ ТЕЛ ФОНЕТИК НОРМАЛАРЫНЫҢ ФОРМАЛАШУЫ

§79. Татар әдәби теле кебек башкорт теле дә бик төрле диалект һәм сөйләшләрдә сөйләшүче ил-көнне (илатны) хезмәтләндерә. Өстәвенә Урал-Идел регионында төрки язма телләр алмашынып торган. Шуңа күрә әдәби телләрнең, алырның грамматик, бигрәк тә фонетик нормаларның карарлашуы шактый озын тарихка ия.

Урта Иделдә төркет тибындагы төрки телдә сөйләшкән халык кимендә мең ел дәвамында язу-сызуны яхшы белгән, сәләтле булган, әмма аның үз халыкчан әдәби теле барлыкка килгәнче озак гасырлар узган.

Бу хәлнең тирән сәбәпләре бар.

Урта Идел, бигрәк тә хәзерге Татарстан территориясе борын-борыннан төрле яктан юллар тоташкан җир. Бу төштә һәр тарафтан – төньякта нһәм көньяктан, көнчыгыштан һәм көнбатыштан күп сулы, көймәйөзәр елгалар бергә килеп кушыла. Ә бит борынгы заманнарда, әйтик, безнең эраның беренче меңьеллыгында су юллары урман һәм урман-дала зонасында берләнбер ышанычлы, үткеле аралашу юллары булганнар. Өстәвенә дала һәм чүлләр аша үткән кыраз (коры җир) юллары да (Болгар-Урта Азия һәм Болгар-Төньяк Кавказ, Болгар-Киев) бу төштә тоташкан.

Ошбу әхвәл Урта Идел өлкәсен, Һәртөрле тышкы тәэсирләр учарытөене вә учагы иткән. Урта Иделнең үзендә, нишләптер, бигүк зур империя үзәге оешмаган, әмма Иделнең түбәндәге агымнарында, Урта



Азиядә яисә Үзәк Азия далаларында тәшкилләнгән көчле империяләр Урта Идел регионын үз тәэсирләрендә тотарга тырышканнар. Ул империяләрнең төп хуҗалары бирегә үз мәдәниятләрен, үз телләрен, хәтта үз кешеләрен урнаштырырга омтылганнар.

Төньяк Кавказдан Печора буйларына чаклы бердәй яисә калькалаштырылган (биш көнлек атнадагы) көн исемнәре, Әләнгәсәр (Алан-Хазар) сүзе, хуҗалар (аеруча изге затлар) һәм аларның каберләре-кирәмәтләр культы таралган. Бу хазар империясеннән һәм тәүге чорындагы Болгар дәүләтеннән калган мирас.

X гасырда Урта Азия һәм Иран территориясендә гаять көчле угыз империяләре – башта Газнәвиләр, аннары Сәлҗүкый дәүләтләре оеша. Угыз чирүләре көнбатыш көнбатышка узып киткәч, XI гасырда Карахани дәүләте зур куәткә ирешә. Бу чорларда төрки халыкларның хәрби куәте генә түгел, рухи үсеше дә күтәрелеш кичерә. Угызлар һәм болгарлар төркиләрдән беренчеләр булып мөселманлыкка күчәләр. Шул дәвердә гарәп язуындагы төрки әдәби тел мәсьәләсе килеп туа[58].

Мәхмүт Кашгари һәм аның чордашы (ихтимал ки, танышы) Йосыф Баласагуни бу мәсьәләне үзләренчә хәл итәргә тырышканнар. Ләкин тарих алар теләгән юлдан китмәгән. Бөтен мөселман төркиләренең мәдәни-әдәби теле булып Й.Баласагунинең «Кудатгу Билик» теле түгел, аңардан йөз елга соңрак яшәгән Әхмәт Яссави һәм аңа чордаш әдипләр аңлы рәвештә угыз, уйгур-карлук һәм кыпчак телләре элементларыннан оешкан ясалма телдә язганнар.

Гомумән, бу уртак тел идеясе егерменче гасыр башларына кадәр төрки зыялылар аңында үз тәэсирен югалтмаган. Һәм Урта Иделдә мөселманлык кергәннән башлап шундый телләр – башта, ихтимал, Карахани әдәби теле, аннары борынгы угыз язма һәм Әхмәт Яссәви теле официаль әдәби тел булып хисапланган. «Кыйссаи-Йосыф» һәм Ә.Яссәви хикмәтләре телендә мәктәп-мәдрәсәләрдә укыганнар, шул телдә хат һәм шигырьләр, рәсми документлар, бәетләр һәм рисаләләр язганнар.

Бу телне элегрәк чыгтай теле (русча *чагатайский, джагатайский язык*) теле дип атыйлар иде. Бу атамада шундый тарихи вәзгыять чагыла: әлеге тел Чыңгыз угълы Чыгатай биләмәсе булган Урта Азия һәм Иран өлкәсендә халык массалары теленә якын һәм киң кулланылган рәсми тел була; Чыгатай биләмәсеннән Алтын Урдага килүчеләр шул телдә яза һәм сөйләшә. Ләкин бит бу хәл әдәби тел тарихыннан бер эпизод кына. Ул тел монгол яуларыннан бер гасыр элек үк Урта Азиядә генә түгел, бөтен Дәшти-Кыпчак һәм Идел-Урал регионында да билгеле

---

[58] F.Sumer. Oguzlar. Istanbul, 1992. 59-60 б.

мәдәни тел булган. Һәм аны (аның кайбер вариантлары татар халык теленә Әхмәт Яссәвинең үз теленнән ераграк булса да) Яссәви теле дип атау дөресрәк булыр кебек.

Татар халкы кавем буларак оешкан чордан ук утрак халык. Татар халкында күчмәчелек чорындагы матди культура да, рухи-мәдәни культура да булалмаган. Конкрет алганда, татар халкы кабилә-ыруг иерархиясен һәм шуның белән бәйле кабилә-ыруг эпик традицияләрен, тирмәләргә җыелып чичән-озаннардан борынгы батырлар турында озын-озын героик дастаннар тыңлап утыруны бигүк өнәмәгән. Телдәнге дастаннар урынын китап тыңлау, хафиз-абызларның укуын тыңлау алган. Ә китаплар исә Яссәви телендә язылган.

Тыңлаучылар һәм абызлар булган, язучылар да булган. Әмма алар да әлеге традицион китап телендә язганнар. Һәм иң кызыгы шул ки, Урта Идел, Болгар һәм Дәшти кыпчак сәвәтләре китаплардагы гарәп-фарсы сүзләре ничек язылса, шулай укыганнар. Аларның укуы теле дөньяда аңарчы беркайда да булмаган **өр яңа бер тел** булып килеп чыккан.

§80. Һәрбер озын тарихлы язу системасы шикелле гарәпчә язу искедән калган шартлылыкларга ия. Шундый шартлылыкларның берсе – гарәп телендә инде күп гасырлардан бирле укылмый торган ع (гайн) хәрефе: ул татар теленә дә кергән *гаилә, галим, гает* һ.б. шундый сүзләр башында укыла, ә гарәпләр белән турыдан-туры аралашкан төркиләр ع хәрефен язмада гына сүздән сүзне аеру өчен кулланып, телдән укымыйлар һәм әлеге мисалларны *аилә, алим, аид* дип укыйлар.

Гарәп телендә сузыклар аз һәм алар язуда еш кына хәрәкәләр – хәреф өстендәге яки астындагы сызыкча, өтерләр белән генә билгеләнәләр. Гарәп хәрефләре белән язган төркиләр дә, үзләренең телләрендә кимендә сигез сузык аваз булуга карамастан, сузык авазларның гарәпчә билгеләнеше белән генә канәгатьләнеп килгәннәр. Төрки сингармонизм тартык авазларны билгеләгән (*қ* һәм *к*, *ғ* һәм *г*, нечкә *т* һәм калын *т*-ны һ.б.) хәрефләр белән өлешчә тәгъбирләнгән. Гарәп әлифбасы бигрәк тә ирен сузыкларын билгеләүдә ярдәм итми: бер үк و хәрефе контекстына теленә карап *у, ү, о, ö* һәм *ŏ, ө* авазларын билгеләргә мөмкин. Шулай ук, бер ی хәрефе дә ый, и, й һәм е авазларына уртак билге. Билгеле, бу система әйтелеш һәм тел нечкәлекләрен төгәл билгеләрә алмый.

Ләкин бу язуның төркиләр өчен үз уңайлыклары да булган. Төрки диалектлар еш кына сузык аваз системалары җәһәтеннән генә аерылалар. Ләкин ул аермалыклар иске язуда билгеләнми. Шуңа күрә бер язма текстны һәр төрки халык үз вокализмы белән, үзе теләгәнчә укый алган.



Өстәвенә, иске «төрке» язуда кушымчалар унификацияләнгән язылышта биреләләр ягъни, мәсәлән, иялек килеш кушымчасы, аның нинди нигездә (алгы рәтме, арткы рәтме икәнлегенә) карамастан, һәрвакыт бер төрле ڭ рәвешендә, чыгыш килеш кушымчасының дүрт варианты да бер دان язылышында һ.б.ш. язылалар.

Билгеле, мондый язуны иркен уку өчен шактый күнекмәләр кирәк. Чөнки, асылда, уку процессында укучыдан текстның үзенчә, аерым вариантын иҗат итү таләп ителә.

Урта Идел һәм Алтын Урда сәвәтләре гарәпчә язулы төрки телле китапларны барлык гарәп тартыкларын, шул хисаптан югарыда әйтелгән ع ны да төгәл итеп, җиренә җиткереп (изге язу бит!) укыганнар. Әмма сузыклар һәркемнең үз телендәгечә укыган. Нәтиҗәдә гарәп язма сүзләренең, хәтта Коръәннең дә, оригиналь татарча укылышы барлыкка килгән. Бу укылышта татарның *о* һәм *ө* авазлары киң кулланыла, ع һәм غ һәрвакыт *ғ* итеп укыла.

§81. Безнең карашыбызча, Урта Иделгә мөселманлык кергән дәвердә һәм беркадәр шуның белән бәйле рәвештә Болгар дәүләте чикләрендә, аның иң зур шәһәре Биләрдә вә аның әтрафында[59] татар халкы оеша башлаган һәм үзенең төп чалымнары (борынгы төрки һәм көнбатыш кыпчак консонантизмы, җирле Урта Идел вокализмы) белән татар теле барлыкка килгән. Татар теле баштан ук язма телгә ия булган дип әйтеп була, чөнки IX-X гасырларда ук Урта Идел төрки руник алфавит яхшы билгеле булган: орчыкбашларга, ашык сөякләренә язылган руник язулар төркет телендә һәм алар иң гадәти көнкүреш хадисәләрен чагылдыралар. Димәк, бу язуны киң катлам гади кешеләр белгән.

XII гасырда формалашкан Ә.Яссәви теле (к. §36) шундук Урта Иделгә ирешкән дип уйларга бөтен нигезләр бар. Биредә IX гасырдан бирле руник хәрефләр һәм гарәп хәрефләре параллель рәвештә кулланылганнар. Ләкин бөтен халыкны исламлаштыру, мөселман дөньясының куәте вә авторитеты, ниһаять Яссәви теленең бай мәдәни тел булуы гарәп хәрефенең җиңүенә китергән.

Һәм шундук кара халык теле белән китап теле, Яссәви теле арасында тәэсирләшү процессы башланган. Татар теле үзе китап теле һәм җирле кыпчак теле кушылу нәтиҗәсендә формалашып җиткән дисәк тә күп ялгышмабыз. Чөнк икитап теленнән, Яссәви теленнән кергән сүзләр, тәгъбирләр, фразеосхемалар, идиомалар татар теленең

[59] К. Р.Әхмәтҗанов. Биләр (Буләр топонимы һәм татар халкының оешуы турында)//«Мирас», 1992, №7, 64-67 битләр.

структур челтәрен тәшкил итәләр, шуларсыз татар телен күз алдына китерү дә кыен. Әлеге гарәпләрдә, Иранда, Урта Азиядә, Төркиядә һ.б. укылмый торган, әмма татар-башкортлар (шулай ук, өлешчә казахлар һәм кумыклар) бик ачык укый торган غ, ع-лы сүзләр: *гаҗиз, гадел, гадәт, гашүрә, галәм, галим, Гаишә* (исеме), *гыйбадәт, гыйбарәт, Габбас* (исеме), *Габдулла* (исеме), *гыйбрәт, Госман, Гомәр, Гали* (исемнәре), *гаҗәп, газап, гарәп, гореф, гыйззәт, гаскәр, гыйшык, гыйфрит, гакрәп* (зодиак йолдызлыгы – чаян), *галәмәт, гыйлләт, голәмә, гыйлем, гомер, гамәл, ганбәр, ганка, гуҗ, гаурәт, гаһет, гает, Гайсә* (исеме), *мөгамәлә, мөгаен, мәгариф, мәгърифәт, мөгаллим, мәганә, мәгънә, тәгъбир, тәгаен* һ.б. күп сүзләр татар теленең әзәлдән бирле китап теле тәэсирендә үсеш алуына дәлил.

Шундый дәлилләрдән тагын төптә гарәп теленнән килгән күп кенә ярдәмче сүзләрнең, мәсәлән, *әле, әллә, фәлән, ахры, гел* һ.б. татар сөйләм теленең грамматик стихиясенә үтеп кергән булуын күрсәтергә кирәк. Шундый сүзләрнең кайберләре (мәсәлән, *гел* << *гөлле* < гарәпчә *күлли*) угыз телләре аша узган булса кирәк. Моннан татар халкы составына угызлар да кергән булган дип нәтиҗә ясарга мөмкин.

§82. Китап теле белән тәэсирләшү нәтиҗәсендә гомумтатар теле һәм, бигрәк тә, әдәби тел, берничә яңа фонематик авазга ия булган. Ул авазлар *ф, х, һ*. Шунысы кызык ки, *ф* һәм *х* авазлары татар телендә инде гарәп-фарсы сүзләрендә генә түгел, *туфрак, яфрак, яхшы* кебек төп төрки сүзләрнең аваз составында да күренгәлиләр. Бу хәл дә, һичшиксез, Ә.Яссави телендәге китапларны мәдрәсәләрдә һәм халыкка уку, халыкка «изгеләр телен» пропагандалау нәтиҗәсендә килеп чыккан.



## ТАТАР ҺӘМ БАШКОРТ ТЕЛЛӘРЕНЕҢ ТАРИХИ ФОНЕТИКАСЫ БУЕНЧА МОТЛАК ӘДӘБИЯТ


Ахатов Г.Х. Татарская диалектология. Уфа, 1977.

Ахметьянов Р.Г. Общая лексика материальной культуры народов Среднего Поволжья. М, 1981.

Башкорт әҙәби теленең тарихе. Өфө, 1993.

Дмитриев Н.К. Строй тюркских языков. М., 1962.

Дмитриева Л.В. Язык барабинских татар. Л., 1981.

Древнетюркский словарь. Л., 1969.

Исанбаев Н.И. Марийско-тюркские языковые контакты. Йошкар-Ола, 1989.

Кейекбаев Ж.Г. Башкорт теленең фонетикаһы. Өфө, 1958.

Хәзерге башкорт теленең лексикаһы һәм фразеологияһы. Өфө, 1960.

Киекбаев Дж.Г. Введение в Урало-алтайское языкознание. Уфа, 1972.

Максютова Н.Х. Восточный диалект башкирского языка. М., 1976.

Махмутова Л.Т. Опыт исследования тюркских диалектов. М., 1978.

Миржанов С.Ф. Южный диалект башкирского языка. М., 1979.

Очерки истории башкирского литературного языка. М., 1989.

Пауль Г. Принципы истории языка. М., 1960.

Серебренников Б.А. О принципах превращения начального *s* в *h* в башкирском языке//СТ, 1973, №2.

Серебренников Б.А. Вероятностные обоснования в компаративистике. М., 1974.

Хаков В.Х. Татар әдәби теленең тарихы. К., 1993.

Шайхулов А.Г. Историческая и диалектная лексика тюркоязычных народов волгокамского-уральского региона. Уфа, 1988.

Щербак А.М. Сравнительная фонетика тюркских языков. Л., 1970.

Җәләй Л. Татар теленең тарихи фонетика буенча материаллар. Казан, 1954.

*Учебное пособие*

**АХМЕТЬЯНОВ Рифкат Газизянович**

**СРАВНИТЕЛЬНО-ИСТОРИЧЕСКАЯ ФОНЕТИКА**
**ТАТАРСКОГО И БАШКИРСКОГО ЯЗЫКОВ**

**(на татарском языке)**


Ответственный редактор *Юнусов И.Ш.*

Компьютерный набор *Файзуллина С.Р.*

Корректор *Максютова Г.Ф.*

Компьютерная верстка и оригинал-макет *А.Р. Набиуллин*

Лицензия на полиграфическую деятельность 002037 от 08 ноября 2001 года,
выданная Поволжским межрегиональным территориальным управлением
Министерства Российской Федерации по делам печати,
телерадиовещания и средств массовых коммуникаций

Подписано в печать 25.05.2003 г.
Гарнитура «Times». Печать на ризографе с оригинала.
Формат 60x84$^1/_{16}$. Усл.-печ.л. 6,50. Уч.-изд.л. 5,68.
Бумага писчая. Тираж 300 экз. Заказ № 151.
Цена договорная.

452450, Республика Башкортостан, г. Бирск, ул. Интернациональная, 10.
Бирский государственный педагогический институт.
Отдел множительной техники БирГПИ